ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 8 (355)
АВГУСТ 2021

ТАТАРСТАН ТЕРРИТОРИЯНЕ КОМПЛЕКСЛЫ ҮСТЕРҮ ҮРНӘГЕНӘ ӘЙЛӘНӘЧӘК

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Катерина Котова,
Луиза Шарова
Фотографлар: Ната Смирнова, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Игорь Глушков, Олег Бурилов
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: ТР төзелеш, архитектура
һәм ТКХ министры Марат Айзатуллин. Фото: Рамил Гали

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: Е-2779
Басарга кул куелды: 13.08.2021
Басмадан чыкты: 19.08.2021
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79
Коммерция директоры:
Юлия Фасахова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә

Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

«АЛТЫН» МАРТА

Кайчакта без инглизләргә кызыгып та, көнләшеп тә карыйбыз. Алар үз традицияләрен ничек шулай саклый ала соң? Дөньяда ни генә бармасын, кичке сәгать биштә – рәхим итегез – файв о`клок. Сайлау нәтиҗәләре нинди генә булмасын, иртәнге ашка – рәхим итегез, сэр, солы боткасы. Ә аларның иртәнге эчпошыргыч «Файнэншл Таймс»ны укудан башлау гадәтләре, королевага һичшиксез «Сез галиҗәнапләр» яисә, инде фәлән яшькә җиткән булса да, аңа «мэм» дип эндәшүләре... Һәм бу бер ел яисә дистә еллар дәвамында гына түгел, гасырлар буена шулай бара... Хәер, белгән кешеләр, уңышларның нигезендә нәкъ менә традицияләргә хөрмәт белән карау ята, диләр. Һәм әгәр без үз традицияләребезгә алар кебек сак карасак, галәмдә генә түгел, Марста да беренче булыр идек!

Ә беләсезме, ихтимал, монда күпмедер дәрәҗәдә дөреслек бардыр да. Казан кызы Марта Мартьянова яулаган Олимпия алтынына нәкъ менә традицияләрне саклау дип карарга кирәк. Травма алган килеш, тешен кысып беренчелек өчен көрәшкән һәм җиңүгә ирешкән Мартабыз шушы көннәрдә Токиода узган Олимпия уеннарында батырлык, фидакарьлек үрнәге күрсәтте. Ә батырлыкка омтылу кичә генә түгел, моннан ярты гасыр диярлек элек – Казан фехтование мәктәбе ачылган елларда башланды. Бөек тренер Владимир Житлов, 1976 елда Монреальдә узган Олимпия уеннары чемпионкалары Валентина Никонова, Ольга Князева, Наилә Гыйләҗева, 2012 елда Лондонда үткән Олимпиаданың көмеш призеры Камилә Гафурҗанова... Нәкъ менә алар безгә «алтын» Мартаны бүләк иткән атаклы фехтование мәктәбенә нигез салды, данын еракларга таратты, җиңү өчен мөмкинлекләр чигендә көрәшү үрнәге күрсәтте.

Һәм хәзер инде инглизләр бездән көнләшсен.

Сезнең ватанпәрвәр редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

100 яшь «ТАТАРСТАН» журналына

\# ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

\# бары тик ТАТАРСТАНДА

ТУГАН ТЕЛЛӘР БИШЕГЕ

Казанда 1922 елның көзендә ачылган югары уку йортында лекцияне берьюлы биш телдә – марича, русча, татарча, удмуртча һәм чувашча укыйлар. Көнчыгыш педагогика институты Татарстан һәм Урта Идел буендагы башка республикалар өчен укытучылар әзерләргә тиеш була. Җирле халыкларның туган теле һәм әдәбияты, мәдәнияте һәм этнографиясе буенча укытучылар әзерләү өчен махсус көнчыгыш бүлеге ачыла. Рус булмаган халыклар вәкилләре институтка ташламалы шартларда кабул ителә, күпләре – максатчан юллама буенча. Мәсәлән, чуваш студентлары ел саен гомуми укучылар саныннан 20–25 процентны тәшкил итә. Әлеге югары уку йортында Чувашиянең булачак халык шагыйре Петр Хузангай, язучы Дмитрий Данилов, тел белгече Николай Резюков белем алган.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

6. Алда өй туйлары көтәме?
10 ел эчендә ничек 30 миллион квадрат метр торак төзергә

10. Гаять зур планнар юлында
Татарстанда нинди объектлар төзелә

14. Бәхетлеләр каласы
Киләчәк кайда чынга аша

24. Ык елгасы ярында,
яисә Авыл тормышын дөнья трендларына яраштыру җиңелме

28. Гасырлардан ашкан манара
Югала барган ядкәрне ничек саклап калырга

32. Безнең гасыр лицее
Кайсы мәктәптә начар укып булмый

36. Башкала интерьерында Африка чалымнары
Яңа зоопаркта нәрсәләр бар

игелекле эшләр

42. Җәйге бәйрәмнәр
Безнең бәйрәмнәр нәрсә белән җәлеп итә

46. Халык ашлары
Чын ирләр нинди пәрәмәчләр пешерә

52. Тел, бию һәм глобальләшү
Самара татарлары традицияләрне ничек саклый

58. Рафинат Сәлаховның тормыш линиясе
Җыр ничек туа

64. Шифаханәләр буенча юл күрсәткеч
Кайсы курортларда ял итү яхшырак

мәңгелек кыйммәтләр

74. Тарих сәхифәләре
Империянең соңгы мөфтие

78. Китап киштәсе
2021 ел нинди китаплар белән шатландыра

82. Мәмәткә рәхим итегез!
Үз бәһаңне белеп яшәү

88. Тарихи ядкәрләребез
Борынгы кульязмалар нинди серләрне саклый

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Акыллы гамәлләр

6.07

Петер Сийярто, Венгриянең тышкы икътисадый элемтәләр һәм чит ил эшләре министры, – «Татнефть» компаниясе һәм Венгриядән MOL Group төркеменең уртак предприятиесе тарафыннан резина вагы кушылган битум җитештерү җайланмасын төзү эшләре башланган ТАНЕКОда:

– Алты ел элек без, Европа берлегенең беренче һәм әле дә бердәнбер иле буларак, Татарстанда федераль консуллык ачу турында карар кабул иттек. Яман ниятле дусларыбыз безгә көлеп карады, ә хәерхаһлылары гамәлебезне бик аңлап та бетермәде. Әмма бүген инде бөтенесенә барысы да яхшы аңлашыладыр, дип уйлыйм.

14.07

Марат Җаббаров, Татарстан вице-премьеры – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, – #ТатарстанОнлайн программасының туры эфирында:

– Кагыйдә буларак, ел саен бу чорда республика складларында бәрәңге һәм яшелчә запаслары бетә. Быел пандемия аркасында аларны көньяк төбәкләрдән кайтартуда өзеклек килеп чыкты, менә шунлыктан бәяләр югары сикерде дә. Бер-ике атна дәвамында хәл җайланачак. Өстәвенә, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда, шәхси бакчаларда яшелчәләрнең иртә сортлары уңыш бирә башлады инде. Көзгә барысы да тотрыклы булачак.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

18.07

Михаил Щелкунов, КФУның Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм гаммәви коммуникацияләр институты директоры, фәлсәфә фәннәре докторы, – Казанда узган «Могҗизалы Изге Ана образы Россия һәм дөнья цивилизациясе язмышында» халыкара фәнни-гамәли конференциясендә:

– Изге Алла Анасы образы – барлык диннәр, Россия халыкларының бердәмлеге символы. Анда рус халкының, Россия дәүләтенең, барлык милләтләрнең өметләре, хыяллары берләшкән. Шул ук вакытта ул Россиягә хәзер җитенкерәми торган гадәти кыйммәтләр – гаилә, фидакарьлек, ата-аналык, ана булу символы да.

акыллы гамәлләр /

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

10 ел эчендә **НИЧЕК** 30 миллион квадрат метр торак төзергә

Авыл тормышын **НИЧЕК** дөнья трендларына яраштырырга

Югала барган ядкәрне **НИЧЕК** саклап калырга

«Замбези елгасы» Казан зоопаркына кадәр **НИЧЕК** килеп җиткән

PRESSA

БҮГЕН ТӨЗИБЕЗ,



КИЛӘЧӘКНЕ ТӨЗИБЕЗ

Без ничек яшибез һәм якын киләчәктә ничек яшәячәкбез? Моңа тулы җавапны, мөгаен, сәясәтчеләр, икътисадчылар, ниһаять, социологлар бирердер. Әмма тагын бер вариант бар, иң саллысы – безнең нәрсә төзүбезгә, ничек төзүебезгә һәм нәрсә төзергә планлаштыруыбызга бәя бирү. Безнең кече һәм зур калаларыбызда, район үзәкләрендә һәм ерак авылларда, мәсәлән. Татарстан картасында билгеләнгән күпләгән төзелешнең кайберләре турындагы сүзебез дә бүгенгегә бәя бирергә һәм киләчәкне кайбер футурологларга караганда да төгәлрәк күрергә ярдәм итәр, дип өметләнәбез.

ТАТАРСТАН ТЕРРИТОРИЯНЕ КОМПЛЕКСЛЫ ҮСТЕРҮ ҮРНӘГЕНӘ ӘЙЛӘНӘЧӘК

ТР төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин «Татарстан» журналы сорауларына җавап бирә.

– Марат Мансурович, якындагы ун елда Татарстанда 30 миллион квадрат метр торак төзергә ниятлиләр. Бу бик зур сан. Алар чынмы?

– Әйдәгез санап карыйк. 2021 елдан 2030 елга кадәр республикада 31,1 миллион квадрат метр торак төзү планлаштырыла. Әлеге максатка ирешү өчен, файдалануга тапшырылган торакның еллык күләмен 2,67 миллионнан 3,52 миллион квадрат метрга кадәр җиткерү зарур. Әмма торак төзелеше буенча тотрыклы лидер төбәкләрдән берсе булган Татарстан өчен ниятләнгән саннар бер дә фантастика түгел. Мәсәлән, былтыр республикада 2 миллион 680 мең квадрат метр торак файдалануга тапшырылды. Торак белән тәэмин ителешне бер кешегә күчереп исәпләгәндә бездә Россиядәге уртача күрсәткечтән бер квадрат метрга артыграк килеп чыга.

– Мондый зур колачлы төзелеш татарстанлыларның торак белән тәэмин ителешен яхшыртачакмы соң?

– Планга ярашлы рәвештә, фатирлар, шәхси йортларны файдалануга тапшыруның еллык үсеше татарстанлыларның торак белән тәэмин ителешенең уртача күрсәткечен 28,2 дән 32,6 квадрат метрга җиткерү мөмкинлеген бирәчәк. Аңлашыла ки, квадрат метрларга бәяне базар билгели, ул күп факторларга бәйле. Шунысы мөһим: ажиотаж тынганга, бүген торакка бәяләрнең шактый арзанаюы күзәтелә. Бу се-

зонлылыкка да, ташламалы ипотека кредиты программасының озайтылуына да бәйле. Һәм, табигый инде, торак төзелеше күләменең һаман артуына да.

– Аерым алганда, Лаеш төенендә һәм Зур Яшел Үзәндә күп торак төзелер дип көтелә. Биредә нәрсә салыначак?

– Бурыч – Татарстан башкаласы агломерациясен үстерү кысаларында Лаеш төене (Казан һәм Лаеш муниципаль районы җирләренең бер өлеше) һәм Зур Яшел Үзән (Казан – Яшел Үзән трассасы буендагы җирләр) территорияләрен үзләштерү. Зур Яшел Үзән биләмәләрендә 5 миллион 657 мең квадрат метр торак төзү фаразлана. Әлеге колачлы проектның беренче этабы 2025 елга кадәр тормышка ашырылачак, бу вакытка биредә 888 мең квадрат метр торак төзеләчәк.

Лаеш төене территориясендә исә 4 миллион 423 мең квадрат метрны файдалануга тапшыру ниятләнә. Шулардан 1 миллион 767 меңен – 2024 елга кадәр.

– Анда пәйда булачак торак мохите безнең һаман үсә барган таләпләребезгә җавап бирәчәкме? Ялан кырдагы җәмәгать мәйданнарсыз, машина кую урыннарсыз, эшкә барганда-кайтканда бөкеләр сәбәпле юлга күп вакыт сарыф ителәчәк яңа микрорайон – бик кызыктырырлык перспектива түгел...

– Табигый ки, болай килеп чыкмасын өчен, барысын да алдан ук яхшылап уйларга һәм планлаштырырга кирәк. Аннары исә, кыенлыкларга зарланмыйча, эзлекле рәвештә ниятләнгәнне гамәлгә кертү зарур. Хәзерге вакытта безнең министрлык, Казанның, Лаеш һәм Яшел Үзән муниципаль районнарының башкарма комитетлары, кызыксынган министрлык һәм идарәләр белән бергә әлеге территорияләрнең инженерлык һәм транспорт инфраструктураларын җентекләп өйрәнү һәм планлаштыру белән шөгыльләнә.

– Без инде ел саен үзебездә яңа җәмәгать мәйданнары, парклар, скверлар, яр буйлары пәйда булуга күнектек. Быел һәм киләсе елга да шулай булачакмы? «Безнең ишегалды» президент программасын гамәлгә кертүгә пандемия комачауламасмы икән?

– Былтыр да, быел да «Безнең ишегалды» программасын тормышка ашыру бер генә көнгә дә туктамады. 2020 елда барысы бергә 9,672 миллион квадрат метр мәйдан билгән 1084 объектның исемлеге төзелде һәм расланды, барлыгы 8 миллиард сум акча бүленде. Шунысын да әйтергә кирәк: ресурсларны экономияләү 1084 урынына 1091 объектта юл эшләрен башкару мөмкинлеген бирде. Быел да 1074 ишегалды территориясен төзекләндерүгә 8 миллиард сум акча бүленде, эш тулы куәтенә бара. Исегезгә төшереп үтәм, «Безнең ишегалды» президент программасы комплекслы төзекләндерүгә юнәлтелгән: бу юл һәм тротуарларны ремонтлау, яктырту җайланмаларын кую һәм ремонтлау, эскәмияләр һәм чүп савытлары урнаштыру, каты коммуналь калдыклар ташлау өчен контейнерлар мәйданчыгы булдыру, балаларга уйнар өчен ком-вак таш кушылмасы җәелгән мәйданчыклар җиһазлау, өлешчә яшелләндерү дә. Сүз уңаеннан, РФ субъекты бюджеты акчалары хисабына хосусый территориядәге ишегалларын төзекләндерү һәм андагы асфальт катламын ремонтлау тәҗрибәсе ил өчен уникаль булып тора.

– Ә яңарту таләп ителгән ишегалларының бер өлеше программа кысаларына кермичә калмасмы соң?

– 2019 елда Татарстан Президенты республикадагы ишегалларын төзекләндерүнең киң колачлы программасын башлауга ук, беренче эш итеп барлык ишегалды территорияләре инвентарьлаштырылды. Аны Татарстан Төзелеш министрлыгы муниципаль берәмлекләр һәм республика ТИБ (БТИ) белән бергә үткәрде. Бу эшнең никадәр зур икәнен аңлау өчен, саннарга күз салу да җитә: гомуми мәйданы 70,2 миллион квадрат метрлы 9628 ишегалды тикшерелде! Бер генә ишегалды да экспертлар игътибарыннан читтә калмады. Максат ачыкланды: мәйданы 49,36 миллион квадрат метрлы 6845 ишегалды комплекслы ремонт таләп итә. Чират барысына да җитәчәк, кайбер йорт яны территорияләрен быел ук, икенчеләрен исә бераз соңрак яңартачаклар. Программа 2014 ел азагына кадәр гамәлдә, ел саен аны тормышка ашыруга 8 әр миллиард сум акча бүлү ниятләнә. Төзекләндереләчәк ишегаллары исемлеге исә үзләренә бүленгән финанслау лимиты кысаларында муниципаль берәмлекләрнең гаризалары нигезендә формалаша. Исегезгә төшереп үтәм, dvor.tatar порталында төзекләндереләчәк ишегалды территорияләре план-схемаларын җәмәгать тикшерүләре үтә. Биредә төзекләндерүнең интерактив картасы да бар – үз ишегалдының кайсы елда яңартыласын һәркем белә ала.

Безне әле алда территорияләрне тагын да төзекләндерү буенча зур эш көтә, ул хакимият һәм халык тырышлыгын берләштерүне таләп итә. Үзара хезмәттәшлегебез нәтиҗәсендә ишегаллары, җәмәгать мәйданнары төзекләнәчәк, уңайлырак булачак, бу исә республикабыздагы тормыш сыйфатын да сизелерлек яхшыртачак.

– ТР Президенты мондый бурыч куйды: Татарстан башка төбәкләр өчен территорияне комплекслы үстерү үрнәгенә әйләнергә тиеш. Әлеге җәһәттән Татарстан Республикасындагы торак төзелеше стратегиясе никадәр үзгәрәчәк (яки төзәтмәләр кертеләчәк)?

– 2020 ел азагында «Территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 494-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителде. Аны гамәлгә кертү максатыннан Татарстанда «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында»гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында», «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлауны оештыру турында»гы Татарстан Республикасы Законының 2 нче маддәсенә үзгәреш кертү хакында», «Гражданнарның торакка хокукын яклауны тәэмин итү турында»гы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» законнар кабул ителде.

Моннан тыш, ТР Министрлар Кабинеты норматив-хокукый актлары исемлеге формалаштырылган, 494-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларын гамәлгә кертү өчен, аларны 2021 ел дәвамында эшләп бетерергә кирәк. ТР Министрлар Кабинеты карары проекты әзерләнгән, анда норматив-хокукый актларның бөтен мәҗбүри проектлары исәпкә алынган. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары комплекслы үстерү максатларында беренче чиратта үзләштереләчәк территорияләрне билгели. Тиешле норматив-хокукый актларны кабул итү әлеге механизмны практикада гамәлгә кертү мөмкинлеген бирәчәк.

Территорияләрне комплекслы үстерү механизмын гамәлгә керткәндә эшнең шактый өлешен җирле үзидарә органнарына башкарырга туры киләчәк. Шунысын да әйтеп китәсем килә: бүген төзүчеләр йортлардагы торак биналарның бәясе, торак мәйданы, урнашу урыны, җиренә җиткерелүе, шулай ук социаль инфраструктура белән тәэмин ителеше буенча төрле вариантларын тәкъдим итә.

Инвестиция программасы кысаларында социаль ипотека буенча төзеләчәк торакны проектлаганда Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды социаль инфраструктура объектларын да кертә. Шул ук вакытта зур торак районнарны («Салават күпере», М-14 һ.б.) гамәлгә керткәндә социаль инфраструктураны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре яки инвесторлар хисабына өстәмә рәвештә үстерү мөмкинлеге дә карала.

– Алданган пайчылар проблемасы кайчан тулысынча хәл ителер икән?

– Татарстан Президенты һәм федераль үзәк кабул иткән карарлар, Хөкүмәт, ТР Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары һәм пайчыларга ярдәм итү фондының уртак эше нәтиҗәсендә 2016–2019 елларда 3884 пайчы өчен 29 объект файдалануга тапшырылды. Былтыр республика программасы буенча җиде проблемалы йорттагы 398 алданган пайчының хокуклары торгызылды.

Быел беренче яртыеллык нәтиҗәләре буенча тагын 891 алданган пайчының хокукы торгызылды. Өч проблемалы бина: Академик Губкин урамындагы 2 нче йорт («МЧС» ТК, Казан), Достоевский урамындагы 57 нче йорт (Казан), Мөңьеллык урамындагы 1А йорты (Алабуга) төзелеп бетте һәм файдалануга тапшырылды. Бүген тагын җиде проблемалы объектта эш бара. Ел азагына кадәр алар файдалануга тапшырылачак һәм 1654 пайчы күптән көтелгән фатирлы булачак.

Кызганычка, күптән түгел тагын бер объект ачыкланды, ул 1 июльдән проблемалы йортларның бердәм реестрына кертелде. Әлеге объект буенча ТР Хөкүмәте Уртак төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау фондына (ДОМ.РФ) төзүчене банкрот итеп тануны үтенеп мөрәҗәгать юллады.

2020 елда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Свей» фирмасы» ҖЧҖнең ике объекты пайчыларына ярдәм күрсәтү турында аерым карар кабул итте – анда проект документациясендә һәм төзелешкә рөхсәт кәгазендә каралмаган 350 фатир алдалап сатылган. 2021 елның икенче яртыеллыгында Казанда Рәүис Гәрәев урамында 160 фатирлык компенсация йортын төзи башлау планлаштырыла.

10 ТАТАРСТАННЫҢ ЗУР ТӨЗЕЛЕШЕ



ИННОПОЛИСТА ЯҢА «Ю-1» ТОРАК МИКРОРАЙОНЫН ТӨЗҮ

Микрорайонда уртача биеклектәге йортларда өч меңнән артык фатир, җир кишәрлекләре булган комфорт-класслы 55 арендага бирелә торган йорт, шулай ук 975 торак ячейкасына исәпләнгән уңайлы коливинг төзү планлаштырыла. Яңа микрорайонда гомуми белем бирү мәктәбе һәм сәнгать мәктәбе, балалар бакчалары, коворкинглар, кибетләр, кафе һәм ивент-холлар салу да каралган. «Ю-1» проектын төзеп бетергәннән соң, ИТ-шәһәрдә халык саны 25–30 меңгә җитәргә мөмкин.

ЯҢА БАЛАЛАР БАКЧАЛАРЫ

«Торак һәм шәһәр мохите» һәм «Демография» милли проектлары кысаларында быел 3100 урынга исәпләнгән 16 балалар бакчасы төзелергә тиеш. Төзелешкә салыначак акчаларның гомуми күләме 4 млрд сумга якын булачак. 2018 елдан 2020 елга кадәр Татарстанда «Демография» милли проекты составына кергән «Хатын-кызларның мәшгульлегенә ярдәм – өч яшькә кадәрге балаларга мәктәпкәчә белем бирү өчен шартлар тудыру» федераль проекты кысаларында гына да 52 объект кулланышка тапшырылды, аларда 11 160 урын булдырылды, шуларның 5 635е – ясле балалары өчен.



ЯБЫК ЙӨЗҮ БАССЕЙННАРЫ, БОЗ САРАЙЛАРЫ ҺӘМ УНИВЕРСАЛЬ СПОРТ МӘЙДАНЧЫКЛАРЫ ТӨЗҮ

Адреслары – бөтен республика. Лаешта һәм Балык Бистәсендә ачылганнан соң, республикада төзелгән боз сарайларының саны кырык тугызга җитте. Ябык йөзү бассейннарын, боз сарайларын һәм универсаль спорт залларын төзү буенча колачлы программа ТР Президенты карарына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

ЯҢА ҖӘМӘГАТЬ МӘЙДАННАРЫ

Өч ел эчендә* җәмәгать мәйданнарын (парклар, скверлар, яр буйлары) төзү һәм яңартуга 14 миллиард сум акча тотылды. Шуларның 9 миллиард 765 миллион сумы – республика акчалары. Калганнары – федераль үзәк ярдәме һәм кече шәһәрләр һәм тарихи җирлекләр өчен грантлар программасы.



* 2018 елдан 2020 елга кадәр. – Ред. иск.

«МӘСКӘҮ – ТҮБӘН НОВГОРОД – КАЗАН» М-12 ЮЛЫ

Зур тизлекле «Мәскәү–Казан» автомобиль юлы республиканың биш районы территориясе аша үтәргә тиеш. Трассаның гомуми озынлыгы – 729 километр, шул исәптән аның 142 километры Татарстан территориясендә салыначак. Автомагистраль төзелеше сигез этапка бүленгән. Җиденче һәм сигезенче этаплары Татарстанга туры килә. Юл төзелеше 2024 елда төгәлләнер дип көтелә.

ЗУР КАЗАН БОҖРАСЫ, СОҢГЫ ЭТАП

Зур Казан боҗрасының соңгы этабының 1,2 километрга сузылган икенче участогында эшләрне быел тәмамларга исәплиләр. Беренче участокны төзү 2,3 миллиард сумга төште (шул исәптән 1 миллиард сум акча федераль бюджеттан бүленде). Икенче участокның бәясе – 2,6 миллиард сум (1,76 миллиард сум – федераль бюджеттан). Зур Казан боҗрасының соңгы этабының беренче участогын кулланышка 2020 елның августында тапшырдылар. Ул Татарстан башкаласы юлларындагы киеренкелекне шактыйга киметергә тиеш.

М-12 АВТОЮЛЫН ЕКАТЕРИНБУРГКА КАДӘР ДӘВАМ ИТҮ

РФ Президенты тәкъдиме белән «Мәскәү–Түбән Новгород–Казан» М-12 юлын Екатеринбургка кадәр сузарга дигән карар кабул ителде. Татарстанда җәяүлеләр өчен 22 җир асты кичүе, Түбән Кама һәм Яр Чаллы шәһәрләрен урап узу өчен 81,4 километрлы юл, Чулман елгасы аша күпер салу каралган, М-7 трассасының кайбер участокларын реконструкцияләү дә күздә тотыла.

«АДЫМНАР» ПРОЕКТЫ

Полилингваль мәгариф комплексы челтәрен төзү. Казанда һәм Алабугада ачылган беренче ике полилингваль мәктәпкә быел тагын берсе – Яр Чаллыда төзеләчәге өстәлә. 2024 елга аларның саны алтыга җитәчәк: Казанда – ике, Яр Чаллыда, Түбән Камада, Алабугада һәм Әлмәттә – тагын берәр.

КАЗАН МЕТРОСЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЛИНИЯСЕ

Башкала метросының төзелеп килүче икенче линиясенең беренче участогына «Ю. Фучик», «10 нчы микрорайон», «ТАССРның 100 еллыгы» һәм «Академик Сахаров урамы» станцияләре, шулай ук дүрт куу тоннеле керәчәк. Аның озынлыгы 5,7 километр булачак.



ГОРЬКИЙ ШОССЕСЫНЫҢ ДУБЛЕР ЮЛЫ

Несмелов урамыннан яңа төзеләчәк «Серебряный бор» торак комплексы аша федераль әһәмияттәге «Волга» М-7 юлына кадәр автомобиль юлын салу «Куркынычсыз сыйфатлы юллар» милли программасына керә. Беренче этап – Несмелов урамыннан «Серебряный бор» торак комплексына кадәр, озынлыгы – 7,05 километр. Икенчесе – «Серебряный бор» торак комплексыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр, озынлыгы – 8,8 километр.

ТАТАРСТАННЫҢ ТОП-10 ЯҢА ТӨЗЕЛЕШЕ*

КАЗАН ИЗГЕ АНА ИКОНАСЫ СОБОРЫ ТӨЗЕЛЕШЕ

Объектның нигезенә истәлек ташы 2016 елның 21 июлендә салынды. Быелның 21 июлендә собор изгеләндерелде һәм гыйбадәт кылучылар өчен ачылды.

ЯШЬЛӘР ӨЧЕН «УРАМ» ЭКСТРИМ-ПАРКЫ

Россиядә иң зур экстрим-парк. Казансу ярында, Миллениум күпереннән ерак түгел урында төзелде.

ЯР ЧАЛЛЫДА ЯҢА ОНКОЛОГИЯ ҮЗӘГЕ

Үзәкнең амбулатор-поликлиника һәм радиология комплекслары елына 100 мең кешене кабул итүгә һәм нур белән дәвалау буенча 30 мең сеанс үткәрүгә исәпләнгән.

* «Татарстан» журналы версиясе буенча

«АДЫМНАР – БЕЛЕМГӘ ЮЛ» МӘГАРИФ ПРОЕКТЫНЫҢ ПОЛИЛИНГВАЛЬ МӘКТӘПЛӘРЕ

Проект заманча мәктәп моделе булдыруны күз уңында тота, анда рус, татар һәм инглиз телләрендә ныклы белем биреләчәк. Беренче ике полилингваль мәктәп Казан һәм Алабуга шәһәрләрендә ачылды. 2024 елга аларның саны алтыга җитәчәк.

ЧИСТАРТУ КОРЫЛМАЛАРЫ

«Экология» милли проектының «Иделне чистарту» федераль проекты кысаларында 10 муниципаль берәмлектә 11 чистарту корылмасы төзелде һәм яңартылды, шул исәптән Казанда, Яр Чаллыда, Алабугада. Тагын ике объект Питрәч муниципаль районының Кощаково авылында төзелә. Бу елгага агып төшкән пычрак суның күләмен өч мәртәбәгә киметергә мөмкинлек бирә.

КАЗАНДА БАЛАЛАР ОНКОЛОГИЯСЕ, ГЕМАТОЛОГИЯСЕ ҺӘМ ХИРУРГИЯСЕ ҮЗӘГЕ

«Сәламәтлек саклау» милли проекты һәм «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлеген саклауны үстерү» төбәк проекты кысаларында төзелде. 100 урынга исәпләнгән. Татарстан һәм Идел буе федераль округына кергән башка субъектларда яшәүче балаларны кабул итәчәк.

ЯР ЧАЛЛЫДА ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ТЕАТРЫ БИНАСЫ

Элеккеге «Колизей» күңел ачу комплексы урынында төзелде. Тамашачы залы 300 урынга исәпләнгән, бинада шулай ук яшьләр үзәге дә урнашты.

ӘЛМӘТТӘ ИҖТИМАГЫЙ МӘДӘНИ ҮЗӘК

Элеккеге шәһәр универмагы урынында төзелде. Мәгълүмати-күргәзмә кырын, интерактив фәнни-танып белү үзәген, лингвистика үзәген һәм күпфункцияле концерт залын үз эченә ала.

КАЗАНДА ЙОГЫШЛЫ АВЫРУЛАР ХАСТАХАНӘСЕНЕҢ ЯҢА КОРПУСЫ

Рекордлы 100 көн эчендә төзелде. 232 урынга исәпләнгән. Таләп ителгәндә урыннар санын 504 кә кадәр арттырырга мөмкин.

КАЗАНДА КАБАН КҮЛЕ ЯР БУЕН РЕКОНСТРУКЦИЯЛӘҮ

Төзекләндерү буенча иң мөһим һәм күләмле проектларның берсе. Татарстан Президенты сүзләренә караганда, бу яр буе тарихи нигезе сакланган җәмәгать мәйданнарын тулысынча үзгәртеп кору, яңартуның үрнәге була ала.

БӘХЕТЛЕЛӘР ШӘҺӘРЕ

Автор фотолары

Автор: **Ольга Туманская**

Җәяүлеләр кичүендә пилотсыз таксиның әйбер китерүче роботны үткәреп җибәрүен күзәтәм. Болар барысы да шаулап утырган каеннар, зәп-зәңгәр күк йөзе фонында. Әйе, мин Иннополиска югары технологияләр шәһәре турында «архитектура» репортажы язарга барган идем. Әмма каланы үзем өчен бөтенләй башка яктан ачтым. Иң әүвәл бу бәхетлеләр шәһәре икән бит.

**БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН:
ИҢ ЯШЕ ҺӘМ АЛДЫНГЫСЫ**

Иннополис – Россиянең иң яшь һәм технологик шәһәре. Беренчедән, әлегә бу безнең илдә безнең гасырда төзелгән беренче һәм бердәнбер шәһәр. Икенчедән, бүген аның халкының уртача яше нибары 31 яшьне тәшкил итә. Киләчәктә биредә 155 мең кеше яшәр, дип планлаштырыла. Иннополис – югары технологияле проектларны үстерергә тиешле ИТ-белгечләр өчен махсус төзелгән кала. Әлеге максатта «Иннополис» Махсус икътисадый зонасы да ачыла. Югары дәрәҗәдәге кадрларны әзерләү белән мәгариф кластеры шөгыльләнә, аңа шәһәрдәге мәктәпләр, лицей һәм университет керә. Беренче мәртәбә мондый инновация үзәген булдыру идеясе Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан 2010 елда яңгырый. Тәүге нигез ташын салу тантанасы 2012 елда оештырыла, һәм өч ел үтүгә, 2015 елның 9 июнендә, Иннополис шәһәренең рәсми рәвештә яши башлавына старт бирелә. Монда уникаль һәм бик уңайлы шәһәр мохитен булдыруга ирешәләр, ә архитектурасы моңа басым гына ясый. Иннополис – чыннан да киләчәк каласы. Шәһәр планын төзү белән Сингапурны үзгәртеп кору департаменты генераль планлаштыручысы Лиу Тай Кер җитәкчелек итә. «Казан Гипронииавиапром», генераль проектлаучы буларак, барлык инженерлык һәм социаль инфраструктура документларын эшли. Төп объектларны генераль подрядчы оешма – «Казан» җитештерү-төзелеш берләшмәсе» ҖЧҖ төзи.

1
Иннополис Университеты бинасы.

2
Махсус кечкенә бүлмәләр. Анда, мәсәлән, видеоконференция элемтәсе буенча сөйләшүләр үткәрергә була.

3
Урбанист, Иннополисның шәһәр проектлары буенча белгече Анастасия Козырицкая.

«МОНДЫЙ ШӘҺӘР БАШКА ЮК»

– Болары нинди «шакмаклар» тагын, өстә… дивардардан чыккан кебек? – дип сорыйм гидым – урбанист, Иннополисның шәһәр проектлары буенча белгече Анастасия Козырицкаядан.

Дөресен генә әйткәндә, архитектор булмагач, миңа күргәннәремне тасвирлау кыенрак кебек. Иннополис Университеты бинасы тәэсирләндерә, гаҗәпләндерә, шикләнергә мәҗбүр итә – әлеге бина идеясен дөрес итеп аңлата алырмынмы?

– Бу махсус кечкенә бүлмәләр, – дип, бик тиз аңлап ала соравымны Анастасия.– Әгәр аерым, тыныч урын кирәк икән, анда һәркем керә ала. Әйтик, бу бүлмәләрдә видеоконференция элемтәсе буенча сөйләшүләр алып барырга була.

Каршымдагы бина һавада эленеп тора кебек. Аның рельефы тере, динамик. Тыштан карагада, университетның эчендә бөтенләй башка форма яшеренгәнгә ышануы кыен: бер җирдән икенчесенә күчү урыннары, теге «һавада эленеп торган» шакмак-бүлмәләр булган бик зур атриум ул. Монда «классик» лекция заллары һәм гадәти парталар урынына йомшак пуфиклар куелган сыйныфлар да бар, үзәктә – өч катны биләгән китапханә (аңа бормалы баскыч буенча күтәрелергә мөмкин), университетны дүрт торак кампусы белән тоннель берләштерә, скверда кояш батареялары ярдәмендә эшли торган USB-портлы эскәмияләр тора.

– Заманча архитектура – шәһәрнең гомуми концепциясенең бер өлеше, – дип сөйли Анастасия. – Һәр бинаның үзенә генә хас өслүбе бар, ләкин алар, күркәм рәвештә берләшеп, Иннополис шәһәренең кабатланмас йөзен тәшкил итә. Безгә килгән кеше шуны аңлый: мондый шәһәр башка юк, ул – уникаль.

Университеттан ерак түгел генә югары технологияле персоналы булган үзенчәлекле кунакханә төзеләчәк. Әйе-әйе, кешеләргә роботлар хезмәт күрсәтәчәк, алар клиентларның теләкләрен, тойгыларын «укый» алачак, кунакның туган телендә сөйләшәчәк, ашауэчү тәкъдим итәчәк. Кунакханәдәге җиһазлар да килгән кеше турындагы мәгълүматны анализлау нигезендә эшләячәк. Бер робот алтылап хезмәткәрне алыштырырга сәләтле

1

2

3


булачак. Мөгаен, биредәге шәһәр архитектурасы чыннан да «киләчәктән кунак» булыр. Университет бинасына карап, мин моның шулай булачагына шикләнмим.

Тагын бер архитектура җәүһәре – Лобачевский исемендәге Технопаркның яңа бинасы. 29 мең квадрат метрлы әлеге гаять зур «бумеранг» төзелеше 2020 елның декабрендә тәмамлана. Ул 1,5 мең эш урынына исәпләнгән. Эчке ягы – таләп ителгәндә бик тиз үзгәртеп була торган киңлек-трансформер. Югары катлардагы гаять зур опенспейслар резидентларга, үз өслүбләрен кулланып, дизайн буенча үз теләкләрен истә тотып, үз ихтыяҗларына туры килгән офислар ачарга мөмкинлек бирә.

«Лобачевский» – Иннополисның икенче технопаркы. Беренчесе, Попов исемендәгесе, мөгаен, шәһәрдәге иң билгеле архитектура проектыдыр. Биек бөҗра рәвешендә эшләнгән технопарк безне Иннополиска кергәндә үк каршы ала. Тоташ пыяла диварларга карагач, кояшлы көннәрдә анда эшләү уңайлымы икән, дигән шик керә. Уңайлы. Эчтә – үз микроклиматы булган табигый оазис. Эчке ишегалды-бакчада эштән соң ял итәргә теләүчеләр җыела. Бина үзе өч «табигать» зонасына бүленгән – агач, таш һәм үлән, алар, болай да уңайлы навигацияне гадиләштереп, зоналарның бизәлешендә чагылыш тапкан. Биредә зур конференцияләр, биеннале, форумнар уздырыла. Әмма 45 мең квадрат метрны биләгән урында алардан башка да тормыш гөрли. Арендага бирелми, буш калган мәйданнар юк диярлек. Өстәвенә монда 5 коворкинг эшли, аларда башлыча стартаплар урнашкан.

Узган елда Попов исемендәге Технопарк Office Development категориясендә күчемсез милек өлкәсендәге абруйлы European Property Awards халыкара конкурсы бүләгенә ия булган. Жюри бинаның архитектурасына гына түгел, интерьер дизайнына да, бина төзелешендә һәм бизәлешендә кулланылган инновацияле материалларга да югары бәя биргән.

Иннополисның сәнәгать зонасы бик тиз үсәчәк. Әлеге вакытта шәһәрдә архитектура күзлегеннән караганда футуристик саналган тагын ике технопарк төзелә. Анда югары технологияләр өлкәсендә эшли торган предприятиеләрнең сәнәгать куәтләре урнашыр дип көтелә. Әйе, бик тиздән Иннополис чиста җитештерү шәһәре булачак.

«ЙӨРИМ ТАҢДА...»

Машина көтә! Мобиль кушымта хәбәр итә: без чакырган такси килеп җиткән. Борылып карыйбыз – чыннан да автомобиль тротуар янында көтеп тора. Әйе, нәкъ шулай, безне машина үзе көтә, чөнки йөртүче урыны буш. Арткы утыргычка махсус планшет куелган.

4 Н. И. Лобачевский исемендәге Технопаркның яңа бинасы.

5 Пилотсыз такси.

Мин «старт» төймәсенә басам, һәм пилотсыз машина – «беспилотник» урыныннан кузгала. «Күзгә күренми торган көчнең» руль әйләндерүен күзәтеп барам. Спидометрга күз салам, «күренми торган йөртүченең» рөхсәт ителгән тизлекне бер генә километрга да арттырмавын билгеләп үтәм. Аның без, руль артындагы кешеләр, яраткан «20+» мөмкинлегенә исе китми. Бәлки алар катнашында бер генә юл-транспорт һәлакәте дә теркәлмәвенең сәбәбе нәкъ шундадыр? Ә бит Иннополиста соңгы ике елда пилотсыз машиналар 12 меңгә якын рейс ясаган. Әлбәттә, вакыт барысын да күрсәтер.

Сүз уңаеннан, юл хәрәкәте җәһәтеннән бик уңайлы шәһәр бу. Шуңа күрә пилотсыз таксиларны сынау өчен Иннополис сайланган да. Кызыклы үзенчәлек: шәһәрдә светофорлар юк. Бүген мондагы барлык юл чишелешләре боҗра буенча хәрәкәт итүгә нигезләнеп эшләнгән. Гадәти юл чатлары белән чагыштырганда, бу куркынычсызрак санала. Факторлар берничә: анда сулга борылыш юк, транспорт агымнары кисешми һәм, ниһаять, боҗрага кергәндә машина йөртүче тизлекне өчтән бер тапкырга диярлек киметергә мәҗбүр.

Хакыйкать хакына шунысын да әйтергә кирәк: Иннополиста юллар буш диярлек. Болар барысы да бүген популяр саналган 15 минутлык шәһәр концепциясен куллану нәтиҗәсендә мөмкин була – биредә барлык социаль инфраструктура объектлары кул сузымында гына диярлек. Икенче сәбәп – җәяү һәм велосипедта йөрү модасын актив кертү. Инфраструктура моңа да мөмкинлек бирә.

– Иннополисның гомуми шәһәр төзелеше концепциясенә үзара бәйләнгән бердәм җәмәгать мәйданнары челтәрен кертүгә ирештек, – дип аңлата Анастасия Козырицкая. – Мәсәлән, бездә Квант бульвары бар, ул күп кенә мөһим объектлар – торак йортлар, балалар бакчалары, лицей, технопарклар, университетны үзара бәйли… Ягъни Иннополиста яшәүчеләр өйләреннән эшкә, укырга яисә ял итәргә машинасыз, яшеллеккә чумып утырган җәмәгать мәйданнары аша бара ала. Җәяүле өчен уңайлы шәһәр – замана таләбе, һәм без моңа туры килергә тырышабыз.

Хәер, монда җәяүлегә һәм автомобилистка гына уңайлы дип әйтү дөрес булмас. Велосипедчыны да онытмаганнар. Юл хәрәкәтендә катнашучылар арасында ниндидер низаглар чыгу мөмкинлеге юк диярлек. Велосипед полосалары юлның буеннан буена билгеләнгән, торак комплекслар аша үтеп, аларны җәмәгать мәйданнары һәм объектлар белән бәйли. Теләсә кайсы җиргә велосипедка утырып бару һәм кайту бик уңайлы.Әмма «барып кайту», аңлавыгызча, инфраструктураның бер өлеше генә. Тимер дустыгызны дөрес урында калдыру һәм аның өчен тыныч булу да мөһим.

Бер ишегалды яныннан үтеп барганда, аның уртасында велосипедлар өчен ябулы парковка күрәм. Шәһәрдә «сәпидләрне» ел дәвамында саклау мәсьәләсе шул рәвешле хәл ителгән – урамда булса да, түбә астында аларга кар да, яңгыр да куркыныч түгел. Һәр зур объект – мәдәни үзәк, технопарк, университет янында диярлек уңайлы велосипед кую урыны бар. Шәһәрдәге мәктәпләрнең берсе ераграк, каенлык эчендә урнашкан. Әмма ата-анага баласын мәктәпкә илтергә кирәкми: укучыларның олысы-кечесе анда үзләре бара – самокатта яисә велосипедта. Тиз, күңелле, сәламәтлек өчен файдалы. Һәм дөрес гадәт бала чактан ук тәрбияләнә. Хәзер инде мәктәп янындагы 70 урын гына җитми дә икән – шәһәр аны зурайтачак.

Кайчандыр, Казанда транспорт реформасын башлар алдыннан, транспорт сәясәте буенча абруйлы эксперт Михаил Блинкин республика башкаласына килә. Ул шәһәр җитәкчелегенә кырыс чаралар күрергә мәҗбүр булачаксыз дигән фикерне җиткерә, чөнки Казан ел саен дистәләгән мең машинага «арта» бара. Кешеләрнең күпчелегендә эшкә көн саен автомобильдә барудан баш тартуны күздә тоткан дөрес гадәт тәрбияләргә кирәк, дип аңлата Блинкин. Һәм автоконцерн шәһәре Мюнхенны мисалга китерә. Гаиләдә берничә машина булса да, бу шәһәрдә яшәүчеләрнең күпчелеге эшкә велосипедта яисә метрода баруны өстен күрә. Эксперт аңлатуынча, Казанны да нәкъ менә шундый язмыш көтә. Иннополис исә иң баштан ук үзенә шундый язмышны сайлаган.

6

Һәр зур объект – мәдәни үзәк, технопарк, университет янында диярлек уңайлы велосипед кую урыны бар.

ТӨЗЕ ӘЛЕ!

Янәшәдәге йорт балконына карыйм – зур гына үрмәле үсемлек диварларны, түбәне

каплаган... «Кыяр бит!» – дип уйлап куям мин. Күрәсең, кемдер кечкенә генә бакча ясаган. Менә шундый пыяла панорама фатирларны якты итеп, электроэнергияне саклап кына калмыйча, кешеләрне төрле тәҗрибәләргә дә илһамландыра.

Гаҗәп түгел, илһамландыру – Иннополис архитектурасының беренчел бурычы бит. Технопаркларның бормалы формаларыннан, университетның футуристик дизайныннан алып, һәр йорты бер-берсенә охшамаган торак төзелешенә кадәр. Төсләрнең нигездә тынычлык бирә торганнары сайланган, табигый – ак, соры, яшел, коңгырт. Хәер, Иннополиста җетелек тә җитәрлек.

– Бирегә күз салыгыз әле! – дип, йортларның берсенә ишарәли Анастасия. Баскыч янындагы диварга картина ясалган – табигать мотивлары һәм нейроннар челтәреннән торган гадәти булмаган пейзаж фонында хатын-кыз сурәте. – Бу танылган урам рәссамнары һәм биредә яшәүчеләрнең уртак эше – безнең язгы ворк-шоп нәтиҗәсе. Мондый иҗади активлык барысына да бик ошады.

Торак төзелеше концепциясенең тагын бер үзенчәлеге – түбәнге катларның барысы да диярлек коммерция фирмалары өчен калдырылган. Чөнки шәһәрне шәһәр иткән иң беренче нәрсә – алга киткән социаль инфраструктура. Мондый карарның нәтиҗәсе буларак монда кечкенә кафе һәм рестораннар, азык-төлек кибетләре һәм эре сәүдә челтәрләре филиаллары, матурлык салоннары, чәчәк һәм китап кибетләре пәйда булган...

– Гомумән алганда, бездә көн саен кулланыла торган товар һәм хезмәтләргә булган ихтыяҗ канәгатьләндерелә, – дип сөйли Анастасия. – Әмма без яңа мәйданнарның пәйда булуын көтәбез, димәк, кече бизнес та артачак, чөнки көндәшлек хезмәт күрсәтүләрне югарырак дәрәҗәгә күтәрергә ярдәм итә. Ә Иннополистагы кулланучы чыннан да бик таләпчән.

Сүз уңаеннан, Иннополисның планлаштырылуы гына түгел, йортларның үзләре дә акыллы. Өйгә кергәндә битнең формасын билгели торган Face ID–сканер куелган. Ул кешене автомат рәвештә танырга булышa, димәк, ишекне кемгә ачарга, кемгә ачмаска кирәклеген билгели. Яшәүчеләрне тәңгәлләштерүнең икенче варианты – бармак эзе буенча. Үзең белән ачкычлар күтәреп йөрисе дә юк. Фатирлардагы «акыллы» исәпләгечләр – кешенең тормышын гадиләштерү, ә урамнардагы һәм җәмәгать мәйданнарындагы «акыллы» яктырткычлар шәһәр хакимиятенең эшен җиңеләйтү өчен куелган.

Бүген Иннополиста 4 меңгә якын кеше яши. Тагын меңгә якын кеше көн саен бирегә эшкә килә, аларны маятниклы миграциягә кертәбез. Әйе, әлегә бу шәһәрдә торак буенча тәкъдим ихтыяҗдан зуррак. Мәсәлән, 2021 елга Иннополиста 22 күпфатирлы йорт төзелгән. Бу 1,5 меңнән артык фатир дигән сүз, ләкин аларның барысы да диярлек арендага бирелә, чөнки Иннополисның күпкатлы комплекслары асылда – муниципаль торак. Әлегә ике катлы таунхауслардагы фатирларны һәм апартаментларны гына сатып алырга була. Кварталның беренче чираты кулланышка тапшырылган – «Зион» торак комплексының 21 йортында 168 фатир исәпләнә.

Әлбәттә, шәһәр үсәчәк. Төзелешнең яңа комплекслы планы биредә 500 мең квадрат метрдан артыграк торак һәм коммерцияле күчемсез милек салуны күз уңында тота. Аларга арендага бирелә торган уртача биек-

7
Табигать мотивлары һәм нейроннар челтәреннән торган гадәти булмаган пейзаж фонында хатын-кыз сурәте – танылган урам рәссамнары һәм монда яшәүчеләрнең уртак эше.

8
Торак төзелеше концепциясенең тагын бер үзенчәлеге – түбәнге катларның барысы да диярлек коммерция фирмалары өчен яраклаштырылган.

9

9

– Кешеләр рәхәтләнеп кызына яисә агачлар күләгәсендә ял итә алсын өчен, без монда һәр җәй саен ятаклар куябыз, – дип аңлата Анастасия.

лектәге йортлар да, эконом һәм комфорт-класслы шәхси йортлар да кирәчәк.

КОЯШ, ҺАВА ҺӘМ... НОУТБУК

Кояш кыздыра, талгын җил тирә-якка үләннәрнең хуш исен тарата, минем хәйләкәр баш мием аларны шундук диңгез исенә әйләндерә. Әй, ямьле җәй, дип уфтанып куям мин һәм кинәт үземнән берничә метр арырак чын «пляж» идиллиясен күреп алам. Коену костюмы кигән кыз яшел газонга җәймә җәйгән дә, рәхәтләнеп, ноутбугында эшләп утыра. Иннополисның төп скверында мондый күренешләр беркемне дә гаҗәпләндерми, дип сөйли Анастасия.

– Кешеләр рәхәтләнеп кызына яисә агачлар күләгәсендә ял итә алсын өчен, без монда һәр җәй саен ятаклар куябыз, – дип аңлата ул. – Кемдер укый, ә кемдер – үзегез күреп торасыз – иҗади, креатив проектлар эшләү белән шөгыльләнә. Һава торышы яхшы булганда, парк беркайчан да буш тормый. Мондагы атмосфера үзе үк кәефне күтәрә!

Бу шәһәрдә технологияләр шулкадәр күп ки, шунлыктан анда яшәүчеләрнең төп теләге – гармония. Урамында роботлар йөргән Иннополиста табигать белән турыдан-туры элемтә булдыру, аның кочагында ял итү бигрәк тә актуальгә әйләнә. Безнең республика омтылган тагын бер урбанистик тренд – уртак проектлаштыруны, әлбәттә, «киләчәк шәһәрендә» колач җәеп каршы алалар. Иннополиста яшәүчеләр үзләренең барлык теләкләрен архитекторлар һәм урбанистлар белән махсус очрашуларда җиткерә. Шул рәвешле, көне буе утырып эшләүдән алҗыган айтишниклар тормышында спорт, хәл алу, гаилә һәм дуслар белән бергәләп актив ял оештыру урыннары барлыкка килгән. Сүз уңаеннан, нигәдер бер генә фонтан да юк!

Шәхсән минем өчен Иннополисның төп җәмәгать мәйданы белән танышу ярминкәдән башланды. Ташкабак, кыяр, помидор, бакча һәм урман җиләкләре, бал һәм пешерелгән кукуруз – кечкенә, әмма тәртип белән оештырылган базарда якын-тирәдәге авыллардан килгән бакчачылар табигать нигъмәтләрен тәкъдим итә. Бу да халык соравы буенча эшләнә. Тагын берничә метр, һәм табигыйлек трендын бәйрәмнәр өчен барбекю һәм мангаллы зона дәвам итә. Биредә, ачык һавада, шахмат уйнарга, сукмак буйлап йөрергә, эскәмияләргә утырып ял итәргә, кояш формасындагы кызыклы арт-объектта «кайтаваз тыңларга» мөмкин. Ә инде хәрәкәт җитмәүчеләргә бик зур спорт комплексына өстәмә буларак скверда җайланмалар куелган мәйданчык, зур булмаган экстрим-парк һәм скалодром бар.

Парк буенча сәйран кылып йөрүемнең соңгы тукталышы ArtSpace мәдәни үзәге булды. Коллегаларым язганча, «заманча минимализм рухында» эшләнгән үзәк җирле сәнгать сараена әверелергә тиеш. Моның өчен барлык мөмкинлекләр дә бар. Ике мең квадрат метрдан артык мәйданда кафе, кино күрсәтү залы, бию классы һәм театр студиясе, заманча инструментлары һәм 3D-принтеры булган остаханә, робот техникасы һәм модельләштерү залы, буккроссинг зоналы зур коворкинг урын алган. Биредә хәтта заманча тавыш яздыру студиясе дә бар. Анастасия сөйләвенчә, ул бер дә буш тормый – шәһәрнең үзенең музыкаль төркемнәре бар, алар монда репетицияләр үткәрәләр, клиплар өчен көйләр яздыралар.

Балконга чыгам – каршымда парк җәйрәп ята. Әлегә анда кеше юк диярлек, ләкин кичкә таба халык күбәя, музыка яңгырый, шашлык исләре тарала башлый. Әйе, бу шәһәрнең төп җәмәгать мәйданы, әмма ул бердәнбер түгел. Биредә хәтта җир асты юллары да җәмәгать мәйданына әйләнә. Шуларның берсендә (ул университетны спорт комплексы белән тоташтыра) көтмәгәндә генә картиналар күргәзмәсенә юлыктым. Иннополис лицеенда укучы яшь рәссамнар киләчәк шәһәрен ясаган. Аларны нәрсә илһамландыруга төшенү кыен түгел.

УЙЛАНДЫРА ТОРГАН АРХИТЕКТУРА

Җәяүлеләр кичүендә «беспилотник» товар китерүче роботны матур гына уздырып җибәрүен күзәтәм.

– Әйе, без үзебез дә мондый күренешләрне яратабыз. Әле күптән түгел генә Иннополиста яшәүче һәркем диярлек аларны үзенең инстаграмына элә иде! – дип елмая Анастасия.

Мин борылам һәм ровер юлына басам. Ул туктый, үпкәләгәндәй миңа «карый». Ләкин бу шулай тоела гына – чынлыкта ул, мөмкинлекләрне бәяләү өчен, тирә-якны сканлаштыра. Мизгел – һәм робот, «каршылыкны» урап узып, юлын дәвам итә.

Роверны (шулай ук «беспилотник»ны) сынау өчен Иннополис очраклы гына сайланмаган. Монда роверга зыян китерү куркынычы юк диярлек, ә инде аның үз бурычларын үтәү мөмкинлегенә киресенчә бик зур. Кибет һәм җәмәгать куллану ноктaларын торак кварталлар

эчендә урнаштыру роверларга, клиентларының тормышларын җиңеләйтеп, заказларны тиз арада үтәргә ярдәм итә. Бигрәк тә пандемия шартларында. Юллардагы тыныч хәрәкәт һәлакәтләр куркынычын киметә. Бирердә кулланылышка алынган урбанистик трендларның берсе – каршылыксыз мохит, тротуарлар биеклегенә күтәртеп ясалган җәяүлеләр кичүләре кебек үк, ровер өчен теләсә кайсы маршрутны каршылыксыз итә. Һәм ул ишек төбенә килеп басуга, «мин килеп җиттем», дигән хәбәр юллый.

Бер сүз белән әйткәндә, шәһәр югары технологияле казанышларны үзенә «кертергә» мөмкинлек бирә. Кичер, Казаным, мин әлегә синең урамнарыңда мондый күренешләрне күз алдына китерә алмыйм.

– Сез нәрсә! Бездә дә авырлыклар була, – ди Анастасия, минем уйларымны укыгандай. – Әмма мондый очракларда кешеләр ярдәмгә килә. Мәсәлән, кышын кайбер урыннарны кар баса – ровер үтә алмый. Велосипедчылар юллары да салкын вакытта аерым игътибар таләп итә. Консьерж-сервис – шәһәр хезмәте аша кешеләр проблема турында шәһәр мэриясенә хәбәр итә, соңгысы, сүз уңаеннан әйтергә кирәк, әле сервис компаниясе буларак та эшли.

Иннополиста бик актив кешеләр яши, дип сөйли Анастасия. Бүгенге көндә инде йөзләгән берләшмә исәпләнә. Төрле мессенджерларны кулланып, монда яшәүчеләр кызыксынулары буенча гына түгел, көндәлек проблемаларны хәл итү өчен дә берләшә – балалар уйный торган тау ватылганмы, газон корыганмы яисә ишегалдында йөрүче эт авырып киткәнме... Бер сүз белән әйткәндә, шәһәрдәге тормышны үзләре кайгырталар.

Кызык, Карл Маркс буенча ничек була икән бу дип уйга калам: «яшәеш аңны билгелиме» яисә, киресенчә, прогрессив кешеләр үз тирәләрендә шундый ук мохитне булдырамы?

– Бу һәрвакытта да кеше һәм мохитнең үзара тәэсир итешүе нәтиҗәседер, – дип җавап бирә минем соравыма гид. – Бер-беребезгә таба хәрәкәт итәргә кирәк, без нәкъ шуның белән шөгыльләнәбез дә – биредәге берләшмәләрне шәһәрне үстерү эшенә җәлеп итәбез. Сүз уңаеннан, Иннополиста яшәүчеләрнең урбанистика белән кызыксынучылар берләшмәсе бездә иң активлардан санала. Анда катнашучылар бик еш кына үз идеяләре белән уртаклаша, проектларын тәкъдим итә, без инде аларны гамәлгә ашыру өчен акча чыганаклары эзлибез.

Иннополиста яшәүчеләр үзләрен иң бәхетле дип хис итә, диделәр безгә җирле мэриядә. Ил күләмендә алганда. Биредә эшнең нәтиҗәлелеген бәхет индексы белән үлчәргә иялә̆нгәннәр. Бу яктан караганда Иннополиста барысы да шәп дип раслый ВЦИОМ да. Югары технологияләр һәм киләчәк архитектурасы шәһәре буенча сәяхәтемне тәмамлап, мин дә: «Ышанам!» – дип авыз тутырып әйтә алам. Т

10

Биредә «сәпидләрне» ел дәвамында саклау мәсьәләсе шул рәвешле хәл ителгән – урамда булса да, түбә астында аларга кар да, яңгыр да куркыныч түгел.

11

Ровер – юл хәрәкәтендә катнашучы.

12

Җәяүлеләр кичүендә «беспилотник»ның товар китерүче роботны матур гына уздырып җибәрүен күзәтәм.

13

Электромобиль энергия ала.

КАБАТЛАНМАС ЛОФТ

Автор: **Ольга Туманская**

Яңартылган ташландык сәнәгать зонасы андеграунд культура казанышы була аламы? Һичшиксез. Сәүдәгәр Алафузов фабрикасының арт-мәйданга әверелү тарихы – моңа саллы дәлил.

ҮЗЕНӘ ТАРТЫП ТОРА

Мин бер адым алга атлыйм һәм... параллель дөньяга килеп эләгәм. Кирпеч диварлар китап киштәләре артына яшеренгән, бөтен җирдә ниндидер сәер конструкцияләр. Өстәвенә, биредә манекеннар яши икән. Күпме алар биредә? Тулы бер коммуна хасил итәрлек!

– Бу безнең «иске-москы храмы», биредә җиһазлар, арт-объектлар, бизәү элементлары саклана, – ди элек сәүдәгәр Алафузов фабрикасы булган урындагы лофтның оештыручысы һәм хуҗасы Андрей Питулов. – Кайчандыр бу бинада ремонт-механика цехы урнашкан. Ул коточкыч ташландык хәлдә, ишекләре дә, тәрәзәләре дә юк иде. Без аны тәртипкә китердек, һәм нәкъ җиде ел элек нәкъ менә биредә беренче чарабызны үткәрдек. Аннары икенчесен, өченчесен... Шулай әкренләп безнең башка биналарны ремонтлау өчен дә акчабыз пәйда булды.

Фабрика ишегалдында музыка уйный, Тигра кушаматлы маэмай йөгереп йөри. Әмма мин үземне һаман параллель чынбарлыкта итеп тоям. «Алафузов фабрикасы» лофты үзен креатив мәйдан буларак тәкъдим итә. Һәм бу чыннан да шулай. Биредә өстәлләр, эскәмияләр, сәхнә һәм җәйге кухня бар. Әмма мин бу урынны зиннәтле димәс идем. Ул үзенчәлекле һәм тере. Мин аны күзәтәм, ул исә мине җентекләп өйрәнә. Түбәләрдән – манекеннар, граффитидан – йөзләр, ә кирпеч дивардан – зур ак баш карап тора.

– Кайбер чаралар вакытында без бу башка проекция төшерәбез, һәм ул йә күз кыса, йә елмая, – дип аңлата минем кая карап торуымны күргән Андрей Питулов. – Безгә ул очраклы гына килеп эләкте – Спортның су төрләре буенча чемпионаттан соң аның берәүгә дә кирәге калмаган иде. Биредә исә аңа яңа сулыш өрдек, ул лофтның үзенә күрә бер символына әйләнде.

ИҢ ЯҢА ТАРИХ

Без 1860 елда төзелгән бина янынннан барабыз, бу – сәүдәгәр Иван Алафузов туку-күн империясенең беренче бизнес-проекты. Хәер, биредә җитештерү совет хакимияте дәверендә дә, үзгәртеп кору чорында да эшли әле. 2007 елда гына туктап кала. Фабрика ятимләнә, әкренләп җимерелә. Аның иң яңа тарихы 2013 елдан башлана. Ул чакта, Мәскәүнең «Красный Октябрь» фабрикасын яңарту тәҗрибәсеннән илһамланып, танылган клуб промоутеры Андрей Питулов үзенең партнерлары белән Алафузовның элекке сәнәгать зонасын сатып ала.

– Мин туган Казанымда да уникаль интерьерлы, чаралар үткәрү өчен берничә биналы, иҗат һәм һөнәрчелек остаханәләре гөрләгән шундый галәмәт зур креатив мәйдан пәйда булуы турында хыялландым. Галәмдә минем хыялымны ишеттеләр.

Бүген бу урында кабат тормыш кайный – тик бу юлы иҗади тормыш. Алай гына да түгел әле: лофт шәһәрнең туристларны җәлеп итә торган «сәер» урыннарыннан берсенә әйләнгән. Хәзер бу арт-мәйданга, фотога төшерү һәм тарихи ядкәрләр белән хозурланып йөрү өчен, атнасына меңнән артык турист килә.

МАТУР ТУГАНДА

Кирпеч диварлар һәм колонналар, бетон түшәм һәм идән. Өстә – прожекторлар, дивар-

да – бирeдәгеләрнең иң яраткан бизәү алымы һәм күп еллар буе үткәрелгән граффити фестивальләре нәтиҗәсе буларак мураллар...

Мартта биредә җырчы АИГЕЛ концерты уздырылган. Бу зал – трансформер. Аны зур чаралар өчен киңәйтеп, аз кеше җыелганда җыйнакландырып була – бөтенесе дә роликлар ярдәмендә хәрәкәткә китерелә: диджей пульты да, сәхнә дә, диваннар да.

– Лофт шактый кыйбатлы да, һәм менә безнеке кебек гади дә була ала, – ди Андрей Питулов. – Чынлыкта, бинаны тәртипкә китерү – идәнгә бетон җәю, батареялар кую өчен һәр квадрат метрга 2 мең сум гына кертү дә җитәргә мөмкин.

Шуның белән бергә, бу лофтның бөтен биналары төрле һәм үзенең кабатланмас өслүбенә ия. Әлеге өслүб исә, Андрей әйтүенчә, дизайнерлар проектларында түгел, ә стихияле рәвештә туган. Һәр залның үзенең уникаль тарихы бар. Берсенең идәненә ламинат җәелгән. Анда Бразилиядәге популяр бию стиле-зук фестивале үткәрелгән икән. Башта оештыручыларга бина ошый – идәне генә яраксызга чыгарыла. Андрей аларның сүзенә колак сала, һәм аренда акчасының бер өлеше идән алыштыруга тотыла. Шул рәвешле, фабрикада биюле чаралар үткәрү өчен дә бер дигән зал барлыкка килә.

БЕРЕНЧЕ ҺӘМ ИҢ ЗУР

Әлегә «Алафузов фабрикасы» лофты республикадагы иң беренче генә түгел, иң зур яңартылган сәнәгать зонасы булып кала бирә. Биредә 7200 квадрат метр җир һәм якынча шуның кадәр үк бина мәйданнары бар. Эш бер генә көнгә дә тукталып тормый. Әлегә биналарның өчтән бере генә үзләштерелгән.

– Беренче сезонда – күмер, аннары утын яктык. Хәзер җылылыкны һәм кайнар суны күршедәге пар казаннары бинасыннан алабыз. Электриканы, канализацияне, башка коммуникацияләрне алыштырдык. Түбәне яптык. Нигезне ныгыттык һәм гидроизоляциялədек – элеккеге Алафузов фабрикасыннан фундамент һәм диварлар гына калуы аңлашыладыр инде. Торгызу эшләренең бер өлешен төгәлләдек.

Яңарту процессында иң катлаулысы нәрсә булу белән кызыксынам. Әмма Андрей соравымны аңламый: төзелешкә кагылышлы теләсә нинди проблемаларны хәл итеп була. Иң катлаулысы – инвестор табу. Бездә креатив теманы бизнес буларак аңлап җиткермиләр әле. Хәер, Питуловның планнары хәттин ашкан.

– Әгәр берничә кат өстәп төзесәң, мәйданны 12,5 мең квадрат метрга җиткерергә мөмкин. Тик биредә ресторан, кафе, бер-ике бар ачу өчен болай да урын җитәрлек. Аерым җәмәгать мәйданнары һәм коворкинглар оештыру мөмкинлеге дә бар. Мансардада 24 фатирлык коливинг төзеп, иҗат белән шөгыльләнүче яшьләргә арендага бирергә була. Бу лофтның мөмкинлекләре чиксез.

1 Элек сәүдәгәр Алафузов фабрикасы булган урындагы лофтның оештыручысы һәм хуҗасы Андрей Питулов.

ЫК БУЕНА КИЛ ӘЛЕ, ГҮЗӘЛЛЕКНЕ КҮР ӘЛЕ...

Автор: **Катерина Котова**

Тын елга, ямь-яшел үзән һәм калкулыклар – әлеге гүзәллекне авыл манзарасы тулыландыра. Шунда ук ерак офыкка сузылган заманча яр буе күзне иркәли. Архитектура һәм урбанистиканың соңгы сүзе буенча ясалганы әллә каян күренеп тора. Юк, бу берәр мегаполис тирәсе түгел, бу – Мөслим!

РӘХӘТ ЭССЕЛЕК

Хәтта гайре табигый эсселек тә биредә сизелми диярлек. Уңайлы агач ятакта ярты сәгать кызынып ятканнан соң көньякта ял итеп кайткандай буласың. Хәер, эссе кояш нурларыннан да ышыкланырга була – менә инде мин дулкынсыман чатыр күләгәсендә елга һавасын сулап кинәнәм, үзем каршы яктагы матурлыкны күзәтәм.

Кояшлы аланда уңайлы ял өчен барысы да бар. Бу урында яр буе ташлар белән махсус ныгытылган, ерак түгел генә машина кую урыны, бәдрәф... Хәер, монда бернинди дә «евроремонт» юк. Яр буе тирәлек рельефына кушылып китә, аны бозмый, елганың табигый матурлыгына басым ясагандай, аңа яраша. Шул ук вакытта барысы да заманча! «Бөтен Россия менә шундый була алыр иде!» – Татарстандагы яр буйлары турында язган мәкаләсенә танылган урбан-блогер Илья Варламов әнә шундый бәһа бирде. басым куйган.

ЯЛ УРЫНЫНА ӘЙЛӘНГӘН ЧҮПЛЕК

Кайчандыр бу чүп-чар тулган ташландык урын булган. Аяк баскан саен ишелгән Ык яры, куе чытырман, ләмләнгән үзән – болар барысы да кешеләргә елга буена төшәргә комачаулаган.

Фотолар «ТР шәһәрләрен үстерү институты» фонды тарафыннан бирелде

Үзгәрешләр 2016 елда башлана. Елга үзәнен чистарталар, суның биеклеген карап тору һәм язгы су басулардан саклану өчен хәтта плотина да төзиләр. Яр буена мең ярым агач һәм куак утырталар. 18 километрга сузылган җәяүлеләр һәм велосипедчылар сукмаклары Ык елгасы һәм аның элеккеге үзәнендәге күлләр янындагы кечкенә паркларны берләштерә. Нәтиҗәдә төзекләндерелгән җәмәгать мәйданының зурлыгы 100 гектарга җитә. Шуның 30 гектары «Кояшлы Ык» яр буена керә. Калган җирләр аның дәвамына – «Киләчәк» паркына карый. Авылдагы мондый ял урынына һәр шәһәр кешесе кызыгырлык, шуңа күрә дә «Кояшлы Ык» якын-тирәдәге кала халкы өчен ял көне маршрутына кертелгән.

Сүз уңаеннан, «Архдесант» архитекторлар командасы, бу урынны күргә үк, биредә ландшафтлы парк ясарга кирәк, дигән фикергә килә. Яр буе проектының башлангыч этабының әйдәп баручы архитекторы Юлия Хәйруллина, безне иң беренче территориянең зурлыгы хәйран калдырды, дип сөйли.

– Ык елгасының матур яр буенда йөргәндә, күз алдыма табигый материаллардан ясалган арт-скульптуралары һәм аларны үзара тоташтырган җәяүлеләр маршрутлары булган Никола-Ленивец паркы манзарасы килеп басты. Монда, Мөслимдә, ярның буеннан-буена ландшафтның төрле формалары һәм үсемлекләрнең күп төрләре очрый, алар Ык елгасы яр буеның кабатланмас дөньясын хасил итә. Гаҗәеп киңлекләр иркенлек, җиңеллек, табигать белән кушылу, аралашу тойгысы уята, мин биредә шул хисләрне кичердем. Минем чыннан да монда каласым килде. Әлеге тойгыны җуймаска, табигый тирәлеккә бик сак карарга кирәклегенә төшендем. Һәм без чыннан да моңа ирештек. Сүз уңаеннан, Мөслим районы башлыгы Рамил Муллин һәр эшебезне диярлек хуплап торды. Шунысын да әйтергә кирәк: «Кояшлы Ык»та гамәлгә ашырылган кайбер кызыклы идеяләр алдан ук аның тарафыннан тәкъдим ителгән иде.

КЫЗЫКЛЫ ТАРИХ

Бик зур ташлар һәм кайчандыр көчле җил аударган агачлар арасында йөрим. Стоун-парктагы элеккеге «коры сазлык» урынында тарих үзе арт-объект булып тора. Һәм менә мин инде гүя плейстоцен чорында басып торам. Монда хәтта борынгы хайваннар да очрый! Чынлап менә! Алар арасында, мөгаен, иң кызыклысы Фестиваль аланындадыр – бик зур мөгезборын кыяфәтендәге балалар мәйданчыгы турында әйтүем.

– Мөслимгә беренче тапкыр килгәч мин, «Монда хәтта йонлач мөгезборыннар яшәгән», дигән сүзләрне ишеткәч, бик гаҗәпләнгән идем, – дип сөйли Юлия Хәйруллина, әлеге объектның ничек пәйда булуы турында сүз чыккач. – Бу турыда күбрәк белү өчен җирле музейга кагылырга булдык. Анда безгә уникаль табылдыкларны күрсәтте: борынгы заманнарда әлеге тирәләрдә яшәгән хайван, балык һәм кошларның ташка әверелгән калдыкларын.

[1] Никола-Ленивец – Европаның иң зур арт-паркы, Калуга өлкәсендәге кечкенә бер авыл тирәли урнашкан. Иҗади тәҗрибәләр өчен ачылган һәм табигый ландшафтка яраштырып урнаштырылган заманча сәнгать әсәрләре белән таң калдыра.

Шул рәвешле археология сукмагы идеясе туды, без аны ташка әверелгән хайван сыннары белән бизәргә уйладык. Сукмак буйлап йөргәндә, без тарих белән төрле тойгылар аша танышабыз: утлап йөргән мөгезборын һәм мамонтлар көтүенә юлыгабыз, дала кошлары көтүен күрәбез, җир өстендәге эзләргә басабыз һәм төрле инсталляцияләрдән тарих турында укыйбыз...

Балалар мәйданчыгында тарих темасы тагын ике зонада дәвам итә: беренчесе – реликт урман рәвешендәге үрмәләү лабиринты, анда рәхәтләнеп качыш уйнап була; икенчесе – учагы, балык ятьмәләре һәм куышы да булган кыргый кеше почмагы. Менә шул рәвешле, уйный-уйный, балалар туган төбәкләренең тарихы белән таныша ала. Әлеге гадәти булмаган балалар мәйданчыгының эскизлары да уникаль. Алар архитекторлар тарафыннан кулдан ясалган, ә инде әлеге идеяләрне гамәлгә ашыруны җирле остакуллар һәм җитештерүчеләр башкарган. Бүген бу яр буендагы иң матур урыннардан берсе.

Сүз уңаеннан, әлеге объектларны ничек урнаштырырга кирәклеген табигать үзе әйтеп тора. Юлия сүзләренә караганда, язгы ташу вакытында елганың киңәюе яр буен планлаштыруда, атап әйткәндә, маршрутларны һәм мәйданчыкларны урнаштыруда билгеле бер кагыйдәләрне үтәүне таләп итә. Мәсәлән, археология паркы булган «коры сазлык» өчен су баса торган зона сайлана... Хәзер ташу вакытында елганың элеккеге үзәнендә су күтәрелә һәм «сазлык» су белән тула, үзгәрә, бөтенләй башка төрлегә әйләнә.

БЕРЕНЧЕ ОЧРАШУДАН ГАИЛӘ ТРАДИЦИЯЛӘРЕНӘ КАДӘР

Биредән искиткеч гүзәл манзара ачыла. Яр буена көньяк-көнчыгыштан караганда мәһабәт Ык елгасы җәйрәп ята, ә икенче як ярда киң яшел болыннар җәелгән, чын таулар күренә! Кергәндә үк каршы алган хайван һәм кош силуэтлары төшерелгән стелалар кунакны «табигать» дулкынына җайлый. Мин исә таганга уңайлап урнашып Мөслим табигате гүзәллеген күзәтүемне дәвам итәм. Таганда ике кешегә утыру җайлыйрактыр. Янәшәмдәгесенә утырган пар минем белән тулысынча килешәдер, дип уйлыйм.

Сүз уңаеннан, биредә бар нәрсә романтика белән сугарылган. Әйләнә-тирәсен чәчәк түтәлләре бизәгән эскәмияләр, яңа өйләнешүчеләр үз иткән бөгелмәле күперләр, ясалма күл, аңлашуларны, матур фотосессияләрне көтеп торган мәхәббәт утравы, ял итү өчен көймә һәм катамараннар... «Кояшлы Ык»та беренче очрашу өчен дә, күркәм туй өчен дә барысы да бар. Гаилә традицияләре өчен дә...

– Моннан ерак түгел генә парк бар, анда һәр гаилә үз агачын утырта. Без дә үзебезнекен утырттык. Хәзер оныкларым белән бергә агачыбызга су сибәбез, аның ничек үскәнен карап торабыз, – ди җәмәгать эшлеклесе, Мөслим районының мактаулы гражданы Моряк Йосыпов.

Проектның генераль подрядчысы – «Автострой» җитештерү-коммерция фирмасы ҖЧҖ. Әмма, Моряк Йосыпов сөйләвенчә, яр буен төзекләндерүдә төзүчеләр белән бергә бистәдә яшәүче һәркем – олысы да, кечесе дә катнашкан. Укучылар, мәсәлән, яшелләндерү эшләрендә булышкан – үсентеләр утыртканнар, су сипкәннәр. Әлеге матурлыкны булдыруга һәркем диярлек үз өлешен керткән. Шуңа күрә дә Мөслимдә вандаллык юк, чөнки кайчандыр үз хезмәтең белән төзегәнне бозар-җимерер өчен акылсыз булырга кирәк. Киресенчә, яшьләр яңа яр буен тагын да кызыклырак итәр өчен тырыша – катамаран һәм көймәләрне прокатка бирү нәкъ менә алар көче белән оештырылган.

СӘНГАТЬ БЕРЛӘШТЕРӘ

Ботаклардан ясалган зур йомгак, бөтенләй тропик булмаган Мөслимдә «үсеп чыккан» алып кактус гаиләсе, агачтай биек борчак кузагы, гигант саксофон... Ә никадәр футуристик сын бар биредә! Аларны караган саен карыйсы килеп тора. Һәм һәр җәй саен арт-объектлар коллекциясе тулылана барачак. Кайчандыр Юлия Хәйруллина күз алдына китергән Никола-Ленивец паркы күренешләре чынга ашкан диярсең.

Барысы да моннан ике ел элек башланган. Ул чакта бирегә ун «КАМАЗ» тал чыбыгы кайтарталар. Дүртесе дизайнер һәм рәссамнар өчен мастер-классларга тотыла. Калган алтысы «Лэнд-Арт» халыкара фестивалендә файдаланыла. Ул вакытта Мөслимдәге матурлыкны илнең төрле почмакларыннан һәм хәтта чит илләрдән килгән 17 команда иҗат итә. Быел июньдә биредә фестивальнең икенчесе оештырыла. Әлеге чараның асылын аның исеме үк әй-

теп тора, чөнки лэнд-арт – табигый ландшафт белән тыгыз бәйләнештәге әсәрләр тудыру сәнгате. Бүген «Кояшлы Ык»ны фестивальдә катнашучыларның эшләре бизәп тора. Һәм, әйтергә кирәк, алар Мөслимгә барып кайту өчен менә дигән сәбәп тә.

– Безнең гаилә өчен бу фестиваль кызыклы вакыйгага әйләнде, – дип сөйли Моряк Шәйхрахман улы. – Беренче «Лэнд-Арт»ка испаннар командасы килгән иде. Кызыбыз белән оныгыбыз аларның ярдәмчеләре булды. Шуннан бирле алар үзара аралашып, языштып тордылар. Ә быелгы җәйдә тагын Мөслимдә очраштылар! Мин үзем дә испан телендә алты җөмлә өйрәндем, махсус, аларны каршы алу өчен. Шулай итеп, Испаниядә безнең дусларыбыз пәйда булды – «Кояшлы Ык» дуслаштыра, берләштерә!

Шуңа күрә дә нәкъ менә «Кояшлы Ык»ның Бөтенроссия авыл Сабан туен үткәрү урыны итеп сайлануы һич тә гаҗәп түгел.

ИҢ ШӘП САБАН ТУЕ

Илнең 45 төбәгеннән биш йөздән артык делегат һәм утыз меңгә якын кунак – аларның барысын да Мөслим һәм «Кояшлы Ык» кабул итте. Мөслимдәге бәйрәм турында яңалыкларда «Барысыннан да уздырган Сабан туе» кебегрәк башисемнәр белән язып чыктылар. Кунакларның, катнашучыларның фикерләре дә шундыйрак иде.

Федераль Сабан туена әзерлек ике ел дәвамында бара. Һәм менә нәтиҗәсе – яр буеның Фестиваль аланында биш мең тамашачыга исәпләнгән амфитеатрлы гаять зур мәйдан, ат чабышлары өчен ипподром, учак, төрле уеннар өчен аерым урыннар әзер. Алар барысы да мөслимнәргә «мирас» булып кала. Тагын бассейнны, физкультура белән шөгыльләнү мәйданчыкларын һәм югарыда соклануымны белдергән 18 километрлы җәяүлеләр һәм велосипедчылар сукмакларын санап китәргә кирәк. Кыскасы, актив, спортка битараф булмаган һәм сәламәт яшәү рәвеше алып баручы һәр кешенең хыялы – сезнең каршыгызда!

Монда тормыш гөрли! Яр буен күзәтеп йөргәндә бала арбасы тарткан яшь әниләрне, йөгерүче, велосипедта йөрүче, парлап атлаучы яшьләрне, гаиләләрне, бергәләп ял итүчеләрне очратам. Кешеләр кайткан кунакларны да монда алып килә – матурлыкны күрсәтергә, шаккатырырга... Яр буе тарту көченә ия урынга әверелгәндәй тоела.

– Әйе, «Кояшлы Ык» мөслимнәрнең яшәү рәвешен үзгәртте, – дип раслый минем фикерләрне Мөслим муниципаль районының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы Илшат Җаббаров. – Ләкин минут эчендә генә түгел. Ни дисәң дә, бездә күбрәк авыл халкы яши, алар парк һәм скверларда ял итеп йөрергә ияләнмәгән. Шуңа күрә баштарак бәйрәм һәм фестивальләр үткәреп халыкны бергә тарттык. Ә хәзер инде тырышырга да кирәкми – үзләре рәхәтләнеп киләләр, йөриләр. Без ешрак аралаша, очраша, ял итә башладык.

Хәзерге вакытта оештырыла торган бәйрәмнәр районга туристларны җәлеп итәргә мөмкинлек бирде, дип саный Илшат Җаббаров. Беренче тәҗрибә – «Лэнд-Арт» фестивале – өч меңнән артык кунакны сыйдырган. Һәм бу яңа яр буе зонасында гына мөмкин булган. Өстәвенә, ландшафтлы парк җылы фасылда гына актив файдаланылып калмый, әлеге территорияне үстерү кысаларында монда чаңгы базасы да салынган. Шуңа күрә яр буендагы җәяүлеләр сукмагы кыш көне чаңгы трассасына әверелә. Мөслимнәр әлеге идеяне күтәреп алганнар, чаңгы шуарга теләүчеләр аз түгел икән.

– Гүзәллек дөньяны үзгәртә, – ди Илшат Җаббаров. – Һәм бүген аны күрү өчен әллә кая барырга кирәкми, туган ягыбыз Мөслимдә дә рәхәтләнеп хозурланырга була. Балаларыбыз инде бүген үк матурлыкны күреп үсә. Яңа, заманча җәмәгать мәйданнары пәйда булу белән Мөслим үзе дә башкача үсеш ала. Һәм бу, киләчәгебез искиткеч гүзәл булыр, дигән өмет уята.

ГАСЫРЛАРГА АШКАН МАНАРА

Югала барган ядкәрне ничек саклап калырга

Автор: **Алсу Троицкая**

Татарстандагы иң иске таш мәчет авыл үзәгендә, калкурак урында тора, һәм бу шулай булырга тиеш тә. Аның тыйнак матурлыгын күрергә теләп бирегә бик ераклардан киләләр. Ә җирле халык исә авылның йөрәге булган мәчетнең, йөз ел онытылып ятканнан соң, яңадан торгызылуына ихлас куана.

Объект: Таш мәчет
Урыны: Татарстан Республикасы Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылы
Төзелгән елы: 1769
Реставрация еллары: 2018–2020

Ә мәчет чыннан да бик матур. Ак таштан салынган Аллаһ йортының очлы чатыр түбәле төз манарасы, мәһабәт ярымай... Бернинди дә артык нәрсә юк: барысы да тыйнак вә җыйнак.

– Тарихчылар, архитекторлар мәчетебезне дини архитектураның тиңсез һәйкәле дип атый. Ә безнең өчен ул – авылыбызның җаны, – дип каршы ала ишек төбендә Наилә Гәрәева. – Бу авыл бик бай тарихлы. Татарстанның иң борынгы таш мәчете, күпләр уйлаганча, Казанда түгел, ә нәкъ менә биредә урнашкан. Безгә исә аны кереп күрү бәхете тиде, – дип пышылдап сөйләүгә күчә Наилә ханым. – Матур авыл, матур кешеләр, матур мәчет...

КҮРЕНЕКЛЕ ҺӘМ ЮМАРТ ЗАТ

...Кайчандыр Түбән Бәрәскә авылында сәүдәгәрләр династиясенә нигез салучы Ибраһим Борнаев яшәгән, әлеге нәсел вәкилләре соңыннан Казанның атаклы Борнай мәчетен салдырган. Нәкъ менә Ибраһим патшабикә Екатерина II дән туган авылында ике катлы таш мәчет төзергә рөхсәт алуга ирешкән.

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ (КАЗАНДА БЕР ЕЛ СОҢРАК ТӨЗЕЛГӘН МӘРҖАНИ МӘЧЕТЕ ШУШЫ ДИН ӘҺЕЛЕ ИСЕМЕН ЙӨРТӘ– РЕД.ИСК.) ҮЗ ХЕЗМӘТЛӘРЕНЕҢ БЕРСЕНДӘ: «Авыл уртасындагы таш мәчетне шул авыл кешесе Ибраһим бине Йосыф бине Әснәй бине Исәнкол бине Борнагыл 1183 (1769) ел азагында бик нык итеп, баскычларын чуеннан ясатып салдырган», – дип яза.

ҖИМЕРЕЛМӘС НЫК

– Таш манараны җимереп төшерү өчен, совет чорында тракторлар һәм авыр техниканы эшкә җигәргә туры килгән, дип сөйлиләр, – ди Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы Аида Фатыйхова. – Әмма барыбер борынгылар өйгән корылманы сүтә алмыйлар: кирпечләр берәм-берәм каерылмый, җимерергә генә кала. Ярый әле әлеге файдасыз хезмәтне туктатырга тәкъдим иткән берәү табыла. Шулай итеп, мәчет бинасының төп өлеше исән кала. Төзүчеләр, бинаның ныклыгын арттыру өчен,

Автор фотолары

измәгә чи йомырка кушкан икән, аны исә Борнаевларның кирпеч заводына авыл халкы китереп торган.

Татарстанның иң борынгы таш мәчетен реставрацияләү турындагы уйны Түбән Бәрәскә халкы күп еллар күңелендә йөрткән.

– Уйладык-уйладык та республика Президентына хат яздык, – дип сөйли Аида Фатыйхова, реставрациянең барлык этапларын сурәтләгән фотоларны күрсәтә-күрсәтә. – Һәм 2018 елның ноябрендә дәүләт белән шәхси партнерлык шартларында эш башланды. Реставрация өчен кирәк булган барлык әйберләрне «Ленин исемендәге завод» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы директоры Илгиз Хәйруллин һәм аның урынбасары Азат Мөхәммәтҗанов гамәлгә куйган «1769 елгы мәчет» хәйрия фонды аша сатып алдык һәм тикшереп-хисаплап тордык. Мәчетне торгызу тәкъдимен нәкъ менә алар күтәреп чыкты, республика җитәкчелеге белән бергә реставрация эшләре өчен 52 миллион сум акча тупланды, моның күпчелек өлеше – иганәчеләр ярдәме.

Мәчетне торгызу эшен Татарстан Президенты каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды үз өстенә ала. Реставрация

1

2



2018 елның дүртенче кварталында башлана һәм былтыр тәмамлана. «Строй Мир Реконструкция» төзелеш компаниясе подрядчы оешма була.

Кызганычка, реставрация башланган вакытка мәчет инде бик зур үзгәрешләр кичерергә өлгерә, алар материалларның табигый искерү процесслары белән генә түгел, ә совет чорындагы динне кысрыклау белән дә бәйле. 1930 нчы елларда ябылган мәчет озак вакытлар склад, кибет һәм клуб итеп кулланыла, ә аннан соң бөтенләй ташландык хәлдә кала. Нәтиҗәдә, манара юкка чыга, икенче катта эчке баскычлы манара дивары, төп бинада һәм михрабта карнизнең дәвамы булган икенче кат көймәләре җимерелеп бетә.

Әмма бинаның төп диварлары, тәрәзкөймәләре белән бергә аскы кат, ярымтүгәрәк формадагы михраб урыны, беренче яруста манара дивары сакланып кала. Мәчетнең югалган фрагментларын проектлаганда, XVIII гасыр һәйкәлләренә пропорциональ һәм чагыштырма анализ ясала.



1

Манарадан авылның 1992 елда агачтан салынган икенче мәчете күренеп тора.

2

Өч еллык реставрация этапларын сурәтләгән фоторәсемнәр бүген мәчетнең беренче залына куелган.

3

Бу ишек артында – манарага менү баскычы.

4

Манарага менү баскычы.

Җәмигъ мәчетенең фотосурәтләре сакланмаган, ул чордагы дини биналарның тарихи рәсемнәре белән чагыштырып эшләргә туры килгән. Әйтик, реставрация эшләрен башлаган вакытта мәчет туры түшәмле була, совет чорында шулай итеп үзгәрткәннәр. Ә чынлыкта башта түшәм кирпечтән ясалган зур гөмбәздән гыйбарәт булган. Төзекләндергәндә, әнә шулай итеп ясап та куялар.

КҮМӘК ЭШ ТАУ КҮЧЕРӘ

– Таш мәчетләрнең архитектурасы ул вакыттагы рус архитектурасы йогынтысында формалашкан, – дип аңлатма бирә Түбән Бәрәскәдәге мәчетне реставрацияләү кураторы, махсус чакырып китерелгән архитектор Светлана Алаева. – Бу гыйбадәтханә Казандагы әл-Мәрҗани мәчетенә бик охшаш. Ул авылның бу өлешенең әлеге ачык җирендәге тигезсез рельефында искиткеч мәһабәт булып күренә. Ул чорда, минемчә, мәчет мәдәни-агарту үзәкләреннән берсе булгандыр. Биредә Аллаһыга гыйбадәт кылганнар һәм дингә хезмәт итәргә өйрәнгәннәр. Заманында Түбән Бәрәскәдәге таш мәчетнең даны бик еракларга таралган була.

Реставраторлар бирегә беренче тапкыр килгәндә, коточкыч манзарага юлыга, сакланып калган диварларның кайчандыр гыйбадәтханә бинасы булуын бары тик берән-сәрән архитектура элементлары гына расльй.

– Фасадлардагы ярыклар, җимерек кәрнизләр... Бу гаҗәп тә түгел – инде ничә дәвер узган. Әмма безнең белән йөргән Илгиз Хәйруллин мәчет тарихы турында шулкадәр илһамланып сөйләде, аны реставрацияләү идеясе белән шулкадәр ихлас яна ки!.. Ә сүзләрендәге әрнү исә әйтеп бетергесез! Аны тыңлаганда, бу объектка алыначакмын дип, үзем өчен шундук карар кылдым. Бүген Татарстанның иң борынгы таш мәчете шушы рәвештә балкып торуда, гыйбадәтханәнең башлангыч кыяфәтенә ни дәрәҗәдә якын булуында, әлбәттә, реставрация ниятен локомотив кебек алга сөйрәгән авыл халкының өлеше зур. Төзекләндерүдән соң кешеләр мәчет эчендә үзләрен уңайлы хис итсен, монда намаз укырга, аралашырга һәм төрле авыл мәсьәләләре хакында фикер алышырга килсеннәр иде, дип теләдек. Минемчә, теләкниятләребез барысы да чынга ашты, – дип, үзенең тәэсирләре белән уртаклашты Светлана Алаева.



5 Гыйбадәт залы гөмбәзе.

*Наилә Гәрәева – Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты һәм режиссеры Рафкать Бикчәнтәевнең тол хатыны, театрның хәзерге баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәевнең әнисе – ред.

Автор фотолары

ЗАМАНЧА МӘКТӘП

Автор: **Алсу Троицкая**

Яңа мәгариф мәйданында педагогик процесска гына игътибар бирү җитми. Мәктәптә бөтен нәрсә: архитектура да, интерьер да, инженерлык һәм иминлек системалары да иң югары дәрәҗәдә булырга тиеш.

Объект: «Советлар Союзы Герое Г. К. Камалиев исемендәге күппрофильле лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
Локация: Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Яңа Шигали авылы «Царево утары» торак комплексы
Төзелгән елы: 2020

«Царево утары» торак комплексында 1224 балага исәпләнгән күппрофильле лицей бинасы «Торак һәм шәһәр мохите» милли программасы нәтиҗәсендә салынган. Төзелешнең подрядчысы – «Акташ» ҖЧҖ.

Бирегә уку сыйныфларына гына түгел, бәлки мәктәп балалары тормышында шулай ук мөһим роль уйнаган җәмәгать мәйданнарына да зур игътибар бирелгән. Тематик блокларга бүленгән биналар эчендә – ике атриум. 500 урынлык актлар залы, зур ашханә. Коридорларда укучылар өчен уңайлы ял зоналары җиһазландырылган.

Әле тагын ике бассейн да бар, алардан берсендә – 25 метрлысында – ярышлар үткәрергә була. Спорт белән шөгыльләнер өчен мөмкинлекләр күп: душ һәм чишенү бүлмәләре булган ике спорт залы, мәктәп ишегалдында – футбол кыры, хоккей, баскетбол һәм волейбол мәйданчыклары, тренажерлар комплексы...

Күп төрле заманча җайланмалар белән җиһазландырылган кабинетлар дисциплиналар, технологияләрне тирәнтен өйрәнү һәм төрле-төрле күнекмәләр үзләштерү мөмкинлеген бирә. Хәтта стоматология кабинеты булган үзләренең медицина блогы да, шулай ук типография җиһазлары куелган һәм видеостудияле медиаүзәкләре дә бар.





Атриум.

Мөмкинлекләре чикле укучыларны күтәрү җайланмасы.

1
Йорт эшләре һәм кулинария кабинеты.

2
Химия кабинеты.

3
Башлангыч мәктәп сыйныфы.

4
Медиаүзәк.

5
Спортзал.

6
Ашханә.

7
Актлар залы.





Барлык сыйныфлар интерактив такта, укытучы өчен компьютер һәм күп функцияле җайланма белән җиһазландырылган.

Интерьер һәм фасадлар якты төсләргә буялган.

АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ДИЗАЙН

– Мәйданнар мәктәпнең бөтен җирендә бик якты булырлык итеп планлаштырылган. Проект типлаштырылган булса да, махсуслашкан зоналар мөмкин булганча киңәйтелгән.

– Мәктәптә 11 керү һәм чыгу урыны бар: балалар урамга теләсә кайсы ишектән чыга ала.

– Мәктәпнең бөтен территориясе периметр буенча койма белән әйләндереп алынган, капкалар, ишекләр һәм бина эчендәге блоклар еракт ан торып идарә ителәторган контроль системалары белән җиһазландырылган. Ике керү юлында металл детекторларының дүрт кысасы, сумка һәм портфельләрне яктыртып карау өчен рентген җайланмалары урнаштырылган, кул металлэзләгечләре бар. Мәктәп балаларының иминлеге беренче урында тора.

– Рекреацияләр күпфункцияле: анда балалар утырып ял итә һәм төрле өстәл уеннары уйный ала. Башлангыч сыйныфлар блогында кабинетлардан тыш озынайтылган көн төркеме өчен уен бүлмәләре һәм ике йокы бүлмәсе дә бар. – Өлкән һәм башлангыч сыйныф укучылары төрле блокларда укый, әмма уртак мәйданнар – ашханә, китапханә, актлар залы, бассейннар, спорт заллары һәркемгә хезмәт күрсәтергә җайланган.

– Лицейда бик якты, яшел үсемлекләр күп.

– Мөмкинлеге чикләнгән балалар өчен лифтлар, шулай ук бассейнда гидравлик күтәртү җайланмалары бар.

Лицей директоры **РифкатьТибаев** соңгы елларда республикада мондый мәктәпләрнең һаман арта баруын искәртә:

– Аларны салу идеясе шунда: алдынгы белем бирү методикалары өчен мәйдан булдырып, мондый мәктәпләрнең гайре табигый булмавын дәлилләү. Киресенчә, бөтен мәктәп шундый һәм хәтта яхшырак та була ала, дигән фикерне ныгыту. Һәм безнең балаларның нәкъ менә шундый мәктәптә укыйсы киләдер, дип уйларга җөрьәт итәм.

СҮЗ УҢАЕННАН

2021 елда Татарстанда «Торак һәм шәһәр мохите», «Демография» һәм «Мәгариф» милли проектларын гамәлгә ашыру кысаларында 16 балалар бакчасы һәм ике мәктәп төзелә. Әлеге максатка 2,9 миллиард сум акча бүленгән.

КАЗАН ҮЗӘГЕНДӘГЕ АФРИКА САВАННАСЫ

Автор: **Алсу Троицкая**

Объект: Казан зообoтаника бакчасындагы «Африка. Замбези елгасы» экспозициясе
Локация: Казан шәһәре
Төзелеш еллары: 2015–2019

«Замбези елгасы» – ике гасырлык тарихы булган Казан зообoтаника бакчасы территориясендә гамәлгә ашырылган беренче колачлы проект. Киләчәктә иске зоопарк территориясе дә реконструкцияләнәчәк, анда «Врангель утравы», «Уссури елгасы, «Байкал күле» пәйда булачак, Вахитов мәйданы янәшәсендә исә зоологлар «Амазонка елгасын» планлаштыра. Әлегә исә Кабан күле ярындагы Африка саваннасы буйлап сәйран кылыйк.

МАЙМЫЛ ҺӘМ ФИТНЕС

Өч төсле танаулы Бразза маймыллары бирегә килүчеләрне яннарына магниттай тартып тора. Алар исә кешеләргә игътибар да итми – гел хәрәкәттә. Ятьмә лабиринтта шаяралар, ашыга-ашыга киртәләп алынган улакка төшеп, азык алалар да, кирегә – эчке вольерга йөгерәләр. Һәм кинәт туктыйлар да, бер урында катып калган сынга әйләнәләр... Маймылларның Казан «джунглиеннан» бик канәгать булуы күренеп тора.

Фото: Сергей Хлюпин

– Алар бередә кышын да йөгереп йөрде, – дип сөйли җилкәсенә улын утырткан ир-ат. – Урамда 23 градус салкын, авыздан пар чыга, алар исә һаман чабыша. Аннары рәхәтләнеп кышкы кояшта җылынып утыралар. Үзем күрдем.

Зоопаркның яңа мәйданчыгында Африка хайваннарының яшәү территориясе җиде гектарга тәңгәл. «Замбези елгасының» мәйданы шундый. Һәм бернинди дә төрмә рәшәткәләре юк бередә...

МИН ШУЛАЙ ЯШӘСӘММЕ...

«Зоопаркларны күралмыйм!», «Мескен җанварлар!», «Иреккә, барысын да иреккә!», «Карый алмыйм мин моңа!» – безнең зоопаркларның күбесе шундый реакция тудыра. Карасу бетон диварлар, кысан вольерлар, корыч чыбык артында – боек күзле сүлпән хайваннар. Б-р-р...

Бәхеткә, «Замбези елгасы» андый түгел. Яңа зоопарк проекты 2014 елда Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме белән гамәлгә ашырыла башлаган.

– Иң мөһиме, зоопарктагы хайваннар рәшәткә артында утырырга тиеш дигән стереотиптан котылдык, – ди Казан зооботаника бакчасы директоры урынбасары **Александр Малёв**. – Шул ук вакытта бирегә килүчеләрнең, хезмәткәрләрнең һәм хайваннарның үзләренең дә иминлеген кайгырту беренче урында тора.

Концепцияне тормышка ашыру территорияне чүп-чардан чистартудан башланган. Зооботаника бакчасы җирләрендә күп еллар буе чын чүплек тупланып килгән. Хәер, нәкъ менә шул чүп тауларыннан куркып, территориягә кызыгучы булмаган да инде. Еллар буена җыелган чүп-чарны меңләгән «КАМАЗ» белән ташып түккәннәр.

Иң кызыгы шуннан соң башланган. Африка экспозициясе өчен хайваннар сайлауга керешкәннәр: филләр, жирафлар, бегемот, гориллалар, ак мөгезборыннар, зебралар, тимсахлар, арысланнар, гепардлар, антилопалар... «Замбези елгасы» концепциясен төзүгә консультант сыйфатында Брно шәһәре зоопаркының иң карт хезмәткәрләреннән берсе, Прага зоопаркының элекке директоры, танылган териолог һәм зоопарклар эше белгече доктор Богумил Кралны җәлеп иткәннәр.

Күп кыенлыкны җиңәргә туры килә. Чөнки зоологларның да, проектчыларның да, төзүчеләрнең дә мондый концепцияне гамәлгә ашыру тәҗрибәсе булмый.

– Без кайвакыт үзебезнең ялгышлардан сабак алдык, – ди Александр Малёв. – Мәсәлән,





шимпанзе өчен вольер төзибез. Инде барысы да әзер кебек. Һәм шул вакытта программаның шимпанзелар буенча координаторы Том де Йонг безгә әллә никадәр төгәлсезлек булуын күрсәтә. Аның каравы, хәзер безнең шимпанзелар кыргый табигатьтәгедәй шартларда яши. Ябык вольерда 60–70% дымлылык саклансын өчен, томан җайланмалары куелган. Мондый тропик дымлылыкта шимпанзелар сабыйлар кебек уйный-шаяра, ә иң мөһиме, үзләрен бик яхшы хис итә. Әмма... дымландыргычлар эшләгәндә, һаваның температурасы төшә. Кышын әлеге проблема җылыту системасы хисабына хәл ителсә, җылы бирү тукталган арада маймылларга салкын. Алар исә, кеше кебек, салкын тиюгә бирешүчән. Шунлыктан тиздән шимпанзелар вольерына кондиционер системалары урнаштырачаклар.

Мондый нюанслар һәр адымда диярлек, дөресрәге, сирәк очрый торган хайваннарның һәр төре белән килеп чыгарга мөмкин. Шунысын да аңларга кирәк: зоопаркларга сирәк очрый торган хайваннар асрауга рөхсәт биргән документларны алу процессы катлаулы һәм озакка сузыла торганнардан. Бигрәк тә безнең географик киңлек шартларында – календарь елның күбрәк өлешен хайваннар ябык биналарда үткәрә бит.

– Без бүген координаторлар таләп иткән барлык шартларны үтәү юлында, бу зоопаркыбыз дөньякүләм дәрәҗә булачак дигәнне аңлата, – дип сөйли Александр Малёв.

ЗАХАРИЯ КАНӘГАТЬ

Казанлылар яратып өлгергән бегемот Захария хәзер фламинго, Мисыр челәннәре һәм балыклар янәшәсендә яши. Кыргый табигатьтә алар бер-берсе белән бик тату. Захариягә уңайлы булсын өчен, суны яңа биологик система чистарта, элеккеге ком фильтрлары гына түгел инде бу, бернинди ис тә калмый. Хәзер һәркем канәгать – бегемот үзе дә, аның бассейнда коенуын күрергә килүчеләр дә.

КҮРШЕЛӘР

Казан зооботаника бакчасы яңа концепциясенең төп принцибы, мөгаен, стереотипларны юкка чыгарудадыр да:

– Катнаш экспозицияләребезне күргәч, Мәскәүдән килгән коллегаларыбыз да безнең өчен сөенде. Без саванна принцибы буенча эшләргә булдык һәм кайбер җанварлар өчен «коммуналка» ясадык. Әйтик, мөгез үсентеле ташбакалар шаян сурикатлардан бер дә курыкмый, алар янында рәхәтләнеп сыйлана. Нил тимсахлары клариусларны аулый, дөрес, алары крокодиллардан качарга өйрәнеп бетте инде. Казан зоологлары түземсезләнеп көткән филләр гамадриллар күршесендә яшәячәк, ә елның җылы фасылларында ак башлы комайлар һәм кара карчыгалар аларны үз вольерының өске ярусыннан күзәтәчәк...

АФРИКА ӨСЛҮБЕНДӘ

Яңа экспозиция бина һәм фасадлары дизайны проектын «Татинвестгражданпроект» ДУП дизайн һәм архитектура бүлегенең иҗат төркеме эшләгән. Моннан тыш, «МосБио Инжиниринг» ҖЧҖ рәссам һәм проектчылары да үз өлешен керткән. Генераль подрядчы исә – «Казан» җитештерү-төзелеш берләшмәсе.

Мондый проект беренче тапкыр әзерләнгән, һәм бу институт белгечләре өчен үзенә күрә бер сынауга әйләнгән:

– Проектны эшләүгә елга якын вакыт китте, бу дәвердә бөтен дөнья зоопарклары тәҗрибәсе җентекләп өйрәнелде, – ди «Татинвестгражданпроект» ДУП дизайн һәм архитектура бүлеге архитекторы **Эльвира Әбүнәгыймова**. – Зоопаркта бернинди читлек тә юк. Хайваннарны бирегә килүчеләрдән сулы канау, электр көтүчеләре, 4 см калынлыктагы пыяла киртәләр аерып тора. Дөнья тәҗрибәсе дә моның яхшы алым булуын раслый. Хайваннар өчен табигый мохиттәгедәй шартлар тудырылган, аларны карарга килүчеләргә дә җанварлар кул сузымында гына кебек тоела. Һәм бернинди рәшәткәләр дә юк! Яңартылган «Замбези елгасы» зоопаркы территориясе Африка өслүбендә башкарылган, һәм бирегә килүчеләр беренче минуттан ук үзләрен эссе кыйтга кунаклары итеп хис итә. Африка стиле бина һәм вольерларны бизәү элементларында да сакланган. Нигез итеп Африка халкы этнокоды алынган: халыкның рухы җете төсләр, чуарлык, төрле геометрик формалар аша чагылдырылган.

Кыйтганың теге яки бу җирлеге атмосферасын, символларны, Африка колористикасын зоопаркның бөтен бизәлешендә күреп була. Кагыйдә буларак, африкалыларның тораклары үзенчәлекле бизәлә. Проект авторлары әлеге идеядән файдаланырга булган – һәр вольерга билгеле бер халыкның бизәге төшерелгән.

КУНАКЛАР МӘНФӘГАТЕН КАЙГЫРТЫП

Бирегә килүчеләрнең мәнфәгате кайгыртылганмы соң? Зоопаркны төзегәндә, аның һәркем өчен уңайлы булуын тәэмин итүгә өстенлек бирелгән. Начар күрүчеләр өчен хайваннарның кечкенә сыннары куелган. Мәсәлән, филләр яши торган урында кечкенә генә фил сыны тора, аны тотып карап, биредә нәрсә яшәвен белеп була. Моннан тыш, Брайль шрифтлы табличкалар да куелган. Зоопаркның бөтен территориясендә инвалидлар коляскада йөри ала. Мөмкинлеге чикләнгән кешеләр өчен махсус тавыш сигналлары да бар.

Биредә гомумән йөрүе җиңел – бөтен җирдә юл күрсәткечләр урнаштырылган. Хайваннарны фотога төшерәсең килә икән, рәхим ит, тик яктырткыч белән генә куркытма. Син бит монда хуҗа түгел, кунак кына.

Фотосессия урыннары, хайваннар һәм Африка турында кызыклы мәгълүмат язылган стендлар, жирафлар павильонында интерактив дисплей бар. Чүп-чарны аерып җыю өчен контейнерлар куелган. Ниһаять, кафе, аның диварлары хайваннар дөньясыннан күренешләр белән бизәлгән, ә тәрәзәләреннән саванналардагы антилопаларны күзәтеп була...

Биредә балаларга да, өлкәннәргә дә уңайлы һәм күңелле ял итү өчен бөтен мөмкинлекләр тудырылган. Тик менә «Замбези елгасына» җәмәгать транспортында килүчеләргә тимер юл күпере астыннан куркынычсыз җәяүлеләр кичүе генә ясалмаган. Дөрес, киләчәктә яңартылган Казан зооботаника бакчасының өч өлеше дә – «Замбези елгасы», «Амазонка елгасы» һәм «Врангель утравы» – үзара күперләр һәм тоннель белән тоташачак, дип вәгъдә итәләр.



Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!

tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar

App Store

Google Play

Реклама 6+

игелекле эшләр /

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстанда җәй **НӘРСӘ** белән шаккатыра

Чын ирләр **НИНДИ** пәрәпәчләр пешерә

Самара татарлары **НИНДИ** традицияләрне саклый

КАЙСЫ курортларда ял итү яхшырак

ТАТАРСТАНДА ҖӘЙГЕ БӘЙРӘМНӘР

Җәй көне Татарстан кунакларны матур табигате һәм истәлекле архитектура һәйкәлләре белән генә түгел, ә бәйрәмнәр белән дә шаккатыра. Аларның саны һәм төрлелегенә килгәндә, һәркем күңеленә хуш килерлеген таба ала. Хәер, кайсын сайлыйм икән дип, баш ватасы да юк, иң яхшысы – берсеннән-берсе якты, чуар бәйрәм мохитенә чуму, чөнки Татарстанда яшәүче һәр халыкның, һәр бәйрәмнең үз киеме, үз йола-җырлары, үз сыйлары була. Җирле генә вакыйгамы ул, әллә кунакчыл республикабыз кабул иткән халыкара дәрәҗәдәге колачлы бәйрәм булсынмы – анысы мөһим түгел. Мондый төрлелек никадәр күбрәк булса, бәйрәмнәр өчен сәбәбе дә күбрәк: милли, дини, музыкаль, мода бәйрәмнәре...

Фото: «Татар-информ» МА

Фото: «Татар-информ» МА

ДИНИ

КАЗАН ИЗГЕ АНА ИКОНАСЫ СОБОРЫН ТОРГЫЗУ

Бу христиан динендәге казанлылар өчен генә түгел, ә барлык дин вәкилләре өчен дә «күңелләрне сафландыра торган» чын бәйрәм булды.

Казанда Алла Анасының могҗизалы сурәтен табу көнен Татарстан башкаласы Казан Изге Ана иконасы соборын изгеләндерү тантанасы белән каршы алды. Әлеге гыйбадәтханәгә патша Феодор Иоаннович фәрманы белән 1594 елда икона табылган урында нигез салынган. Собор 1932 елда, Совет власте чорында, җимерелгән һәм 2021 елда, нәкъ архитектор Иван Старов планлаштырган рәвештә, яңадан торгызылган, төзелеш эшләре архитекторның архив документлары һәм сакланып калган проектлары буенча алып барылган.

БИК ИСТӘЛЕКЛЕ КӨН

Мәскәү һәм Бөтен Русь Патриархы Кирилл:

– Кадерле туганнар, православиедәге дин кардәшләрем һәм мөселманнар, бүген бик истәлекле көн. Бүген без кафедраль соборны изгеләндердек, ул бөтен дөньяда Алла Анасының Казан иконасы буларак билгеле могҗизалы икона табылган урында яңадан төзелде.

– БЕЗ ТӨП ИЗГЕ УРЫННАРНЫҢ БЕРСЕН ТОРГЫЗДЫК

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Республикасы Президенты:

– Нәкъ биш ел элек без Изге Патриарх Кирилл җитәкчелегендә чиркәү нигезенә беренче ташны салдык. Һәм менә бүген бу мәһабәт соборда Патриарх һәм дәрәҗәле кунаклар катнашында янә илаһи литургия кылына. Татарстан башкаласы һәм безнең данлы Ватаныбыз үзенең төп изге урыннарының берсен яңадан торгызды.

– БЕРДӘМ БУЛГАНДА, КҮП НӘРСӘ ЭШЛИ АЛАБЫЗ

Минтимер Шәймиев,
Татарстан Республикасы Дәүләт киңәшчесе:

– Юл салынган, ул безнең күп динле халкыбыз күңеленә якын, һәм бу юл үзен аклый. Эш бик күп әле. Илдә күңелләрне сафландыру процессы бара икән – үзебездән торганны башкару өчен, без бөтен көчебезне салырга тиеш. Без булдырабыз, бездә шулай диләр. Бердәм булганда,без күп нәрсә эшли алабыз.

МУЗЫКАЛЬ

ОНЫТМА СИН ДӘ БУ ҖӘЙГЕ ҖЫР-МОҢЛЫ КИЧЛӘРНЕ!

Июль аенда Алабуга Россиянең иң популяр шәһәренә әйләнә. Мондагы кунакханәләрдә 15 июльдән 18 июльгә кадәр буш номер табып булмый. Шишкин буаларындагы стадион меломаннар белән шыгрым тула, алар бөтен гаиләләре белән бергә бер максатта – үзләре яраткан классик музыканы сыйфатлы башкаруда тыңларга дип килә. Чөнки бу көннәрдә Алабугада Борис Березовскийның open air форматындагы «Алабугада җәйге кичләр» Халыкара музыка фестивале уза. Июльнең дүрт көнендә ачык сәхнәдә Бельгия, Нидерланд, Франция, Израиль һәм Россиядән 200 гә якын музыкант чыгыш ясады. Виолончельдә уйнаучы Александр Князев, пианист һәм джаз импровизаторы Олег Аккуратов, пианист Юрий Мартынов, Мария театры солисты Айгөл Хисмәтуллина, пианист Константин Емельянов, РСФСРның халык артисты Сергей Шәкүров...

– МИН БИК САГЫНДЫМ

Борис Березовский,
«Алабугада җәйге кичләр» проектының сәнгать җитәкчесе:

– Алабугага килгәч, үзләре белән сине инде күп нәрсә бәйләгән кешеләрне, бу буаларның илаһи манзарасын күрәсең дә, бик сагынганыңны аңлыйсың... Монда кайтуыма искиткеч шатмын, мине көткән һәм булышкан кешеләрнең барысына да рәхмәт.

– ГАФУ ИТЕГЕЗ, МИНЕ ТАТАРСТАН КӨТӘ!

Сергей Шәкүров,
РСФСРның халык артисты:

– Татарстанга, аеруча әтинең туган авылына, Тәтешкә, Иделнең биек яр буена килгәч, йөрәк тибешем ешая. Бу минем өчен бик дулкынландыргыч мизгелләр. Моннан тыш, мин Татарстанның Мәдәният министрлыгы белән тыгыз элемтәдә торам, пандемиягә кадәр Казанга бәйрәмнәргә еш килеп йөрдем. Гомумән, республика белән дуслыгым нык һәм күпьеллык.

Әлегә Казанда кайчан булачагымны белмим. Тик чакырсалар, шундук очып килеп җитәм. Барлык эшләремне арткарак чигерәм, танышларыма да: «Гафу итегез, мине Татарстан көтә», – дим.

Фото: «Татар-информ» МА

МОДАЛЫ

«ТОРМЫШ СТИЛЕ – МӘДӘНИ КОД»

Төрле милләт һәм ил вәкилләрен берләштерү, ил эчендә дә, аннан читтә дә милләтара дуслыкны ныгыту мода ярдәмендә дә башкарыла ала. Моданың «Мәдәни код» проектын июль аенда Казан Кремлендә тәкъдим иттеләр.

«Тормыш стиле – Мәдәни код» I Этно-Fashion фестивале 400дән артык останы – Россиянең барлык төбәкләреннән, БДБ илләреннән, Европа һәм Азия илләреннән иҗат берләшмәләре вәкилләрен, төрле һөнәрчеләрне, халык сәнгате һөнәрләре осталарын, дизайнер һәм модельерларны үзенә җәлеп итте. Казанлылар һәм башкала кунаклары декоратив-гамәли сәнгать һәм халык сәнгате һөнәрләре күргәзмәсендә, дизайнерларның модалы кибетендә, кызыклы кичәләрдә, тәэсирле перфомансларда – кыскасы, чын-чынлап модалы бәйрәмдә булды.

ХАЛЫК ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕН – ШӘҺӘР МОХИТЕНӘ

Елена Ямпольская,
РФ Дәүләт Думасының мәдәният комитеты рәисе:

– Халык һөнәрчелеге – милләтнең сәнгати коды ул, һәм аны көндәлек тормышыбызга киңрәк кертергә кирәк. Мин әлеге сәнгати ысул-алымнарны шәһәр мохитендә булдыру яклы: шул рәвешле балалар мәйданчыклары, стадионнар, мәктәпләр, автобус тукталышлары – һәр тараф матурлансын, төзекләнделсен. Алар гармонияле, яшәеш өчен уңайлы мохит тудырыр иде.

ТАТАРСТАНДА ХАЛЫК ҺӨНӘРЧЕЛЕГЕ ЮГАРЫ СЫЙФАТЛЫ

Лилия Нургатина,
РФ Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының социаль әһәмиятле товарлар сәнәгатен үстерү департаменты директоры урынбасары:

– Татарстан Республикасы кебек алдынгы төбәкләрне бу процесста актив катнашулары, үз осталары эшләнмәләренә һәм кулланучылар, һәм рухи җәһәттән аеруча яхшы мөнәсәбәт күрсәтүләре, шулай ук традицион һөнәрчелекнең югары сыйфаты өчен рәхмәт белдерәбез.

ТРАДИЦИОН НӘРСӘ ДӘ КЫЗЫКЛЫ ҺӘМ АКТУАЛЬ БУЛА АЛА

Ирада Әюпова,
Татарстан мәдәният министры:

– «Киемгә карап каршы алалар» дигән әйтем юктан гына тумаган. Элек, киеменә карап, кеше турында күп нәрсә әйтеп булган... Кием-салым билгеле бер мәгълүмат чыганагы саналган. Глобальләшү заманында кием-салымга бәйле мондый символизм шактый җуелган. Бу өлкәдә ата-бабаларыбыз туплаган тәҗрибәне киләсе буынга тапшыру мөһим. Әлеге проект белән без традицион нәрсәләрнең дә кызыклы һәм актуаль булырга мөмкин икәнлеген күрсәтергә теләдек.

РЕДАКЦИЯ КУХНЯСЫ

АНДРЕЙ ГЕРАСИМОВТАН УДМУРТ ПӘРӘПӘЧЕ

Автор: Татьяна Вафина

Татарстан ир-атлары бөтен нәрсәне пешерә белә – шашлыгын да, ухасын да, йомырка тәбәсен дә... Беренче ашны да, икенчесен дә, хәтта компот та кайната... Ә бу юлы «Татарстан» редакциясе кухнясы» тарихында беренче тапкыр безгә камыр ризыклары остасы белән очрашу бәхете тәтеде: камыр басарга кирәкме – рәхим ит, уклау белән җәяргәме – анысын да булдыра, аннан тарталеткалар ясаргамы – җаның никадәр тели, пәрәпәч белән сыйларгамы – телеңне йота күрмә! Кыскасы, ир-ат кына түгел, ә чын хәзинә!

Мондый фикер белән элеге «хәзинә»нең җәмәгате Ольга да тулысынча килешә.

– Бу – нәкъ менә удмуртларга хас сыйфат, – ди ул ире, Татарстан удмуртларының төбәк милли-мәдәни мохтарияте рәисе Андрей Герасимов турында.

– Пәрәпәч пешерүме?

– Эшне ахырына кадәр җиткерү, – дип төзәтә Ольга Герасимова. – Менә ул пәрәпәч пешерәм дигән икән, пешерде дә. Югыйсә, моңарчы бер тапкыр да пешергәне булмады, гомумән, аның аш-су янында кайнашканы юк. Тик үз халкыңның милли ризыкларын күрсәтеп бирергә кирәк икән – димәк, моны эшләячәк.

– Ярдәмчеләрем яхшы булганга ул, – дип көлә Андрей, Татарстан удмуртлары милли-мәдәни автономиясенең яшьләр тармагы вәкилләре Оля Чайникова һәм Лиза Бехтерева белән таныштырып.

– Безнең Андрей Сергеевич шундый инде ул, барысын да булдыра, – ди кызлар, мактаудан ояла-ояла. – Ул шундый катлаулы ризык сайлар дип хәтта уйламаган да идек. Мондый шеф белән удмурт ашлары ресторанын да ачып була. Пилмән бөгәрбез, пәрәпәч, шаңгә пеше-



Фото: Александр Ефремов

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

Камыр өчен:
- Йомырка – 1 данә
- Арыш оны – 150 г
- Бодай оны –70 г
- Су / Сөт – 150 г
- Каймак – 125 г
- Тоз – тәменчә

Эчлек өчен:
- Йомырка – 3 данә
- Шампиньон – 250 г
- Суган – 1 баш
- Яшел суган – 2 бәйләм
- Сөт – 100 мл
- Көнбагыш мае – 50 г
- Тоз – тәменчә

рербез... Әйдәгез, Андрей Сергеевич, ачабыз, ә! – ди алар, түземсезлектән сикергәләп.

– Әйдәгез, ачыйк, – дип рөхсәт бирә Андрей. – Мин сезгә булышырмын. Армиядә суган һәм бәрәңгене әйбәт чистарта идем...

ӘҮВӘЛ КАМЫР БАСАБЫЗ

Удмурт яшьләре җитәкчеләренә камырны ничек басарга икәнен күрсәтте генә – һәм менә ул инде бирелеп эшкә дә керeште. Үзе сөйләнгәләп тә ала, янәсе, камыр басу авыр, әмма кызыклы эш икән.

Камыр өлгергән арада, пәрәмәчкә әчлек әзерлибез. Бүген ул гөмбәле булачак. Гөмбә, суган, йомырка, сөт, тоз – болар барысы да бергә болгатылып, чәнечке белән җиңелчә генә күпертелә... Әчлек болгаткан арада, без удмуртлар турында күп нәрсә белеп өлгердек. Татарстанда алар әллә ни күп түгел – соңгы җанисәп мәгълүматлары буенча республикада 23454 удмурт яши икән.

– Соңгы җанисәп 2010 елда булды. Шул вакыттан бирле Татарстанда удмуртлар саны арттымы, сезнең фикер нинди?

– Минемчә, артты. Бездә удмуртлар тупланып яши торган районнар бар: Кукмара, Балтач, Әгерҗе, Баулы... Мин аларга әлеге иҗтимагый вазыйфама бәйле эшләр белән еш барам һәм Татарстанда безнең халык – удмуртларның тормышлары яхшы дип әйтә алам. Димәк, үрчергә һәм ишәергә мөмкинлек бар.

Мин үзем Удмуртиядә туып-үстем, тик соңыннан Татарстанга күчендем. Һәм хәзер бу төбәк миңа күпкә якынрак. Биредә – гаиләм, бизнесым, җәмәгать эшем. Монда халыклар дуслыгын ныгытуга корылган сәясәт алып барыла. Биредә хыялларыма ирештем һәм яңалары да чыңга аша тора. Гап-гади удмурт кешесенә тагын ни кирәк инде?

– Гап-гади удмуртның нинди хыяллары тормышка ашты инде?

– Барысы да! Мәсәлән, мин очучы булырга хыялландым. Булдым да.

– Шулай җиңел генәме?

– Бернинди авырлыгы да юк. Балачактан шул хыял белән янып йөрдем. Богырысландагы гражданнар авиациясе очучылары әзерләү училищесына укырга кердем. Армиядә дә һава-десант гаскәрләрендә хезмәт иттем: башта Литвада, аннары – Одесса янында. Соңрак «Татарстан һава юллары» авиакомпаниясенең «Ан-2» самолетында икенче пилот булып эшләдем. 90 нчы елларда эшкуарлык белән шөгыльләнергә карар кылдым. Ул вакытта кирәкле бизнес иде, эш алга китте. Хәзер дә шуның белән шөгыльләнәм. Халыклар дуслыгы йортындагы иҗтимагый эшем дә мавыктырып алып кереп китте...

УДМУРТЧА УҢЫШ СЕРЕ

...Удмуртлар, гомумән алганда, табигате буенча бик хезмәт сөючән, көчле, әмма тыйнак халык. Безнең кебекләр монда кирәк. Җитәкче урыннарда удмуртлар әллә ни булмаса да. Тик Удмуртиядә дә президент удмурт түгел. Без карьерачы түгел, гомумән, үзебезне алга чыгарып күрсәтергә яратмыйбыз. Бу геннарга ук шулай итеп салып куелган, хәтта шундый әйтем дә бар, эти миңа һәрчак: «Башыңны күтәрмә, алайса өзеп китәрләр!» – дия иде.

– Удмуртлар кемгәдер ошау теләге белән янмый, – дип өсти Андрейның хатыны. – Яхшы тәэсир калдырыйм дип, алар төче телләнеп маташмаячак. Удмурт кешесе нинди итеп яратылган, шундый булып кала. Алар үз көчләренә ышана һәм читләрнең ярдәменә мохтаҗ түгел – удмуртларны бәяли торган иң хак сүз.

– Гомумән алганда, яшәешкә карата гасырлар дәвамында формалашкан мөнәсәбәтебез безне канәгатьләндерә, – дип йомгак ясый Андрей. – Шуңа күрә тормышта барысы да яхшы килеп чыга.

– Шактый үзенчәлекле, көтелмәгәнрәк уңыш сере.

– Удмуртларның уңыш сере, – дип дөресли аш-су остабыз һәм кулындагы камырны бик җитез генә берничә кисәккә бүлеп, әвәли һәм түгәрәкләргә кискәли.

– Удмуртлар тагын нинди халык? Сез дә өстәгез! – дип мөрәҗәгать итә ул яшьләргә. – Оялып тормагыз.

– Кунакчыллар! Матурлар! – дип бик тиз өстәп куя тыйнак удмурт кызлары.

– Менә-менә! – дип көлә Андрей. – Безнең удмуртларның автономиясе булган кайсы гына районга барсагыз да, моңа инанырсыз. Ә мохтариятләр Татарстанның 11 районында эшли. Әле тагын яшьләрнеке аерым...

– Ә яшьләрне ник аердыгыз әле?

– Алар бездә бик үзенчәлекле, аерылып тора, – дип ярдәмчеләренә ымлый Андрей. – Алар өчен аерым программа һәм аерым стратегия. Аларның нинди актив икәнен үзегез күрәсез. Үзләре әйдәп бара.

ЯШЬЛӘР БУЛДЫРА

Оля белән Лизадан гыйбарәт актив яшьләр, уклау тотып, уң яктан шеф янына сыеша, камырны үзләре җәяргә маташа. Тик бу юлы түгел! Андрей Герасимов өлгер хәрәкәт белән уклауны яшьләр кулыннан эләктереп ала да, өлкәннәрчә ышанычлы итеп баса-баса, пәрәмәч өчен камыр кисәкләрен җәя башлый.

– Менә монысы тигез килеп чыкмады, – дип тәнкыйтьли Оля. – Анысын кире ясагыз, Андрей Сергеевич, югыйсә «Инстаграм»да матур күренмәс.

– Ярый, сезнеңчә булсын, – дип ризалаша рәис кеше һәм брак камырны күндәм генә кире җәя, эш арасында мичкә утын ташларга өлгерә – пәрәмәч өчен ут кызу янарга тиеш.

Ә шул ук вакытта ниндидер сәер Дыдык исеме белән аталган olya_lya_17 сәхифәсендә уклау, мич һәм утын турында яңа пост барлыкка килә...

– Нәрсә ул «дыдык»?

– Күгәрчен! – дип беравыздан тәрҗемә итеп бирә кызлар.

ДЫДЫК

Андрей Сергеевич пәрәмәчләр өчен камырдан кечкенә кәрҗиннәр ясаган арада, Оля белән Лиза безгә телефоннан июль аенда Әгерҗе районының Варклед-Бодья авылында

Бүген балаларга чын удмурт исемнәре кушмыйлар. Ә юкка, чөнки алар бик кызык һәм матур яңгырый.

УДМУРТ ИР-АТ ИСЕМНӘРЕ:
Лапшабедунь, Дзянкей, Есекей, Бекельдей, Дзюйка, Зянхват, Бегеней, Келдык, Ярхей, Яркипей, Сяськабей, Донды.

УДМУРТ ХАТЫН-КЫЗ ИСЕМНӘРЕ:
Чима, Дыдык, Сетым, Дзусван, Узан, Зянсула, Шады, Бисултан, Нылка, Бегичань, Алмас, Италмас, Чачабей, Зангари.

1 Камыр басабыз

2 Кискәлибез

3 Турыйбыз

4 Кискәлибез

5 Томалап пешерәбез

6 Куертеп болгатабыз

7 Кисәбез

8 Җәябез

9 Ясыйбыз

10 Тутырабыз

11 Пешерәбез

12 Алабыз

13 Теләкләр язабыз

узган «БиГерд» (удмуртчадан «Без – бер төен» дип тәрҗемә ителә) удмурт яшьләре форумының фотоларын күрсәтә. Форумга Россиянең төрле төбәкләреннән активистлар җыелган. Җыенның максаты бер генә була – удмурт яшьләрен үз халкының мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, йолаларын һәм телен торгызу, саклау, үстерү эшчәнлегенә җәлеп итү.

Шунысы куанычлы: мондый җәлеп итүнең бер алымы буларак, кызлар журналистиканы сайлаган һәм үзләрен шул һөнәрдә сынап караган: «БиГерд» форумын һәм «Гырон Быдтон» удмурт милли бәйрәмен яктыртканнар.

Халыклар дуслыгы йорты директоры, Казан университетының журналистика факультетын тәмамлаган Ирек Шәрипов журналистлардан иң яхшы дуслар, димәк, Халыклар дуслыгы йортының иң яхшы хезмәткәрләре чыгуын юкка гына еш телгә алмый. Менә безнең яшь Дыдык – Ольга Чайникова да – Татарстан удмуртларының яшьләр хәрәкәте җитәкчесе. Ерак китәчәк, ерак очачак әле Дыдык!

ТАБИГАТЬ БЕЛӘН ГАРМОНИЯДӘ

Пәрәпәч әзер. Кызлар үләнле чәй пешерә, табын кора. Аш-су белән кайнашып хезмәт куйган шеф тәлинкәдән чәй тәмли-тәмли, үзләренең мәҗүси ата-бабаларын искә ала. Удмуртлар аларны «табигать белән гармониядә яшәүче кешеләр» дип атауга өстенлек бирә...

Без «Тишина» эко-утары территориясендәге ак каеннар арасында, үрелгән кәнәфиләрдә утырабыз,тынлык белән хозурланып, пәрәпәч белән сыйланабыз. Телефон да тынып калды, мобиль элемтәсе дә, интернеты да кайдадыр каен очларында адашты, ахры. Анысы Аллага шөкер! Бер генә көнгә булса да удмуртка әйләнеп, табигать белән гармониядә яшәп алу нинди рәхәтлек бит!


Дорогие читатели
журнала Татарстан
от всей души желаю благополуч-
ия и процветания вашим семьям,
[illegible] исполнения всех ваших [illegible]
Любви, Счастья, Тепла!
[illegible] [illegible], [illegible] [illegible]
[illegible]!
27 июля 2021 г.

УДМУРТЧА-ТАТАРЧА СҮЗЛЕК:

КӨНДӘЛЕКТӘГЕ ҖЫЛЫ СҮЗЛӘРНЕ ТУГАН ТЕЛЕНДӘ, МӘСӘЛӘН, УДМУРТЧА ИШЕТҮ, ҺӘР КЕШЕНЕҢ КҮҢЕЛЕНӘ ХУШ КИЛӘЧӘК:

БУР ЧУКНАЕН! – ХӘЕРЛЕ ИРТӘ!

ЧЕСКЫТ МЕД КОШКОЗ! – ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

КЫЧЕ УЖЪЁСТЫ? – ХӘЛЛӘР НИЧЕК?

ЗЕЧ ЛУЭ! – САУ БУЛЫГЫЗ!

БАДЗЫМ ТАУ! – ЗУР РӘХМӘТ!

КОФЕ ТЫНЫД ЛЭСЬТОНО-А? – СИҢА КОФЕ ӘЗЕРЛИММЕ?

ОЙДОЛЭ ЖӦК СЬӦРЫ ПУКСЁМ – ТАБЫНГА РӘХИМ ИТЕГЕЗ.

САЛАМ ВЕРА – СӘЛАМ ӘЙТ.

ЗЕЧ КӦЛЭ! – ТЫНЫЧ ЙОКЫ!

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

ГӨБӘДИЯ АШАРГА – ЯҢА ФӘЙЗУЛЛАГА



Автор фотолары

Автор:
Алсу Троицкая

Самара өлкәсендә татарлар – сан ягыннан икенче урындагы халык. Аларның күбесе шәһәрләрдә төпләнгән, әмма милләттәшләребез күпләп яшәгән урыннар да бар, һәм без шунда юл тоттык та. Татарстан Нурлаты күршесендәге Кошки районы Яңа Фәйзулла авылына.

Айшә Дадашова,
Самарадан кайткан кунак.

БИЮЛӘР ҺӘМ КУЛ ЭШЛӘРЕ ТУРЫНДА

Бер кыз татар биюен кабатлый. Нечкә кулларының нәфис хәрәкәте кошларның канат җилпүен хәтерләтә. Йөзендә җиңелчә елмаю. Башы бераз гына иелгән. Сары челтәр бизәк белән чигелгән яшел күлмәкле, башында калфак. Бию ахырында ике аяклап тыпырдау авылның бөтен мәдәният йортына кайтаваз булып тарала.

Бии-бии сулышы капкан кыз сәхнә баскычларыннан йөгереп төшә дә сорап куя:

– Йә ничек?

– Һәрвакыттагыча менә дигән! – дип кызның күңелен күтәреп җибәрә Мәдәният йорты директоры Лилия Имаметдинова.

– Таныш булыгыз: Айшә Дадашова. Самарадан кайткан кунагыбыз ул, – дип таныштыра Лилия кыз белән. – Һәм җәй буена безнең сезонлы хореографыбыз да.

Чыннан да, Айшә һәр җәй бирегә, авылга, әби-бабасы янына кунакка кайта. Һәм мондагы Мәдәният йортында милли биюләр куярга ярдәм итә.

Айшә Самара шәһәрендә яши һәм аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле «Яктылык» мәктәбендә укый:

– Безнең хәтта «Мирас» этнографик музеебыз да бар. Татарларның гасырлардан килгән гореф-гадәтләре турында күп нәрсәне без әнә шунда өйрәнәбез. Ә җәйге каникул алдыннан безнең мәктәптә татар шигырьләрен уку бәйгесе узды. Мин 1 нче дәрәҗә лауреат булдым, – дип елмая Айшә. – Минем өчен бу, нигездә, авыр булмады, чөнки өйдә татарча сөйләшәбез. Ә монда, авылда, әби-бабай безнең белән туган телдә генә сөйләшә. Безнең мәктәптә төрле милләт балалары укый, барысы да татар шигырьләрен, җырбиюләрен бик теләп өйрәнә. Ә бер үзбәк кызы хәтта бик күп татардан яхшырак итеп татарча сөйләшә.

Айшә өчен бию дә үзенчәлекле тел булып тора:

– Мин, үз-үземне белгәннән бирле, һәрчак биедем. Татарча да, русча да, грузинча да... Гомумән, һәр халыкның биюендә башка милләтнекенә охшаган урыннар бар. Без үз-үзебезгә бикләнеп яши алмыйбыз бит. Бию дә һәркемдә һич кабатланмас үзенчәлекле була алмый. Иң мөһиме: татар биюе барыбер читтән аерыла-танyла торган булып кала, әйтерсең, ул көнкүрешебезне һәм холык-фигылебезне сурәтләп бирә. Сүз уңаеннан, чигү дә шулай ук. Үзенчәлекле татар бизәкләре белән чигәргә дә мәктәптә өйрәттеләр. Татар чигүләрендә аерым бер төрле шатлык һәм җылылык бар. Безнең эшләр Самарадагы Халыклар дуслыгы йортында тикмәгә генә эленеп тормый. Анда килгән кунакларны чиккән сөлгеләргә татар бавырсагы, чәкчәк куеп каршы алабыз. Чит ил кешеләре милли чигешләргә дә, сыйнигъмәтләргә дә соклана. Мин дә татарга кагылышлы һәрнәрсәне бик яратам...

ГАДӘТ-ЙОЛАЛАР ТУРЫНДА

Яңа Фәйзулла халкы үз авылларын Яңа Җүрәй дип атый. Аның аша Нурлаттан Самара өлкәсенең Кошки район үзәгенә бара торган юл үтә. Йортлар каршында – шау чәчәкле гөлбакчалар.

– Безнең халык чисталык, пөхтәлек ярата, һәркемнең ишегалды һәм йорты балкып тора, – дип сөйли элек мәктәптә тарих фәне укыткан Рәйсә Тәрҗеманова. – Һәрвакыт шулай булды. Бала чактан ук хәтерлим, берәрсе йорт күтәрә башласа, бөтен авыл ярдәмгә килә иде. Кемдер бураны мүкли, кемдер бөтен эшчегә җитәрлек итеп чиләкләп ризык ташый. Аннан соң хатын-кызлар хуҗабикәгә өйне юып чыгарга булыша. Өйдән җылылык бөркелсен, уңайлы булсын өчен, чүлмәге белән гөлләр алып киләләр, ситсы пәрдәләр, чигелгән сөлгеләр эләләр.

Яңа Фәйзуллада каз өмәсенә дә бергә җыела торган булганнар.

– Бездә зур елга да, чишмәләр дә юк, буа гына бар, шуңа күрә без каз йолкырга йорттан-йортка чиратлашып җыела, зур ит бәлеше пешерә идек, - дип дәвам итә әңгәмәдәшебез. – Ә бәрәңге утырту һәм алу, язын өй юу гомумән авыл бәйрәменә әверелә. Анда да бер йорттан икенчесенә күчеп йөри идек. Хуҗалар өмәчеләргә табын җәеп, мунча ягып тора. Хәзер дә мондый гадәт бар, әмма алай ук колачлы түгел. Кемгәдер балалары шәһәрдән җыелып кайта, кемгәдер дуслары яки күршеләре булыша. Әмма безнең авылда элеккечә үк үзара ярдәмчеллек, хезмәт сөючәнлек һәм гореф-гадәтләр саклана. Дөрес, тел белү, татарча өйрәнүгә килгәндә, хәзер инде барысы да ул кадәр куанычлы түгел...

ЭШ ТУРЫНДА

Монда килгән чакта, Нурлат базарында ике әбине очраттык, чиләкләре туп-тулы, кара карлыган сатарга чыкканнар. Икесе дә Яңа Фәйзулланыкы икән. Юлда очраган машиналарга утырып килгәннәр.

– Бүген авылда нигездә өлкәннәр яши, – дип сөйләде алар. – Эшкә якын-тирә авылкалаларга йөриләр, эшләргә теләгән кеше тик утырмый. Бездә фермерлар да бар... Хәер, нәрсә зарланып торырга инде, хәзер күп авылларда шулай. Яшьләр авылда яшәү теләге белән бик янып тормый.

МӘКТӘП ТУРЫНДА

Биредә мәктәп 2005 елда ябылган, чөнки бала саны нык кимегән. Хәзер сигез баланы җирлекнең үзәк авылына йөртәләр, тик программада татар теле юк. Шуңа күрә бөтен өмет – гаиләдә.

ТЕЛ ТУРЫНДА

– Чынбарлык шундый ки, бүгенге көндә балаларыбыз һәм оныкларыбыз өчен карьера, яхшы хезмәт хакы, иминлек-муллык, белем



1 Авыл коесы – саф су чыганагы.

2 Яңа Фәйзулла авылы мәчете.

алу кебек нәрсәләр һич тә татар теленә бәйле түгел, – ди Рәйсә Тәрҗеманова. – Ярый әле гаиләдә бөтен бала да татарча сөйләшә. Мәчет тә зур роль уйный. Безнең хәзрәтнең вәгазь һәм үгет-нәсихәтләре күп очракта туган телне саклау, өлкәннәрне һәм ата-ананы хөрмәт итүгә кагыла. Диндар кеше ата-бабаларының телен югалтмый. Коръән сүрәләренең тәрҗемәләре бар, алар татар телендә. Ә гомумән алганда, яшерен-батырын түгел, балалар татар телен көнкүреш дәрәҗәсендә генә белә.

БОРЧЫГАН МӘСЬӘЛӘ ТУРЫНДА

Авылның тагын бер бик җитди проблемасын өйлә намазын уздырганнан соң безнең белән очрашкан Ислам хәзрәт Тәрҗеманов ачып салды:

– Элек татар авылларында гына түгел, бөтен җирдә төпчек ул әти-әни янында кала иде. Кызганыч, бу гадәт хәзер бөтен җирдә дә сакланмый. Ата-ана йортын ташлап китүчеләрне кайвакыт «качкыннар» дип битәрлисем килә. Гаиләдән бер генә ир бала булса да авылда калса, һәр йортта ким дигәндә бер гаилә яшәр иде!

Ә хәзер үз шәһәрләрегезгә карагыз – Мәскәү якын-тирәләр хисабына киңәя-зурая, Самара, Казан да шулай, хәер, бөтен зур шәһәр мегаполиска әйләнә. Ә авыллар? Монда тиздән авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнергә кеше калмаячак бит. Икенче яктан, авылны үстерүкүтәрү өчен, әлбәттә, газ, су, инфраструктура гына җитеп бетми, болар барысы да бар инде. Эш кирәк. Бу мәсьәләдә ниндидер аныклык, дәүләтнең аңлаешлы, төгәл алгоритмы булмый торып, глобальләшү процессын һәм милли традицияләрнең югалуын туктата алмыйсың.

МИЛЛИ АШЛАР ТУРЫНДА

Самара татарлары да Татарстанда яшәүче милләттәшләре яраткан ризыкларны үз итә. Алар туклыклы, хуш исле, итле һәм бәрәңгеле булсын. Яңа Фәйзуллада зур ит бәлешен дә, кипкән җимешле бәлеш тә, өчпочмагын да, чәкчәк, бавырсагын да пешерәләр. Тик шунысы кызык: бу ашларның исемнәре аерыла. Безнең кыстыбый аларда – якмыш. Бездә кош теле, аларда – юка. Безнең бөккән аларда кәлҗемәгә әйләнә. Татарның татлы пироглары арасында Самара өлкәсендә гөбәдия көннән-көн популярлаша бара. Яңа Фәйзулла халкы тиздән гөбәдия модасы биредә җимешле һәм дөгеле кабак бәлешенең популярлыгын узып китәчәгенә ышана. Самара гөбәдиясе, чыннан да, телеңне йотарлык.

ТАТАРЛАР ТӨРЛЕ, ПРОБЛЕМАЛАРЫ – БЕР ҮК

Шулай да без, татарлар, – гаять кызыклы халык. Дөньяның барлык почмакларында да бик дустанә яшибез, яңа тормыш рәвешенә җиңел җайлашабыз, әмма шул ук вакытта үз гореф-гадәтләребез һәм мәдәниятебезне дә саклап калабыз. Самара өлкәсе татарлары өчен дә бүген урбанлашу, милли үзенчәлекләрнең юкка чыгуы кебек проблемалар көн үзәгендә, шуңа да карамастан, алар үзләренә кадерле, якын нәрсәләрне ничек тә саклап калырга тырыша...



3

Уртак тырышлык белән иске мәчетне дә тәртиптә тоталар.



4

Иркен яланда атлар йөри...



ФИДАКАРЬ МӨГАЛЛИМ

1970 нче еллар... Шулай беркөнне Әгерҗе район башкарма комитеты рәисе янына бер кочак кәгазь күтәреп мәгариф бүлеге мөдире килеп керә. Яшь, энергияле җитәкче ул чакта ук инде югары кабинетларга үзе теләгән вакытта барып керү хокукын яулаган була.

– Менә сез үткән утырышта ветеринария табиблары һәм механизаторлар буенча аяныч саннар китереп сөйләгән идегез, – дип мөрәҗәгать итә мөдир рәискә. Анысы килешеп башын кага – әлеге проблема һәркемгә мәгълүм, системалы була, тиз арада хәл итү мөмкинлеге дә күренми.

– Мин бераз исәпләп карадым. Районның югары уку йортларына керүчеләр санын арттырырга хәленнән килә. Шул чакта белгечләребез дә җитәрлек булачак, – дип, мөдир рәис өстәленә кулындагы кәгазьләрен җәеп сала. Тәкъдиме исә мондыйрак була: барлык мәктәпләрдә капремонт үткәрергә, бик искергәннәре урынына яңа биналар төзергә, барлык уку йортларын методик материаллар һәм предмет лабораторияләре өчен җиһазлар белән тәэмин итәргә. Рәис кашын җыера:

– Ниятең җитди икән. Әмма бер нәрсәне исәпкә алмагансың: безнең күп авылда юл юк бит. Төзелеш материалларын ничек кайтартырга?

– Менә, беррәттән юл да салып булачак. Әллә кайчан кирәк иде бит инде бу! – дип киңәш бирә мөдир.

УКЫТУЧЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРОБЛЕМАСЫ

Ул чакта утопия булып тоелган әлеге проектны гамәлгә ашыруга дистә ел вакыт таләп ителә. Нәтиҗәсе исә сокланырлык булып чыга. Мәктәпләрне яңарту укучыларны хезмәткә әзерләү системасын булдырырга ярдәм итә. Әгерҗедә ике һөнәри-техник училище ачыла. Югары һәм махсус урта уку йортларына керүчеләр саны 19 процентган 76 процентка җитә. Район мәгариф бүлеге мөдире Габделхан Габдуллин исә ТАССР мәгариф министры урынбасары вазыйфасына билгеләнә.

Габделхан Габдулла улы, нинди генә урында эшләмәсен, үзенең бөтен энергиясен педагогик процессны укучы файдасына камиллләштерүгә юнәлтә. Барысы да 1960 нчы елларда башлана: яшь тарих укытучысы Әгерҗенең 1 нче урта мәктәбенә эшкә килә. Яңа тарихчының чын энтузиаст икәнен барысы да шундук аңлый. Габделхан Габдуллин үз фәнен укыту белән генә чикләнергә җыенмый. Мәктәп аның өчен сынау мәйданына әйләнә. Тарихчыны бигрәк тә проблемалы укыту ысулы кызыксындыра: дәресләрдә ул сорауларын шундый итеп бирә ки, аларга җавап табу өчен балаларга кечкенә генә эзләнү-тикшеренү үткәрергә кирәк була. Бервакыт тарихчының дәресенә проблемалы укыту мәктәбенә нигез салучылардан берсе, ул чакта ТАССР мәгариф министры Мирза Мәхмүтов керә. Габделхан Габдуллин дәресе аңарда көчле тәэсир калдыра. Министр тарихчыны мәктәп директоры вазыйфасына тәкъдим итә.

БЕЛЕМ ЛАБОРАТОРИЯСЕ

Укытучылар коллективы гына әлеге тәкъдимгә сөенми. Мәктәпнең ул вакыттагы торышы аяныч була: спорт залы юк, сыйныфлар җитешми, бинага кичекмәстән капремонт таләп ителә.

Автор: Рәис Шәйхелисламов. Фото автордан алынды. Реклама.

Өлкән педагоглар яңа җитәкченең педагогик һәм идарәче тәҗрибәсе булмавына шикләнеп карый. Яшь белгеч бу кадәр проблеманы хәл итә алырмы? Сүз уңаеннан, моңа кадәр директорлар еш алышынып торган. Коллективның бер өлешен район җитәкчеләренең хатыннары тәшкил итә. Аларның таләпләренә туры килү шактый катлаулы, ә инде ышанычын казану бөтенләй мөмкин түгел, дип санала. Әмма министр үзе тәкъдим иткән директор педагогларның потенциалын югары бәяләвен күрсәтә. Уртак максат хакына хезмәттәшлек итүгә игътибар биреп, ул тиз арада коллегалары белән уртак тел таба. Капиталь ремонт ясау, өстәмә сыйныфлар төзү өчен материаллар да табыла, кирәкле методик әдәбият һәм лаборатория җиһазлары да кайтартыла. Кыска гына вакыт эчендә мәктәп танымаслык булып үзгәрә. Берничә ел эчендә укучылар саны бер ярым тапкыр арта. Нәтиҗәдә Әгерҗенең 1 нче мәктәбе район укытучыларының квалификациясен күтәрү курслары һәм инновацион тәҗрибәләр базасына әйләнә.

БАРЫГЫЗ ДА МӘКТӘПКӘ!

Узган гасырның 90 нчы елларында Габделхан Габдуллин Казан педагогика университеты проректоры вазыйфасында хезмәт куя. Проректор сыйфатында эшли генә башлаган көннәренең берсендә ул берничә факультет профессурасы белән очрашу үткәрә. Габдуллинның аспирантларыннан берсе әлеге чарага соңга кала. Аудитория янына барып җиткәндә, ишектән йөгереп диярлек чыккан өлкән яшьтәге профессор аспирантны чак кына бәреп екмый.

– Бу нинди башбаштаклык! – дип тузына профессор, коридор буйлап атлый-атлый.

Габдуллинның шәкерте хөрмәтле мөгаллимнең тузыну сәбәбен аудиториягә кергәч кенә аңлый. Проректор университет укытучыларына хәзер аларның эш нәтиҗәлелеген бәяләгәндә практик тәҗрибә – мәктәптә үткәрелергә тиешле сәгатьләре дә исәпкә алыначагын төшендерә икән.

– Булачак мөгаллимнәрне укыту өчен, мәктәпнең асылын белергә кирәк. Бу мәҗбүри! – дип белдерә Габдуллин. Әмма әлегә аны хуплаучылар бик аз була.

Әкренләп проректор идеяләре университет коллективында яклау таба. Габдуллин таләпчән, әмма бик компетентлы җитәкче, сизгер һәм күпкырлы галим-практик абруен казана.

КИЛӘЧӘК САГЫНДА

Габделхан Габдуллинның республика мәгариф системасы үсешенә керткән өлеше, шулай ук аның яшь галимнәр әзерләүдәге фидакарьлеге хакында Татарстаннан читтә дә яхшы мәгълүм була. Бервакыт бер аспиранты кандидатлык диссертациясен якларга әзерләнә. Барысы да әзер, кирәкле оешманың бәяләмәсе генә юк. Кафедра мөдирен телефоннан шалтыратып тота алмагач, аспирант институтка үзе бара. Кафедра мөдиренең бернәрсә дә диярлек эшләмәве ачыклана. Ул чираттагы ялына китәргә җыена икән һәм бу арада гына бернәрсәне дә үзгәртә алмаячак. Диссертация яклауга исә санаулы көннәр генә калып бара. Бәяләмә юк икән – эш харап. Аспирант институт проректорыннан башка кафедра мөдирен табуын үтенә. Андый галим табыла, әмма ул, бик принципиаль булып, бәяләмәне нәкъ процедура таләп иткәнчә – өч айдан гына өлгертергә ризалаша. Берни эшләр хәл юк – аспирант кунакханәгә кайтып китә. Ни гаҗәп – кайтып керүгә үк проректор, шалтыратып, яңа мөдирнең бәяләмәне кирәкле вакытка өлгертәчәген хәбәр итә.

– Ул сезнең Габдуллин аспиранты икәнегезне белеп алган. Борчылмагыз, барысы да тәртиптә булачак, – ди проректор.

Чыннан да мөгаллим өлгерә: сыйфатлы бәяләмә дә яза, аспирантка поездга билет алырга булышып, вокзалга кадәр озатып та куя.

Габделхан Габдулла улы аспирант һәм коллегалары язмышындагы фән вә мәгарифкә кагылышлы мәсьәләләрне генә түгел, теләсә кайсы проблеманы хәл итүдә булыша. Бервакыт башка шәһәрдән күченеп килгән яшь укытучы кафедрада кызын йорты янындагы балалар бакчасына урнаштыра алмавыннан зарлана. Берничә көннән соң бакчадан шалтыратып, аның баласын кабул итәргә әзер булуларын әйтәләр. Габдуллиннарга төшке яки кичке ашка ипи белән су гына ашап яшәргә күнеккән яшь галимнәр дә еш җыйнала. Аларны һәрвакыт ачык йөз һәм тәмле сый белән каршылыйлар. Габделхан Габдулла улының хатыны Нәҗия апа пешергән искиткеч тәмле өчпочмакларны һәм башка ризыкларны күбесе хәзергә кадәр искә ала әле. Әлеге кунакчыллыкның, кече күңеллелекнең, гел ярдәмгә әзер булуның тамырлары Габделхан аганың ерак балачагына барып тоташа. Бөек Ватан сугышының беренче айларында аның гаиләсе әтисе шахтер булып эшләгән Донбасстан үзләренең Мамадыш районындагы туган йортларына кайтып урнаша. Габделханга биш яшь кенә була, әмма ул бөтен авыл халкының аларга хуҗалыкларын аякка бастырырга булышуын, бераз хәлләнгәнче һаман ризык һәм кием-салым китерүләрен мәңгегә хәтеренә сеңдерә.

ҮЗГӘРЕШЛӘР ЭСТАФЕТАСЫ

Укытучы тактага кытай иероглифларын яза. Балалар карап тора, аннары дәфтәрләренә күчереп яза. Укытучы аларга кытайча сорау бирә. Берничә бала кулын күтәрә. Яшь укытучы Ван Гуанхуа Габделхан Габдуллинга дәрес материалын тәрҗемә итә. Берничә ел элек, 1998 елда, Казанда Габдуллин җитәкчелегендә Кытайдагы халык мәгарифе үсешенә багышланган диссертациясен яклаган ул. Хәзер исә Шанхай мәктәпләренең берсендә Ван Гуанхуа Казандагы остазыннан үзләштергән идеяләрне ничек итеп тормышка ашыруын күрсәтә.

Кайчандыр аспирант булган, хәзер исә Кытай, Төркия, Йәмән һәм, әлбәттә инде, Россиянең зур галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләренә әйләнүчеләр үзләренең гыйльми җитәкчеләрен һәрвакыт хөрмәт һәм рәхмәт хисләре белән искә ала. Күптән түгел 85 яшен тутырган Габделхан Габдулла улы шәкертләре белән элемтәсен югалтмый. Ул – мәгариф тармагының һәр өч тармагында «атказанган» исеменә лаек булган бердәнбер татарстанлы. Габдуллин – РСФСРның атказанган укытучысы, РФнең атказанган югары мәктәп хезмәткәре, ТРның атказанган фән эшлеклесе.

Аның нәшер ителгән 152 фәнни хезмәтендәге күп тезис һәм идеяләре бүген, җәмгыятьтә педагогиканың роленә караш үзгәргән чорда, яңа мәгънә ала. «Яшьләрне укыту һәм тәрбияләүдән тыш, мин дәүләткә тагын ничек күбрәк һәм яхшырак хезмәт күрсәтә алам соң?» – дигән Цицерон. Габделхан Габдуллин исә боларның барысын да тормышка ашыра алган.

РАФИНАТ СӘЛАХОВНЫҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

Автор: Руфия Фазылова

Электән безгә туган-тумача тиешлеләрнең исем-фамилиясе, туган елы, һөнәрен теркәп куярга гадәтләндем. Бу миңа бик кызык иде. Кайчакта уйлыйм: тарихчы булып китәсе калган икән. Әтинең исә музыкант буласы килгән. Шулай килеп чыкты ки, аның хыялын тормышка ашырдым.

Әтием Сәлахов Ясәви Сәлах улы 1918 елгы иде. Ул Казанда атаклы гармунчы Фәйзулла Туишевтан гармунда уйнарга өйрәнгән. Фәйзулла абый үзенең фатирында дәресләр биргән. Ул чорда Туишев фамилиясен күпләр белгән, патша каршында уйнаган, бик атаклы гармунчы булган бит. Әти менә шундый олпат шәхестән дәрес алу бәхетенә ирешкән. Нәтиҗәдә, тальян, хромка гармуннарында өздереп, чын профессионалларча уйный иде. Шулай да әти иҗат юлыннан китмәгән – төрле җирләрдә хезмәт куйган. Салым инспекторы да, инженер да булган. Авылда беренче булып велосипед, мотоцикл алган кеше ул. Саба районы Юлбат авылында туган, без дә шунда яшәдек.

Әти, сугышта катнашып, чак кына исән калган кеше. Шинеленең бер чите күренеп калып, җир астыннан казып алганнар аны. Тик әти сугыш турында сөйләргә яратмый иде. Аз сүзле, кырысрак кеше булды. Шулай да минем атаклы җырчылар белән эшләвемне күреп бик сөенә иде. Турыдан-туры әйтмәсә дә, сизә идем.

Әнием Шляпина Сәлимә Габдрахман кызы – Иж-Бубый авылы кызы. Алабуга педагогика институтын тәмамлагач, аны юллама белән Саба районына эшкә җибәрәләр. Шунда кияүгә чыгып, әти белән дүрт бала тәрбияләп үстерәләр. Әнинең бабалары сәүдәгәр булган. Еракларга чыгып сәүдә иткәннәр. Сәфәрдән алар берсеннән-берсе матуррак эшләпәләр киеп кайткан. «Шляпин» фамилиясе шуннан калган. Халык аларны «Эшләпәнекеләр» дип атап йөргән.

Фото: Александр Ефремов

Иж-Бубый якларында кушаматны фамилия итеп алу очраклары бик күп.

Үземне белгәннән бирле Иж-Бубый авылына әби-бабайга кунакка кайтып йөрдем. Хәтта ике ел укырга да насыйп булды. Безнең авылда башлангыч мәктәп кенә иде. Икенче авылга йөреп укымас өчендер инде, әни, әби-бабай белән сөйләшеп, мине Иж-Бубый мәктәбенә укырга бирде. 5–6 нчы сыйныфларда Иж-Бубый мәктәбендә белем алдым. Уку татар телендә иде. Әлеге мәктәптә әнинең туганнан туган апасы Вәсимә Шляпина немец теле һәм музыкадан укытты. Матур итеп фортепианода уйный иде ул. Ике ел эчендә Вәсимә апа миңа да шактый музыка дәресләре бирде. Шунысы кызык: Вәсимә апа да гел эшләпә киеп йөрде. Аның йөзләгән эшләпәсе бар иде.

Ике елдан соң кире туган ягымда – Саба районында укуымны дәвам иттем. Сүз дә юк, Иж-Бубый мәктәбендә уку бик көчле иде. Мин анда бик күп нәрсәгә өйрәндем. Гаҗәп тә түгел, атаклы укытучыларда белем алган мөгаллимнәр иде анда. Ул якта халык гомер-гомергә аң-белем алуга зур игътибар биргән. Кызык булып истә калган: Иж-Бубыйда безнең яктагы кебек зур капкалар юк иде. Җил капка яки читән генә тотып куйганнар.

Әти минем музыка училищесында укуымны теләде. Унынчыны тәмамлагач, хәтта Казанга җитәкләп алып килде. Ул вакытта музыка училищесының директоры Ильяс Әүхәдиев иде. Әти кереп сөйләште. Тик өйгә кайткач уйладым да бер фикергә килдем – яшьтәшләрем кебек бер ел һөнәр училищесында укыйм да заводта эшлим. Тулай торактан бүлмә була, ай саен хезмәт хакы бирәләр...

Әти-әни минем бу ниятемне хупламаса да, каршы да килмәде. Шулай итеп теләгемә ирештем – Киров районында урнашкан дары заводында эшли башладым. Тик мин уйлаганча күңелле эш булып чыкмады ул – авыр капчыклар ташырга кирәк. Сменадан кап-кара булып чыгасың, күзләр генә ялтырап кала. Шунда гына әтинең хаклы булганлыгын аңладым...

Казанда ул чакта Максим Горький клубы бар иде. Шунда баянчылар клубы эшләде. Ул хакта белә идем. Аны Вәгыйзь Вәлиев дигән атаклы гармунчы оештырган. Бер ялымда шунда бардым. Һәм бер төркем баянчы, гармунчылар белән таныштым. Баян, гармун минеке икәнлеген нәкъ менә шунда аңладым.

Урау юллар аша егерме яшемдә музыка училищесына килдем. Тик бер елдан мине армиягә алдылар. Мәскәүдә хезмәт иттем. Анда да кулдан баян төшмәде – музыка взводына куйдылар. Дуэт оештырып, төрле чараларда катнаштым, оркестрда уйнап йөрдем.

Хәрби хезмәтне тәмамлап кайтып, музыка училищесында бер ел укыганнан соң, Татар дәүләт филармониясендә Габдулла Рәхимкулов төркемендә эшли башладым. Анда кереп китүем һич көтелмәгән булды – баянчылар курсында бергә укыган якын дустым Хәйдәр Сафин: «Барып кара әле, филармониягә баянчы эзлиләр», – диде. Бардым. Худсоветта тыңлап карадылар. Алдылар. Хезмәт хакы күп түгел. Тик шулай да кызык иде, әле дә сагынып искә алам.

Төрле җырчылар белән эшләргә туры килде – Зөһрә Сәхәбиева, Венера Шәрипова, Флера Сөләйманова... Тәҗрибә, өйрәнү өчен бер дигән мәктәп булган ул. Шуннан Илһам абый Шакиров белән эшли башладым. Без өч баянчы – Рамил Курамшин, Хәйдәр Сафин һәм мин – бергә уйный идек. Илһам абыйга шундый мини труппа оештырырга өстән кушканнар, дип истә калган.

Озак та тормады, Илһам абыйның әнисе мәрхүм булып куйды. Ул бик төшенкелеккә бирелде. Берничә көн эчендә чәчләре агарды. Без Хәйдәр белән өч-дүрт тәүлек бер дә аның яныннан китмәдек. Гел саклап йөрдек.

Илһам абый белән унике ел эшләргә насыйп булды. Холкы буенча катлаулы булса да, бик кешелекле дә иде. Һәрчак сүзен өздереп әйтте ул. Күп яшь җырчы, гармунчыларны, шул исәптән мине дә эшләргә, катлаулы хәлләрне ерып чыгарга өйрәтте ул. Безгә, яшь музыкантларга, аның белән сөйләшү, аралашу кызык иде.

Һәр җырга Илһам абыйның кулы кергә иде. Шуңа күрә дә аның сәхнәдәге һәрбер чыгышы музыкаль-әдәби кичәгә әйләнде. Тамашачы алдына чыккач, һәр җырына аңлатма бирә. Үзе язган кайбер җырларны халык җыры дип тә игълан итә.

Кырык яшендә Илһам абыйның 600 җыры тупланган иде. Ни хикмәт, кырык дүрт яшендә яңа җырлар алмый башлады. Яшь композиторларның ритмын кабул итмәде ул. Яңа җырларны бик сайлап кына башкарды. Илһам абый, үзенең репертуарына кире кайта-кайта, күп җырларны яңадан сәхнәгә күтәрде. Чөнки дөнья үзгәрде, күпләргә кызык-мызык, бүгенге көн белән яшәү чире кагылды. Шулай ук тормыш ритмы да үзгәрде.

Илһам Шакировның өч китабын нәшер итүдә актив катнаштым. Шушы китаплар өчен «Бәллүр каләм» дә алдым. Ул китаплар

өч телдә дөнья күрде. Инде менә дүртенче томны да чыгардык. Шулай ук Илһам абыйның җырларыннан торган ике диск эшләдем. Моның өчен чын күңелдән сөенәм дә, горурланам да.

Тормыш бормалы бит. Үзгәртеп кору елларында сәүдә эшенә дә кереп китәргә туры килде. Илһам абый лаеклы ялга киткәч, труппа таркалды. Мин РФ Мәдәният министрлыгына караган оешмага урнаштым. Сигез ел Казан белән Мәскәү арасын таптадым. Мәдәният, тарихка караган проектлар эшләдек. Шул ук вакытта «Горизонт» дигән оешмага директор урынбасары итеп тә чакырдылар. Читтән торып Казан кооперация институтын тәмамладым. Тик иҗат барыбер үзенә тартты.

Егерме еллап инде балалар белән эшлим. Дистә еллар сәхнәдә эшләү дәверендә балалар өчен дә җырлар яздым. Минем өчен ул дөнья да кызыклы иде. Укытучым, дустым, композитор Тәлгать абый Вәлиев: «Балалар өчен язган җырларың шактый, кечкенәләр күңелен аңлыйсың, син алар янында булырга тиешсең», – диде. Һәм Киров районы «Елга аръягы» балаларга өстәмә белем бирү үзәгенә җитәкләп диярлек алып килде. Шуннан кереп кителде. Бүген берничә татар мәктәбендә балаларга курай дәресләре бирәм, җырлар да өйрәнәбез.

Курай дигәннән. Беренчедән, ул музыка уен коралы, икенчедән, бронхларга тренажер да булып тора. Кеше көненә ун-унбиш минут кына курайда уйнаса да, бронхлары ныгый. Шулай булгач, еш йөткергән малай-кызларга курай менә дигән дәва чарасы да булып тора.

Тормыш баскычлар буйлап бара. Аның һәр басмасы үзенә күрә бер рәхәтлек бирә. Балалар белән эшләве бик рәхәт. Алар синең проблемаларың турында оныттыра, күңелне үстерә. Шәкертләреңнең уңышлары сине канатландыра.

Бүген җыр сәнгатендә контроль югалды. Без эшләгән чорда сәхнәгә теләсә кем менә алмый иде. Тик мин бүгенге вазгыятьнең куркыныч ягын күрмим. Ни өчен дигәндә, һәр кеше үзен сынап карый ала. Халык аны кабул итәме-юкмы – шуңа төшенә. Юк икән, сәхнәдән китә генә инде. Һәм моның шулай икәне күренә дә – бер көнлек җырчылар күп булды бит. Алга таба да булачак. Табигый сайланыш законы бар, җырчылар арасында да шулайрак дип әйтер идем.

Ике кулда ун бармак булган кебек, элек танылган җырчылар унау иде. Хәзер дә шулай алар, артык түгел. Калганнары җырлаучылар, хыялланып йөрүчеләр. Мин татар эстрадасын күзаллап әйтәм. Әлбәттә, опера җырчылары бар. Бу ике жанрны кушасым килми.

Җыр язып әле дип, махсус утырганым юк. Башка көй килә икән, тиз генә телефонга яздырып куям. Аннан инде нотага салып карыйм. Ошамаса, сыздырып атасың. Менә шулай җыелып бара. Аннары акрынлап җыр туа. Ә кайчакта көй тулысы белән килеп төшә. «Без бит Саба яклары», «Татарстан – туган илем минем» җырлары әнә шулай язылды.

Ә менә заказга дигән җырлар авыррак языла. Син анда шигырь авторына, җырчыга, аранжировка ясаучыга да ошарга тиешсең. Көй язу ул бер чир дияр идем. Ул яшькә дә, вакытка да карамый.

Бүгенге көндә бер мәртәбәле исемем дә юк. Дөрес, утыз биш яшемдә үк, Илһам абый белән эшли башлаган чагымда, атказанган артист исеме бирергә теләделәр. Документлар җыярга кушканнар иде. Тик мин баш тарттым. Соң, миңа караганда тәҗрибәлерәк, олпатрак кешеләр исемсез йөри. Алар янында ничек шундый дәрәҗәле исемне алырга кирәк?!

Рәсми рәвештә гаилә кормадым. Югыйсә тормышымда хатын-кызлар шактый булды. Минем гаиләм – туганнарым. Сеңелкәшләр, энекәшләрнең гаиләләрен, оныкларын якын күрәм. Алар да мине ярата.

Җитмеш яшь тулганын сизмим. Күрәсең, паспорт буенча яшәмим. Мин гел хәрәкәттә, күп йөрим. Сәламәтлек турында күп китаплар укыйм. Табиб туганым бар, аның белән дә гел сәламәт яшәү турында сөйләшәбез.

Егерме биш ел инде япон докторы Кацудзо Ниши системасы белән шөгыльләнәм һәм файдасын күрәм. Бик танылган кеше ул, китаплары да күп. Кызыксынган кешегә дәвалау алымнары турында интернеттан да карарга була. Әлбәттә, яшәү режимын, юнәлешен кеше үзе сайлый. Ләкин ул һәркемнең булырга тиеш. Сәламәтлеккә игътибар бирергә кирәк, картайгач кына түгел, гомер буе...

ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Рафинат Сәлахов 1951 елның 13 мартында Саба районының Юлбат авылында туа. Баянчы, курайчы, композитор, педагог, җәмәгать эшлеклесе. 1975 елдан башлап төрле җырчылар – Габдулла Рәхимкулов, Флюра Сөләйманова, Зөһрә Сәхәбиева, Таһир Якупов һәм башка бик күп җырчылар белән эшли. Уникe ел Илһам Шакировның баянчысы булып тора.
Ике йөзләп җырга көй иҗат иткән, шуларның сиксәнгә якыны – балалар һәм яшүсмерләр өчен. Халыкара һәм бөтенроссия конкурслары лауреаты.

12+

«КИТАП» ТЫҢЛА!

КИТАП МИЛЛИ радио
КАЗАН 98,6 FM

АО «ТАТМЕДИА» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2 ГРН 1071690057834

Реклама

PRESSA

«ГАУГА»лы ТӨРКЕМ

Андагы яшьләрнең берсе дә гадәти түгел иде. Егетләр – озын чәчле, кайсы толымын – зәңгәргә, кайсы кызылга буяган. Кызлар – кыска җете кызыл күлмәктән яки киң чалбарлардан. Барысының да тышкы кыяфәте истә кала торган, шуның белән бергә монда затлылык сизелә. Әйе, монда бүтән дөнья. Бирегә татар рок-музыкасын яратучылар җыелган.
Күптән түгел GAUGA* татар рок төркеме үзенең тамашачысына яңа клибын тәкъдим итте.

Автор:
Руфия Фазылова

«АҢЛАМЫЙЛАР...»

Татар рухына ят нәрсәләр бар. Рок-музыка шуларның берсе кебек. Ул дөбер-шатыр җырларны озын халык көйләре белән чагыштырып буламы соң? Ләкин заман үзгәрә... Узган гасырның илленче елларында АКШ һәм Көнбатыш Европада барлыкка килгән музыка юнәлеше тиз арада Россиягә дә үтеп керә. Җитмешенче елларда популяр булган «Сокол», «Славяне» төркемнәрен өлкән буын әле хәтерлидер. Шул гомердән бирле рок-музыканың нинди генә төрләре барлыкка килмәде. Һәм ул дөнья халыклары арасында тирән мәхәббәт яулады. Шул исәптән татарларда да.

1990 нчы еллар азагы – 2000 нче еллар башында популяр булган татар рок-музыканты, автор-башкаручы, татар альтернатив музыкасы вәкиле Альберт Исмаилне күпләр хәтерлидер. Демократия, яңалыкка омтылган чорда яңа бер дулкын булып килеп керде ул. Аның «Яшә, татар!», «Яралы мәхәббәт», «Ике пилот» җырлары мәйданнарда да яңгырады. Татар рок-музыкасы нәкъ менә шул чорда барлыкка килде дияргә кирәктер. Яңа заман җиле алып килде аны.

Егерме елдан артык вакыт эчендә бу стильдә җырлаучы яшьләр шактый күбәйде. Алай гына да түгел, төркемнәр барлыкка килде. Шулар арасында GAUGA да бар. Егетләр 2013 елдан бирле эшли һәм бүген шактый танылу алган татарча рок җырлаучы төркемнәрнең берсе. Аның җитәкчесе – Башкортостанда туып-үскән татар егете Әскәр Юнысов. Төркемнең продюсеры да, студиясе дә юк. Ләкин алар туктамый иҗат итә. Зур концертларда чыгыш ясый.

Фото: Александр Ефремов

* GAUGA - ГАУГА.

Дөрес, аларны радио, телевидениедә еш ишетеп, күреп булмый. Радиолар җырларын хәтта ротациягә дә алмыйлар, чөнки «неформат». Тик яшь музыкантлар аптырамый – бүген интернет челтәре аша да үз тамашачыңны табарга була. Алар шулай эшли дә. Ютуб-каналда үзләренең «бите» бар, анда клипларын куеп баралар, социаль челтәрләрдә актив эш алып баралар.

Яңа клипка килгәндә, җиесеме кебек үк исеме дә үзенчәлеке – «LMM». Мәхәббәт турындагы җыр чып-чын мистик фильмга әйләнгән. Әлбәттә, куелыш, аранжировка турында сүз әйтә торган түгел. Көчле музыка. Ләкин миңа, гади тамашачы буларак, егетләрнең тере тавышка тамашачы алдында җырлаулары күбрәк ошады. Алар белән бергә башларны селки-селки, бар дөньяны онытып биисе, хәрәкәтләнәсе килде...

Әскәр җыр текстларын үзе яза. Тавышы матур. Төркемдәге музыкантларның талантлары турында да әйтергә кирәк. Барысы да музыкаль белем алган егетләр. Төрле уен коралларында уйныйлар. Нәтиҗәдә уртак иҗат җимеше – тамашачыга бер урында басып торырга ирек бирми торган көчле рок-музыка туа.

– Ни гаҗәп, аннан-моннан гына гитарада уйнаучы бер авыл егете яки абзые интернетта фәлән мең карау җыя. Ә без андый зур аудиториягә үтеп керә алмыйбыз, – ди егетләр.

Миңа калса, моңа артык гаҗәпләнергә кирәкми – балетны, операны бөтен кеше аңламаган кебек, рок-музыка да аерым аудитория өчен. Ә теге үзешчән гитарист ул бит халыктан, аныкы...

Яңа клипны тәкъдир итү кичәсеннән соң, Әскәр Юнысов белән кыска әңгәмә кордык.

«ТАТАРДА РОК-МУЗЫКА БУЛЫРГА ТИЕШ!»

– Әскәр, карап торышка төркемегездә барысы да гадәти булмаган яшьләр. Озын, буялган чәчләр, киенү рәвеше... Чын рок-музыкантлар. Сезне җәмгыять ничек кабул итә? Сәер дигән караш юкмы?

– Юк, без үзебезне сәер дип санамыйбыз. Әйе, киенү рәвешебез гадәти түгелдер, җырлау да. Әмма без шул ук гади кешеләр тормышы белән яшибез.

– Рок-музыкага тартылу яшүсмер чакта башландымы?

– Туган ягым – Бөре (Бирск) шәһәрендә нигездә руслар яши. Сыйныфташ малайлар-кызлар – барысы да рок-төркемнәрдә уйнап чыкты. Бу төр музыка белән кызыксынуым шуннан китте.

– Руслар арасында үсеп тә, татарча камил сөйләшәсең. Бу гаиләдә аралашуның нәтиҗәсеме?

– Әйе. Мәктәптә татар теле укымадым дияргә була, башлангычта гына ана теле буларак атнага берәр сәгать керде. Мәктәпкә кергәнче рус телен бөтенләй белми идем, чөнки балалар бакчасына йөрмәдем. Күбрәк әби, бабай тәрбиясендә үстем. Ә алар фәкать татарча сөйләшә иде. Әти-әнием филологлар. Әти – рус филологиясе буенча фәннәр докторы, әнием – фәннәр кандидаты, татар әдәбияты буенча белгеч. Шулай булгач, мин татарчаны начар белә алмыйм. (Көлә. – Авт.)

– Казанда күптәннәнме?

– Күптән. Бөредә унбер сыйныфны тәмамлагач, документларны Мәскәүгә дә, Казанга да тапшырдым. Дөрес, этинең Оксфордта укытасы килгән иде. Нәтиҗәдә, мин КДУның ВМК факультетын сайладым. Бюджет урынга эләгә алдым. Казанга бик киләсе килде, чөнки әле профессионал рәвештә баскетбол белән дә шөгыльләнә идем. Ә монда – УНИКС. Кыскасы, хыял тормышка ашты.

– Ә Казанга килгәч, тормышыңда рок-музыка ничек пәйда булды?

– Күрәсең, ул китмәгән дә. Казанда заманча музыка ятатучы яшьләр белән аралашып киттек. Соңрак, төркем оештырдым. GAUGA – бу икенче состав. Беренче состав таркалганнан соң, яңа исем, яңа музыкантлар белән өченче ел эшлибез.

– Татарлар рок-музыканы кабул итәме? Һәм ул нинди булырга тиеш дип уйлыйсың?

– Әлбәттә, булырга тиеш. Сәнгать бит ул күптөрле.

Туган ягым Башкортостанда башкортча җырлаучы рок-төркемнәр шактый. Аларга да ул ят булырга тиеш, үзләренеке түгел бит. Тик башкортлар рок-музыканы күбрәк үз итә, аларга ул кызык. Яшьләр генә түгел, урта буын, өлкәннәр дә кызыксынып тыңлый. Татарлар ничектер аерым бер кысадан чыгарга теләми кебек.

Нинди булырга тиеш дигәндә, рок-музыканың аерым таләпләре бар. Телибезме-юкмы, без шуңа ияреергә тиеш. Юкса ул рок-музыка булмый.

Мин җырларны үзем язам. Бу турыда әйткәнем бар – татар көйләрендә үзгә бер моң бар. Текстларны язганда менә шул моң килеп баса. Шул моң миңа иҗат итәргә булыша.

– Алга планнар нинди, Әскәр?

– Алар күп, туктамаска, иҗат итәргә. Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфага гастрольләргә чыктык. Әлбәттә, барысы да акчага кайтып кала. Әле менә соңгы клипны грант акчасына төшердек. Концертлар оештыру, диск чыгару күп вакыт, акча сорый. Төп оештыру эшләре барысы да үземдә булганлыктан, шактый авырга туры килә. Ләкин бу зарлану түгел. Без эшебездән тәм табабыз, ләззәт алабыз.

...Соңыннан залдагы яшьләрне күзәттем – барысының да күзләре янып тора. Араларында рус егет-кызлары да шактый. Алар Әскәргә килеп: «Рахмат, Татарчонок», – дип кулын кысалар. Һәм әле генә яңгыраган җыр сүзләрен кабатлап йөриләр: «Кил син яныма...»

КУРОРТКАМЫ? ДИМӘК, ТАТАРСТАНГА!

Яхшы итеп ял итәргә һәм сәламәтлегеңне ныгытырга телисең икән, меңәр чакрым ераклыкка китәргә кирәкме соң? Бу сорауны без үзебезгә елына бер мәртәбә генә булса да бирәбез. Ә җавапны «Здравница–2021» Бөтенроссия форумында алдык. Татарстанның уникe шифаханәсе илнең иң яхшы шифаханәләре исемлегенә керә!

Өч меңнән артык кунак һәм катнашучы, араларында РФА академиклары, РФ Президентының Эшләр белән идарәсе түрәләре, Дәүләт Думасы сенаторлары һәм депутатлары булган 300 абруйлы спикер – башкаланың Красная Пресня яр буендагы Экспоүзәгендә оештырылган форум шундый дәрәҗәдә узды. Россия шифаханәләре казанышлары күргәзмәсендә медицина һәм курортология белгечләре хезмәт күрсәтү, савыктыру сыйфаты, кулланыла торган табигать факторларының һәм заманча технологияләрнең уникальлеге буенча иң-иңнәрне сайлап алырга тиешләр.

Лидерлар арасында көндәшлек җитди дип әйтү генә аз, көндәшлек гаять көчле иде.

Шифалы ләме һәм чыганаклары булган Төньяк Кавказ курортлары, Кара диңгез, Балтыйк буендагы, Алтайдагы шифаханәләр... Шуңа күрә абруйлы экспертлардан торган жюри тарафыннан сайлану да бик зур мәртәбә.

«ЗДРАВНИЦА-2021» БӨТЕНРОССИЯ ФОРУМЫ ЛАУРЕАТЛАРЫ:

«Бәкер» шифаханәсе:
- «Табигый дәвалау факторларын куллану буенча иң яхшы шифаханә» (алтын медаль)
- «Шифаханә-курорт дәвасының иң яхшы технологияләре» (алтын медаль)

«Ливадия» шифаханәсе:
- «Билгеле бер авыруларны дәвалауда махсуслашкан иң яхшы шифаханә» (алтын медаль)
- «Социаль әһәмияттәге чирләр белән авыручылар өчен иң яхшы шифаханә» (алтын медаль)

«Жемчужина» шифаханәсе:
- «Савыктыру ялын оештыру буенча иң яхшы учреждение» (алтын медаль)

«Шифалы су – Ижминводы» шифаханәсе:
- «Минераль суларны дәвалау-профилактика максатында куллануның иң яхшы технологияләре» (алтын медаль)
- «Гаилә белән ял итү өчен иң яхшы шифаханә» (алтын медаль)

«Ромашкино» шифаханә-профилакторие:
- «Минераль суларны дәвалау-профилактика максатында куллануның иң яхшы технологияләре» (алтын медаль)

«Ян» шифаханәсе:
- «Иң яхшы spa/wellness комплекс» (алтын медаль)
- «Һөнәри авыруларны һәм корпоратив савыгуны профилактикалау буенча иң яхшы шифаханә» (алтын медаль)

«Лениногорск» шифаханәсе:
- «Кинезитерапиянең иң яхшы тенологияләре» (алтын медаль)

«Васильевский» шифаханәсе:
- «Иң яхшы шифаханә» (көмеш медаль)

«Крутушка» шифаханәсе:
- «Табигый дәвалау факторларын куллану буенча иң яхшы шифаханә» (көмеш медаль)

«Шифалы» шифаханәсе:
- «Иң яхшы spa-технологияләр» (көмеш медаль)

«Җәлил» шифаханәсе:
- «Иң яхшы шифаханә-профилакторий» (көмеш медаль)

«Космос» шифаханәсе:
- «Медицина тернәкләндерүе буенча их яхшы шифаханә» (көмеш медаль).

СҮЗ УҢАЕННАН

«Здравница-2021» форумында катнашкан Татарстан Республикасы Профсоюзлары федерациясе рәисе, ТР Дәүләт Советы депутаты Елена Кузьмичёва форум нәтиҗәләренә йомгак ясады. «Гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту мәсьәләләренең мөһимлеген бәяләп бетерү мөмкин түгел, бүгенге көндә әлеге тема бигрәк тә актуаль», – дип билгеләп үтте ул «Татар-информ» белән әңгәмәсендә.

– Бүген республикада Россия Федерациясе шифаханә-курорт комплексын үстерү стратегиясен тормышка ашыру буенча зур эш бара, – диде Елена Ивановна. – Эшләр РФ Хөкүмәтенең 2019 елның 29 ноябрендәге күрсәтмәсенә ярашлы рәвештә башкарыла.

Мәскәүдә узган Бөтенроссия форумында Татарстан Профсоюзлары федерациясенең «Шифаханә-курорт оешмаларының иң яхшы берләшмәсе» номинациясендә алтын медальгә лаек булуы да республикада әлеге юнәлешнең никадәр уңышлы рәвештә тормышка ашырылуына саллы дәлил булып тора. Бу номинациядә Россия Федерациясе Президентының Эшләр белән идарәсенең Баш медицина идарәсе дә лауреат булды.

ТАТАРСТАН ШИФАХАНӘЛӘРЕ

«АЗНАКАЙ» ШИФАХАНӘСЕ

Ял иту, терәк-хәрәкәт аппараты, сулыш органнары һәм ашкайнату системасы, бавыр һәм үт юллары авыруларын, хроник тонзиллит, нейродермит, гинекология авыруларын, эндокрин системасы, нерв һәм һәм йөрәк-кан тамырлары системасы авыруларын дәвалау.

Адресы: Азнакай шәһәре

«БӘКЕР» ШИФАХАНӘСЕ

Ял иту, сөяк-мускул системасы, нерв системасы, гинекология авыруларын, бәвел-җенес органнары системасы, тире, ашкайнату органнары авыруларын профилактикалау һәм дәвалау.

Адресы: Лениногорск районы, Бәкер авылы

«БАЛКЫШ» ШИФАХАНӘСЕ

Ял иту, йөрәк һәм кан тамырлары авыруларын, буыннардагы авыртуларны, умыртка баганасы авыруларын кисәтү һәм дәвалау. COVID-19 авыруыннан соң тернәкләнү.

Адресы: Казан шәһәре, Петровский бистәсе

«ВАСИЛЬЕВСКИЙ» ШИФАХАНӘСЕ

Уңайлы ял, йөрәк-кан тамырлары системасы, нерв системасы, сулыш органнары авыруларын дәвалау, бәвел-җенес органнары системасын дәвалау, гинекология, гастроэнтерология, профпатология һәм эндокринология буенча программалар. COVID-19 авыруыннан соң тернәкләнү.

Адресы: Яшел Үзән районы, Васильево бистәсе

«ВОЛГА» ШИФАХАНӘСЕ

Ашкайнату, сулыш органнары авыруларын, шикәр авыруын, нерв системасы, терәк-хәрәкәт аппараты, йөрәк-кан тамырлары, гинекология һәм эндокринология авыруларын дәвалау.

Адресы: Яшел Үзән шәһәре

«ГАЗОВИК» ШИФАХАНӘ-ПРОФИЛАКТОРИЕ

Ял иту, комплекслы савыктыру программасы, тире авыруларын, урология һәм гинекология авыруларын кисәтү һәм дәвалау.

Адресы: Югары Ослан районы,
Набережные Моркваши авылы.

«ДЕЛЬФИН» ШИФАХАНӘСЕ

Ял иту, сулыш, ашкайнату органнары, терәк-хәрәкәт аппараты, нерв системасы авыруларын кисәтү һәм дәвалау.

Адресы: Яшел Үзән шәһәре

«ҖӘЛИЛ» ШИФАХАНӘ-ПРОФИЛАКТОРИЕ

Ял иту, кан әйләнеше системасы, нерв, бәвел-җенес органнары системасы, терәк-хәрәкәт аппараты, ашкайнату, сулыш органнары, гинекология, педиатрия юнәлешендәге авыруларны кисәтү һәм дәвалау. Үпкә ялкынсынуыннан (шул исәптән COVID-19 нәтиҗәсендә килеп чыкканын) соң тернәкләнү программасы.

Адресы: Сарман районы, Җәлил бистәсе

«ЖЕМЧУЖИНА» ШИФАХАНӘСЕ

Ял иту, сулыш органнары һәм ашказаны-эчәк тракты, нерв системасы, терәк-хәрәкәт аппараты, йөрәк-кан тамырлары системасы, гинекология авыруларын дәвалау.

Адресы: Яр Чаллы шәһәре

«ЗДОРОВЬЕ» ШИФАХАНӘСЕ

Кардиология һәм гастроэнтерология буенча операция кичергән пациентлар кабул ителә. Шифаханә йөклелекнең катлаулы очраклары белән эшли, неврология авыруларыннан соң тернәкләндерү уздыра.

Адресы: Әлмәт шәһәре

«ИВОЛГА» ШИФАХАНӘСЕ

Сулыш органнары авыруларын, шул исәптән вируслы пневмония кичергәннәргә тернәкләндерү үткәрә, нерв системасы, сөяк-мускул системасы авыруларына профилактика һәм дәвалау уздыра.

Адресы: Баулы шәһәре

«ШИФАЛЫ СУ – ИЖМИНВОДЫ» ШИФАХАНӘСЕ

Ял итү, ашказаны-эчәк тракты, бәвел бүлеп чыгару системасы, нерв системасы, терәк-хәрәкәт системы, җенес органнары, йөрәк-кан тамырлары системасы, тире, авыз куышлыгы, эндокринология һәм сулыш органнары системасы авыруларын кисәтү һәм дәвалау.

Адресы: Менделеевск районы, Ижевка авылы

«КОСМОС» ШТФАХАНӘСЕ

Ял итү, йөрәк-кан тамырлары системасы, терәк-хәрәкәт аппараты, матдәләр алмашына кагылышлы авыруларны, үпкәләрнең специфик булмаган хроник авыруларын, хроник тонзиллитларны, салкын тиеп еш авыручыларны, ашказаны-эчәк тракты авыруларын, һөнәри патологияләрне дәвалау.

Адресы: Алабуга шәһәре, Танай урманы

«КРУТУШКА» ШИФАХАНӘСЕ

Умыртка баганасы һәм сустав авыруларын дәвалау, йөрәк-кан тамырлары системасы авыруларын дәвалау һәм тернәкләндерү, кардиореабилитация.

Адресы: Казан шәһәре, Крутушка бистәсе

«ЛЕНИНОГОРСК» ШИФАХАНӘСЕ

Ял итү, терәк-хәрәкәт аппараты, үзәк һәм периферия нерв системасы авыруларын, йөрәк-кан тамырлары системасы, ашказаны-эчәк тракты, сулыш системасы, гинекология авыруларын, шикәр авыруын дәвалау.

Адресы: Лениногорск шәһәре

«ЯР ЧАЛЛЫ» ШИФАХАНӘСЕ

Шифаханәнең төп юнәлеше – сулыш органнары, кан йөреше, нерв, эндокринология һәм йөрәк-кан тамырлары системалары авыруларын дәвалау. Шулай ук терәк-хәрәкәт аппараты авыруларыннан интегүче пациентлар да кабул ителә.

Адресы: Яр Чаллы шәһәре

«НЕХАМА» ШИФАХАНӘСЕ

Төп юнәлешләр: йөрәк-кан тамырлары системасын, терәк-хәрәкәт аппаратын савыктыру, җәрәхәтләрдән һәм аварияләрдән соң тернәклнәу.

Адресы: Казан шәһәре, «Петровский» шифаханәсе

«ЛИВАДИЯ» ШИФАХАНӘСЕ

Кан әйләнеше системасы, сулыш органнары, эндокринология һәм нерв системасы, ашкайнату органнары авыруларын дәвалау. Урология, гинекология, травматология, һөнәри патология, офтальмология юнәлешләре буенча ярдәм. Йөрәккә, ашказаны-эчәк трактына операцияләр кичергән, шикәр авыруы белән интегүче пациентларны тернәкләндерү.

Адресы: Казан шәһәре

«ЧИЯЛЕ АЛАН» ШИФАХАНӘСЕ

Терәк-хәрәкәт аппараты, кан әйләнеше системасы, ашказаны-эчәк тракты, туберкулездан кала, сулыш органнары авыруларын, неврология, кардиология һәм эндокринология системасы авыруларын кисәтү һәм дәвалау.

Адресы: Нурлат районы, Чияле Алан авылы

«РАДУГА» ШИФАХАНӘСЕ

Ял итү, савыктыру һәм дәвалау-профилактика программалары.

Адресы: Яр Чаллы шәһәре, Наратлык

«ЯН» ШИФАХАНӘСЕ

Күп профильле. Төп юнәлешләр – терәк-хәрәкәт аппараты, йөрәк-кан тамырлары, нерв һәм эндокринология системалары, сулыш һәм ашкайнату органнары авыруларын кисәтү һәм дәвалау, иммун статусын стимуллаштыру.

Адресы: Әлмәт районы, Поташная Поляна авылы

«ЛИЛИЯ» ШИФАХАНӘСЕ

Ял итү, нерв системасы, ашкайнату органнары, терәк-хәрәкәт аппараты, йөрәк-кан тамырлары авыруларын һәм ЛОР-авыруларны кисәтү һәм дәвалау.

Адресы: Бөгелмә шәһәре

«БӘКЕР»ГӘ БАРАБЫЗ!

Гашыйклар тавы итәгендә, Чишмә елгасы тугаенда, Озын Күл үзәнлегендә меңнәрчә кешенең яратып ял итү урынына әйләнгән «Бәкер» шифаханәсе урнашкан. Бу искиткеч гүзәл урын республикабыз көньяк-көнчыгышының йөзек кашы булып тора. Биредәге уникаль дәвалау ысуллары, рәхәтлек һәм ял нәкъ менә кеше организмына шифа өчен яратылгандыр кебек.

Бирегә килергә чыкканда, бер генә нәрсәне – алдан ук юллама алып куюны кайгырту зарур. Шуны онытмасагыз иде: ел саен нәкъ менә «Бәкер»гә килергә теләүчеләр саны арта бара, чөнки ул республикада һәм хәтта илебездә дә ял итүчеләр өчен шартларны гел яхшыртуны кайгырта торган үрнәк шифаханә санала.

Бүгенге зур тизлекле заманда күпләр шуңа төшенде инде: кайвакыт, иң яхшысы исә ярты елга бер, табигатьнең дәва ресурсларыннан һәм күпьеллык курортлар традициясенә нигезләнгән заманча сихәтләндерү-савыктыру ысулларыннан файдаланып, үзеңә рәхәтләнеп ял итү мөмкинлеге бирергә кирәк. Бу җәһәттән караганда «Бәкер» – идеаль урын. Биредә табигать үзе үк сәламәтлекне кайгырта. Сирәк очрый торган сихәт үзлегенә ия җирле ләм, минераль су чишмәләре, рәсемдәгедәй күркәм ландшафт һәм искиткеч саф һава шифаханәнең табигый дәва ресурслары булып тора. Шуларга югары квалификацияле табиблар тырышлыгы да өстәлә. Болар барысы да ял итүчеләргә күп чирләрдән дәвалану мөмкинлеген бирә. Шунлыктан байтак кешенең «Бәкер»не үз итүе, бирегә ел саен әйләнеп килүе бер дә гаҗәп түгел.

ЯШӘ!

Шифаханә кесә калынлыгы төрле булган кунакларны кабул итәргә әзер. Берничә корпустан торган уңайлы комплекс җылытыла торган корылмалар системасы белән үзара тоташтырылган. Барлыгы дүрт торак корпусы төзелгән, шулардан иң уңайлысы булган «Карлыгач»та берничә лифт хезмәт күрсәтә, аш бүлмәсе дә бар. Ял итүчеләргә җайлы булсын өчен, дәвалау корпусы, бассейн һәм ашханә шулай ук барлык торак корпуслар белән җылы галереялар ярдәмендә берләштерелгән – дәваланганнан һәм процедураларда булганнан соң киенергә һәм урамга чыгарга кирәкми.

СЫЙЛАН!

«Бәкер»дә туклану «швед өстәле» һәм заказ бирелгән меню тәртибендә оештырыла. Ял итүчеләрнең табынынннан яңа өзелгән яшелчә һәм җиләк-җимеш өзелми. Килештерелгән тулы кыйммәтле менюда ризыкларның ассортименты шулкадәр зур ки, ундүрт көн дәвамында аларның берсе дә башка кабатланмый.

Чирнең төренә һәм пациентның физик халәтенә карап, дәвалаучы табиб шәхси диетик меню да билгели ала.

ХОЗУРЛАН!

«Бәкер» шифаханәсе янындагы ландшафт һәм аның үзенең территориясе ял итүчеләрне тыйнак, йомшак һәм гаҗәеп тыныч гүзәллек белән урап ала. Ул боектырмый, киресенчә, биредәге кунакларның тормыш тонусына һәм кәефенә искиткеч гармонияле тәэсир итә. «Бәкер» шифаханәсендә дәвалануның уникальлеге шунда: ул нәкъ менә бу җирлекнең үзенә генә хас сихәтләндерү ысулларын берләштерә.

Биредә шифаханә территориясендәге вольерда яшәүче боланны сыйларга, сулыкта исә балык тотарга, велосипед, самокат, роликларны прокатка алып, табигать кочагында йөрергә була. Әлеге ләззәтнең беренче сәгате өчен хәтта түләргә дә кирәкми.

Фотолар «Бәкер» шифаханәсенең матбугат хезмәтеннән алынды. Реклама.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

Чыныгырга яратучыларга сероводородлы салкын суда коену һичшиксез ошаячак. Һәм әле бөтен җирдә эчәргә яраклы шифалы су эчеп була.

СИХӘТЛӘН!

«Бәкер» шифаханәсендә 7 табигый фактор – 7 могҗиза белән дәваланып була:

– сапропель ләме белән дәвалану хәзерге даруларга караганда күпкә нәтиҗәлерәк санала;

– югары минераллашкан сероводородлы су;

– ашказаны-эчәк трактын дәвалау өчен эчәргә яраклы аз минераллашкан су;

– җир астыннан чыгарылган зәңгәр балчык;

– урология чирләрен дәвалау өчен аз минераллашкан эчәргә яраклы «Бәкер» суы;

– эчәргә яраклы табигый «Бәкер» суы;

– табигать һәм һава шартлары.

Болар барысы да бергә шифаханәдә сөяк-мускуллар, бәвел-җенес, нерв системалары авыруларын, урология һәм гинекология чирләрен, ашкайнату әгъзалары һәм тире авыруларын уңышлы дәвалау мөмкинлеген бирә.

Шифаханә балага уза алмауны уңышлы дәвалавы белән дә танылган. Белгечләр сайлап билгеләгән урология һәм гинекология программалары гаять күп гаиләгә ата-ана булу бәхетен татырга насыйп иткән.

Табигый компонентларны һәм алдынгы медицина технологияләрен куллану дәвалауның нәтиҗәле булуын тәэмин итә. Моңа шифаханәдә аерым игътибар бирелә. Шифаханә иң заманча дәвалау-савыктыру һәм диагностика аппаратлары белән җиһазландырылган.

Шифаханәнең уникаль дәвалау нәтиҗәләрен илдәге курорт тармагы белгечләре югары бәяли. Июньдә үткән «Здравница-2021» XX Бөтенроссия форумында «Бәкер» медиклары коллективына «Шифаханә-курорт дәвасының иң яхшы технологияләре» һәм «Табигый дәвалау факторларын куллану буенча иң яхшы шифаханә» номинацияләрендә берьюлы ике медаль бирелгән.

ҺӘМ ТАГЫН...

Лазер, магнит, озон белән дәвалау, физиотерапия, фитотерапия, ароматерапия, гидроколонотерапия, эрбет (кедр) мичкәсе, инфракызыл сауна, коры углерод ванналары, карбокситерапия, прессотерапия, асыл болан мөгезе (пант) ванналары, «Акватракцион» гидромассажы, спелеокамера, криосауна, кул белән массаж ясау, су асты душы массажы, массаж кәнәфие, медикаментоз терапия, бит һәм тән тиресен карау буенча гаять күп төрле SPA*-процедуралар – шифаханәдә ял итүчеләр боларның барысыннан да файдалана ала.

«БӘКЕР»ГӘ НИГӘ БАРЫРГА:

- ✓ Сәламәтлекне ныгытырга
- ✓ Искиткеч табигать күренешләре белән хозурланырга
- ✓ Күркәм, чиста территориядә рәхәтләнеп сәйран кылырга
- ✓ Чишмәләрдән сихәтле минераль су эчәргә
- ✓ Шифаханәнең мини-зоопаркында сирәк очрый торган хайваннар һәм декоратив кошларга карап сокланырга
- ✓ Лениногорскидагы һәм Шөгердәге нефть музеена барырга – бу искиткеч кызыклы экскурсия булачак
- ✓ Балык тотарга, ял итәргә һәм, ниһаять, туйганчы йокларга

Ял итәргә вакыт җитте түгелме? Сезгә хәл итәргә!

тел.: 8 800 200 69 23
www.bakirovo.com

* СПА.

PRESSA

КАЗАНСУ БУЕНДАГЫ ҖӘННӘТ ПОЧМАГЫ

Грек теленнән «Ливадия» сүзе «җәннәт почмагы» дип тәрҗемә ителә. Һәм бу һич тә арттыру түгел. Шифаханә шәһәр ыгы-зыгысыннан Казансу елгасы тугайлары һәм Троицкий урманы аерып торган искиткеч матур урында урнашкан. Саф һава, шифалы су, шулай ук уңайлылык, дәвалау программалары һәм ял иттерә, көч арттыра торган процедуралар «Ливадия» турында сәламәтлек оазисы дип сөйләргә нигез бирә.

ИҢ ЯХШЫ ШИФАХАНӘ

«Ливадия» шифаханә-курорт дәвалау эше традицияләрен инде күп еллар буе саклап килә. Бүген бу тырышлыкның нәтиҗәләрен ял итүчеләр һәм пациентлар гына түгел, экспертлар да билгеләп үтә. Әйтик, быел июнь аенда Мәскәүдә узган «Здравница-2021» XX Бөтенроссия форумында да «Ливадия»нең казанышлары югары бәя алган. Жюри шифаханәне берьюлы ике алтын медаль белән бүләкләгән – «Билгеле бер авыруларны дәвалауда махсуслашкан иң яхшы шифаханә» һәм «Социаль әһәмияттәге чирләр белән авыручылар өчен иң яхшы шифаханә» номинацияләрендә.

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ПРОФИЛЬ

– «Ливадия»дә төрле авырулардан шифаханә-курорт дәвасын алырга мөмкин. Шул ук вакытта безнең шифаханә – хроник күз авыруларын дәвалый торган аз санлы санаторийлардан берсе. Бу – безнең үзенчәлегебез һәм өстенлегебез, илнең башка шундый учреждениеләреннән «Ливадия»не аерып торган сыйфат, – дип сөйли шифаханәнең баш табибы, КДМАның офтальмология кафедрасы доценты, Татарстанның атказанган табибы һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының шифаханә-курорт дәвасы буенча штаттан тыш баш белгече Фәрит Әүхәдулла улы Галимуллин.

Хроник күз патологияле (күрү нервының өлешчә атрофиясе, макулодистрофия (коры формада), глаукома, челтәр катлам дистрофиясе булган) пациентлар өчен «Ливадия»дә «Күз сәламәтлеге» дигән махсус программа эшләнгән. Аңа төрле хезмәтләрнең һәм дәвалау процедураларының киң комплексы, шулай ук тәҗрибәле офтальмологларның консультацияләре керә.

«Ливадия»дә берничә төрле савыктыру программасы эшли, шуңа күрә бирегә сәламәтлеге өчен файдалы ял уздырырга теләгән һәркем үзенә туры килгәнен сайлый ала: «Сәламәт арка» яки «Сәламәт буыннар» булсынмы, «Коронавирус (COVID-19)

Фотолар «Ливадия» шифаханәсе – профсоюзларның дәвалау-профилактика хосусый оешмасыннан алынды. Реклама.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



һәм балалар мәйданчыклары, кинозал һәм конференц-зал, ябык бассейн һәм берничә төрле сауна... Заказлы меню нигезендә, кирәкле балансларны исәпкә алып, дүрт тапкыр ашату каралган. «Ливадия»дә яшәү, рухи һәм физик көчләрне яңадан торгызу өчен бөтен уңайлыклар бар.

Теләк булганда, шифаханәнең мәдәни-ял программаларын көн саен Татарстан башкаласында уза торган төрле чаралар белән дә тулыландырырга мөмкин. Чөнки бар җанга тынычлык биргән җәннәт почмагыннан машинада, шәһәр транспортында яки электричкада егерме минут эчендә мегаполисның энергия бәреп торган дәртле шау-шуына чума аласың. Әйе, «Ливадия»дә ял әнә шундый да булырга мөмкин!

инфекциясен кичергән пациентларны тернәкләндерү» яки «Гастроэнтерология»ме яисә «Шикәр диабеты» программасымы. Ә бәлки «Детокс+» яки «Синең идеаль фигураң» юнәлешен сайларгадыр?

ТЕРЕ СУ ҺӘМ... ЛӘМ

«Ливадия»дә һәрнәрсә диярлек дәвалый. Саф һавасы да, җанга тынычлык бирә торган табигать манзаралары да, кошлар сайравы да. Әмма бу урын бигрәк тә үзенең минераль суы белән дан казанган. Ул санаторий территориясендәге ике скважинадан суыртыла. 185 метр тирәнлектән чыга торган эчәргә яраклы су сульфат тозларга, магний-кальций ионнарына бай, ул ашказаны-эчәк тракты һәм гепатобилиар система авырулары вакытында файдалы.

Икенче скважинадан – 495 метр тирәнлектән! – «Ливадия»дә составында йод, бром, күкертле водород булган хлоридлы-натрийлы эремә чыгарыла. Ул матдәләр алмашы бозылуны, йөрәк-кан тамырлары һәм нерв системалары, терәк-хәрәкәт аппараты авыруларын дәвалау һәм кисәтү өчен кулланыла торган минераль ванналарга салына.

Алай гына да түгел әле! Шифалы судан тыш, «Ливадия»дә Сак күленең ялкынсынуга каршы тору, авыртуны басу һәм яраны төзәтү үзлегенә ия сульфидлы ләмен дә актив кулланалар.

УҢАЙЛЫ ЯЛ

Өч кунакханә, ике йөздән артык уңайлы номер, җәяү йөрү һәм йөгерү өчен иркен парк зонасы, ачык спорт

Фәрит Әухәдулла улы Галимуллин, шифаханәнең баш табибы, КДМАның офтальмология кафедрасы доценты, Татарстанның атказанган табибы һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының шифаханә-курорт дәвасы буенча штаттан тыш баш белгече.

«Ливадия» шифаханәсе - профсоюзларның дәвалау-профилактика хосусый оешмасы
Казан, Себер тракты, 43
Тел.: 8-800-350-28-30 (шалтырату бушлай),
+7 (843) 237-60-30;
e-mail (бронь бүлеге)
livadia_crm@mail.ru
www.livadiakazan.ru
Instagram: @livadia_kzn

«ИЖМИНВОДЫ»: ШИФАЛЫ СУ КУРОРТЫ

Составы ягыннан уникаль булган су белән сәламәтлекне ныгыту өчен, һич тә Эвиан-ле-Бен яки Вишига барырга кирәкми. Татарстанның Ижевка авылында да Франция курортларының минераль чишмәләренә тиңләшерлек су белән менә дигән дәвалыйлар.

ДӘВАЛЫЙ: СУ...

Савыктыру үзлегенә ия шифалы су өчен бирегә, «Шифалы су – Ижминводы» шифаханәсенә, бөтен илдән киләләр. Химик составы буенча ул хлоридлы-сульфатлы-магнийлы-кальцийлы-натрийлы су санала. Мондагы су чып-чын могҗизалар тудыра: организмда эшләнеп чыга торган үтнең сыйфатын яхшырта, эчәклектә майларның, кальцийның һәм майда эри торган витаминнарның үзләштерелүенә ярдәм итә, бавырны саклау үзлегенә ия, майларның, углеводларның һәм бәвел кислотасының метаболизмына булыша.

Кыскасы, «Шифалы су» ашкайнату тракты, бәвел бүлеп чыгару һәм нерв системалары авыруларыннан, метаболизм һәм пародонтологиягә бәйле проблемалардан арынырга теләүчеләрнең барысына да киңәш ителә.

Шифаханә территориясендә, минераль судан тыш, 1993 елда бер чакрымга якын тирәнлектә йод-бромлы эремә табыла, башка минералларга да бай әлеге су составы ягыннан Кызыл һәм Үле диңгез суына охшаш. Шифаханә табиблары аны күп авыруларны дәвалаганда уңышлы куллана.

ҺАВА...

Санаторий территориясендә һава бераз гына сыеграк, анда аэроннар күп. Камил ял шундый була ул: хәтта болай гына йөреп кергәндә дә савыгасың. Чулман елгасының биек ярындагы матур болыннар һәм нарат урманнары кочагында урнашкан шифаханәне аеруча үз итүчеләр булуы гаҗәп тә түгел, араларында биредә 20 шәр, 40 ар тапкыр ял итүчеләр бар.

РИЗЫК ҺӘМ ХӘРӘКӘТ...

Яңа җиһазлар, ачык төстәге ашъяулыклар, ап-ак савыт-саба, махсус киемле официант кызлар ашханәгә затлы ресторан төсмере бирә. Һәр өстәлдә меню ята, ял итүчеләр иртәнге, төшке һәм кичке ашларга заказ бирә ала.

Волейбол һәм баскетбол буенча турнирлар, өстәл теннисы, бассейн, тренажерлар залы – көч-куәтне кайтару һәм организмны ныгыту актив ял, җәяү йөрү, массаж, физиотерапия, шифалы су һәм ләм белән дәвалау, магнит терапиясе белән бергә традицион дәва ысулларын оста файдалану аша да башкарыла. Шифаханә тәкъдим иткән процедуралар кунакларның физик саулыгын гына түгел, ә рухи халәтен дә савыктыруга исәпләнгән.

«Ижминводы» шифаханәсендә сез организмны гомуми, профилактик савыктыру курсы уза аласыз яисә, ял көне турын сайлап, бирегә бөтен гаилә белән килергә дә мөмкин – ял һәм дәвалауның югары сыйфаты гарантияләнә. «Здравница-2021» XX Бөтенроссия форумының «Гаилә белән ял өчен иң яхшы шифаханә» һәм «Минераль суларны дәвалау-профилактика максатларында куллануның иң яхшы технологияләре» номинацияләрендә «Ижминводы» коллективының алтын медаль белән бүләкләнүе һич тә очраклы түгел.

ФАЙДАЛЫ ВАКЫТ

Табигый минераль сумы әллә сыйфатлы хезмәт күрсәтүме, югары квалификацияле табиблармы яки саф һавамы, өр-яңа медицина җиһазларымы әллә сәламәтләндерүнең классик алымнарын куллануы – санап үтелгәннәрдән «Шифалы су – Ижминводы» шифаханәсен кайсы аеруча танытуын әйтү дә кыен. Әмма биредә уздырылган вакытның сәламәтлек өчен иң файдалы вакыт икәнлеге бәхәссез!

Сату бүлеге телефоны: 8-800-500-8692
igminmarketing@mail.ru
Тел.: 8 (85549) 3-69-16
Сайт: http://ижмин.рф

Фото «Шифалы су – Ижминводы» шифаханәсенең матбугат хезмәтеннән алынды. Реклама.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

Мәңгелек кыйммәтләр

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Империянең соңгы мөфтие **КЕМ** булган

2021 елда **НИНДИ** яңа китаплар чыккан

КАЙДА үз бәһаләрен белеп яшиләр

Борынгы кулъязмалар **НИНДИ** серләрне саклый

ИМПЕРИЯНЕҢ СОҢГЫ МӨФТИЕ: МӨХӘММӘТСАФА БАЯЗИТОВ

Автор: Илдус Заһидуллин

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар милләте язмышында бик зур үзгәрешләр чоры булып тарихка керә. Традицион җәмгыять яңарыш кичереп, анда европача белемле, карашлы милли зыялылар катламы формалаша. Крестьян, мулла, сәүдәгәр һәм дворяннар катламнары вәкилләреннән торган бу элита милләт үсешенең идеологиясен билгеләгән иң йогынтылы көчкә әверелә.

Мөхәммәтсафа Баязитов тарихка империянең соңгы мөфтие, Мәхкәмәи шәргыянең сугыш чоры рәисе буларак кереп кала.

ГАТАУЛЛА АХУН УЛЫ

Мөхәммәтсафа Баязитов 1877 елның 12 декабрендә Санкт-Петербург каласының Касыйм татарларын берләштергән 2 нче мәхәллә мулласы һәм бер үк вакытта Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаменты чиновнигы, төрки телләр тәрҗемәчесе Гатаулла Баязитов (1846–1911) һәм Бибигазизә Сәйфелмөлек кызы гаиләсендә дөньяга килә. Гатаулла хәзрәт Мойка урамындагы 22 нче йортта яши. Фатирның бер бүлмәсендә касыйм татарлары җомга намазына җыела торган була. Мөхәммәтсафа шул намазларда катнашып, дин кардәшләре белән аралашып үсә.

Башлангыч белемне, этисе мәктәбендә алган, төпле дини белемне Казанда Галимҗан Барудиның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә үзләштергән. 1901 елда Мәхкәмәи шәргыядә имтиханны уңышлы тапшырып, имам-хатиб дини дәрәҗәсенә ия була.

Мөхәммәтсафа 1900–1903 елларда Я.Г.Гуревичның шәхси гимназиясендә русча укый. Санкт-Петербург университетының Көнчыгыш факультетына укырга кергән 1903 елның август аенда сәүдәгәр Рахмәтулла Халитовның кызы Зөләйхага өйләнә. Ул университеттә яхшы укучы студентлар санында йөрми: өйләнү матди хәленә дә, вакытын дөрес файдалануга да йогынты ясаган, күрәсең. Яшь гаиләнең бер-бер артлы балалары дөньяга килә: Ләйлә, Вәлидә, Сара, Искәндәр. Университетта сигез семестр укуына карамастан, Мөхәммәтсафа бер имтихан да бирмәгән: аны вакытында акча түләмәгән өчен имтиханга кертмәгәннәр, акча түләгәч, кабат укырга алганнар.

1911 елда этисе Гатаулла ахун вафат булгач, Мөхәммәтсафа университетта укуын калдыра.

Гатаулла Баязитов – татар матбугатының беренче карлыгачы булган «Нур» газетасының нәшире һәм мөхәррире. Газетаның тәүге саны 1905 елның 2 сентябрендә дөнья күрә. 1908 елдан газета Баязитовларның шәхси типографиясендә басыла. Газета башта атнага бер, күпмедер вакыттан соң берничә санда дөнья күрә. Мөхәррирлек эшендә Мөхәммәтсафа этисенең аркадашы була, газетада мәкаләләр белән дә катнаша.

БАШКАЛАНЫҢ 2 НЧЕ МӘХӘЛЛӘСЕ АХУНЫ

Гатаулла ахун күләгәсендә йөргән Мөхәммәтсафа, этисе вафатыннан соң 1911 елның 12 июнендә 2 нче мәхәллә имам-хатибы һәм мөдәррисе итеп билгеләнгәч, иҗтимагый чараларда ешрак күренә башлый.

Мөхәммәтсафа 1912 елның 27 апрелендә ахун итеп билгеләнә. 1913 елны «Санкт-Петербургта җәмигъ мәчетен төзү комитеты»нда этисе урынын ала.

Санкт-Петербургтан Уфага күченгәнче, елына 600 сум хезмәт хакы алып хәрби уку йортла-

Фотолар автордан алынды

рында һәм Ксенинский кызлар институтында ислам дине нигезләрен укыта.

Мөхәммәтсафаның исеме ил күләмендә беренче тапкыр Романовлар династиясенең 300 еллыгына багышланган тантаналы чараларда яңгырый. Әле төзелеп бетмәгән җамигъ мәчетен ачу тантанасында, 1913 елның 21 февралендә, илнең төрле почмакларыннан чакырылган 100 мөселман җәмәгать эшлеклесе, шулай ук яраннары белән Бохара әмире Сәед Әмир-хан, Хива ханы Сәид Әсфәндияр Баһадур-хан, Дәүләт думасы депутатлары һәм башка мөхтәрәм шәхесләрнең җәмәгать намазы Мөхәммәтсафа җитәкчелегендә укыла. 22 февраль көнне Мөхәммәтсафа ахунны, сәүдәгәрләр Фатыйх Бәйрәшевны һәм Хәбиб Янишевны, тантанага килгән мөселманнарның вәкилләре буларак, император Николай II үзе кабул итә. Империянең сәяси тормышында бу чара бик югары хөрмәт билгесе санала.

1914 елның маенда Уфадан мөселманнар эшләренә багышланган хөкүмәт киңәшмәсенә килгән казый Гыйниятулла Капкаев, русча яхшы сөйләшә алмау сәбәпле, аңа тәрҗемәче итеп Мөхәммәтсафа Баязитовны чакыралар. Бу факт империя хакимиятенең Мөхәммәтсафага ышанычын күрсәткән дәлил булып тора.

1914 елның ноябрендә эчке эшләр министры Мөхәммәтсафаны башкала җамигъ мәчетенең имам-хатибы итеп билгели.

1911 елның 21 апрелендә, Гатаулла ахун вафатыннан соң, «Нур»ның нәшире һәм мөхәррире булып Мөхәммәтсафа кала. Бу елларда газетаның басылу ешлыгы азая, башка шәһәрләрдә дә вакытлы матбугат оешканга һәм мәсләге консерватив булганга, аның әбүнәчеләре һәм авторлары саны кими. Аның соңгы – 310 нчы саны 1914 елның 26 июнендә дөнья күрә. Шулай да «Нур» газетасының 10 ел дәвамында басылып килүе татар мәдәнияте һәм басма сүзе өчен әһәмиятле вакыйга була.

Мөхәммәтсафа 1914 елда Тышкы эшләр министрлыгының сәяси бүлегенә тәрҗемәче булып эшкә урнаша. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Петроград хәрби округында хәрби мулла штаты кертелә. Башкала гарнизонына хәрби мулла итеп 1915 елның 26 маенда 2 нче мәхәллә ахуны Мөхәммәтсафа Баязитов билгеләнә.

1914 елның 6–11 декабрь көннәрендә Петроградта мөселман җәмәгать оешмаларының Россия күләмендә съезды уза. Аның эшендә катнашкан ахун Баязитов тиз арада казна хисабына фронттагы һәрбер дивизиягә кимендә бер хәрби мулла билгеләү турында тәкъдим кертә. Хакимият бу тәкъдимне ишетә. Бик тиздән Хәрби министрлык 10 хәрби мулла штаты булдыра.

МӨФТИ ИТЕП БИЛГЕЛӘНҮ ТАРИХЫ

1912 елда Мөхәммәдьяр Солтанов бик нык авырый. Мөфтинең өлкән яшьтә булуы вакытлы матбугатта яңа мөфти кандидатурасы турында фикер алыша башлауга сәбәп була. 1912 елда Казанда нәшер ителә торган «Йолдыз» газетасы бу җаваплы вазыйфага лаеклы кандидатлар дип Ризаэтдин Фәхретдинне, абыйлы-энеле Садри һәм Әхмәтһади Максудиларны атый. 1914 елда Солтанов тагын урын өстенә яткач, мөфти сайлау темасы матбугат битләреннән төшми.

1914 елда Санкт-Петербургта сәүдәгәр Фатыйх Бәйрәшев җитәкчелегендә консерватив рухлы мөселманнар төркеме, шул исәптән генерал Шәйх-Али, Мөхәммәтсафа Баязитов, «Сыйрат эл-мөстәкыйм» («Тугры юл») исемле Бөтенроссия мөселман халык союзы уставын теркәргә алына. Уставта оешманың максаты – мөселманнар арасындагы «сул» сәяси агымнарга каршы тору дип игълан ителә һәм аның нигезенә рус карагруһ «Рус халкы союзы»ның оештыру документлары алына. Устав, шулай ук, мөселманнарның дини-мәдәни тормышын оештыруны да күздә тота. Сүз хаҗ оештыру, мәчетләр төзергә ярдәм итү, урта һәм башлангыч дини һәм дөньяви мәктәпләр, китапханәләр ачу, китаплар һәм газета-журналлар бастыру, мохтаҗларга матди ярдәмгә күрсәтү h.б. турында бара.

Чиновниклар, сәяси яктан Николай II не яклаган бу карагруһ оешманың ил күләмендә иҗтимагый эшчәнлек алып барачагын уйлап, аның мөселманнарны берләштерәчәк институтка әверелүеннән һәм алар арасында сепаратизмның көчәюеннән шикләнә. Киләчәктә составы һәм җитәкчелеге алмашынган очракта, империя структураларында аның төбәк оешмаларын күзәтерлек компетентлы шымчылар булмауны һәм мөселманнарның бердәм һәм яшертен эш йөртүләрен исәпкә алып, иҗтимагый оешманы япкан очракта да, аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә оешкан мөселманнар союзы калачак, дигән фикер әйтәләр. Нәтиҗәдә устав теркәлми, союз оешмый кала.

Күпчелеге либерал карашлы шәхесләрләрдән торган татар зыялылары һәм Дәүләт думасы депутатлары, бу карагруһ иҗтимагый оешма уставы турында ишеткәч, аны оештыручыларга каршы чыга.

Мөхәммәдьяр Солтанов вафатыннан соң империя хакимиятенең яңа мөфти эзләү юнәлешендәге эшчәнлеген игътибар белән күзәткән җәмәгатьчелек, бу урынга карагруһ «Сыйрат эл-мөстәкыйм» оешмасын төзүчеләрнең берсе булган Мөхәммәтсафа Баязитовны куярга җыенганнарын белгәч, сагаеп кала. Татар вакытлы матбугатында Баязитовка каршы бик көчле тәнкыйть кампаниясе башланып китә. Киң җәмәгатьчелектә карагруһчы мөфти образы формалаштырыла.

Мөхәммәдьяр Солтанов 1915 елның 12 июнендә вафат булгач, мөселманнар эчке эшләр министрына мөфти кандидатурасын ачыклау өчен җыелыш уздырырга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итә. Рөхсәт бирелмәсә дә, мөф-



1

2

тилеккә җәмәгатьчелек тарафыннан тәкъдим ителгән затлар арасында дөньяви белемле шәхесләр булуы игътибарны җәлеп итә. Төрле елларда Дәүләт думасы депутатлары булган Садри Максуди, Сәетгәрәй Алкин, депутат Гайсә Еникиев, шулай ук хәрби Габделгазиз Дәүләтшин исемнәре атала.

1915 елның 28 июлендә Мөхәммәтсафа Баязитов мөфти итеп билгеләнә. Дәүләт думасының мөселманнар фракциясе депутатлары моңа бердәм каршы чыга. Протестның икенче сәбәбе дә була. Алар меңләгән дин кардәшләре солдат шинелендә император һәм Россия дәүләте өчен кан койганда империя хакимиятенең, алар белән киңәшмичә, җәмәгатьчелек арасында тискәре имиджы булган һәм мөселманнар хуп күрмәгән шәхесне мөфти итеп куюына гарьләнә.

СУГЫШ ЧОРЫ МӨФТИЕ

Мөхәммәтсафа мөфти яңа вазыйфасын, алтын урталыкны табып, татар либераллары белән хезмәттәшлек итеп оештыра. Башкача булдыра да алмый, чөнки милләтнең идеологиясе һәм башка йогынты ясау инструментлары алар кулында. Бу хезмәттәшлекнең тагын бер мөһим нәтиҗәсе татар либералларының да, шулай ук Дәүләт думасы депутатларының да, хөкүмәткә һәм Николай II гә оппозиция булудан туктап, сугыш барган вакытта «дошманны җиңгәнче» хакимият белән кулга-кул тотынып эшләү хакында килешүләре була.

Яңа мөфтинең күпчелек нәсихәтләре һәм карарлары сугыш белән бәйле. Әйтик, Уфа губернасына сугыш барган төбәкләрдән 100 мең кеше күченәчәге билгеле булгач, Баязитов, 1915 елның 29 сентябрендә имамнарына мөрәҗәгать итеп, качакларның нинди дин тотуларына карамастан, яңа урында урнаштыруда ярдәм итүләрен үтенә. 1915 елның февралендә поплар чиркәүләрдә сугышка киткән солдатларының гаиләләре файдасына акча җыю кампаниясе уздыра. Мөфти 30 сентябрьдә Оренбург губернасы имамнарына мәчетләрдә сәдака җыюны оештыру турында фәрман юллый.

Мөфти Баязитовның зур хезмәте дип Уфада 1911 елда ябылган «Мәгълүматы Мәхкәмәи шәргыя Ырымбургия» исемле айга бер тапкыр чыга торган журналны 1916 елның 1 гыйнварыннан кабат нәшер итә башлауны атарга кирәк. 1917 елның 12 сентябренә кадәр басманың 25 саны чыгып кала.

Сугыш башлангач мөселман руханиларының армиядән калу хокукы саклана. Хакимият 1916 елда Халык мәгарифе министрлыгы карамагындагы башлангыч рус мәктәпләре һәм чиркәү мәктәпләре укытучыларын армиягә барудан азат итә. Бу хакта ишеткәч, мөфти дә мәктәп-мәдрәсә укытучыларына ташлама алу артыннан йөри башлый. Ахыр чиктә, хөкүмәт мөселманнарның теләкләрен өлешчә канә-

гатьләндерә: элек хәрби хезмәттә булып, 40 яшьтән өлкән мөгаллим-мөдәррис, укытырга 1916 елның 4 июленә кадәр урнашкан булса, сугышка барудан азат ителә.

Баязитовның бик күп вакытын сугышка мобилизацияләнгән мөселманнарның дини ихтыяҗларын җайга салуны оештыру ала. Хәрби частьләрдә муллалар билгеләүгә ирешә. 1915 елның июненнән 1916 елның июненә кадәр фронтка 30 хәрби мулла билгеләнә.

1916 елның 22 июнендә Мөхәммәтсафаны Николай II кабул итә. Шул ук елны Баязитов 2 нче дәрәҗә Станислав ордены белән бүләкләнә.

1916 елның җәендә хөкүмәттә рухани шәһадәтнамәсе булган солдатларны дивизия һәм бригада хәрби муллалары итеп күчерү мәсьәләсе тикшерелә. Император Николай II нең 15 июль Указы белән дивизияләрдә хәрби мулла штаты кертелә. Ярты ел эчендә бу урыннарга 12 кеше билгеләнә.

Сугыш шартларында солдатларга бергә җыелып намаз укуны оештыру бик сирәк күренеш була. Мөфти тырышлыгы белән 1915 елны Гает көннәрендә, 24 сентябрьдә һәм 24 декабрьдә армиядә җәмәгать намазлары уздырырга рөхсәт алу мөселман җәмәгатьчелеге тарафыннан зур вакыйга дип кабул ителә.

1917 елның 8 февралендә Баязитов Уфадан Петроградка кузгала. «Вакыт» газетасы мәгълүматларына караганда, фронттан килгән шикаятьләр нигезендә мөфти мөселман солдатларын православие догаларын укырга мәҗбүр итү фактлары турында хәбәр итү, аларга дини йолаларны үтәргә мөмкинлек булдыру, дивизия хәрби муллаларының яшәү һәм хезмәт шартларын яхшырту, тылдагы солдатларның да дини ихтыяҗларын канәгатьләндерү, солдат балалары өчен мөселман приютлары һәм хәйрия оешмалары төзү турында сөйләшергә җыена. Әмма соңга кала. Петроградта революция башлана, озак та үтми Николай II тәхеттән ваз кичә.

1917 елның 9 мартында Мөхәммәтсафа Баязитов руханиларга Россиядә хакимиятнең Вакытлы хөкүмәт кулына күчкәнен хәбәр итә. Муллаларны һәм мөселманнарны, Ватан алдында бурычларын онытмыйча, һәркем үз урынында илгә тугры хезмәт итәргә һәм җәмәгать тәртибен сакларга өнди. Муллаларга җомга һәм Гает көннәрендә, падишаһ һәм аның нәсел-нәсәбе исәнлегенә укыла торган догаларын үзгәртеп, Ватанның тынычлыгы һәм бәхете, шулай ук Вакытлы хөкүмәтнең иминлеге өчен дога кылырга кушыла.

БАЯЗИТОВНЫҢ СОВЕТ ЧОРЫНДАГЫ ЯЗМЫШЫ

Февраль революциясе җиңгәч, Мөхәммәтсафа мөфти, яңа хакимият – Вакытлы хөкүмәтне котлап, Петроградка телеграмма суга. Аннары үзе гариза язып, Вакытлы хөкүмәтнең 1917 елның 22 март фәрманы белән мөфтилектән төшерелә. Беркадәр вакыт үз йортында сак астында тотыла.

1917 елның 1-11 май көннәрендә Мәскәүдә булган Бөтенроссия мөселманнары съезды сайлаган Башкарма комитет 12 июньдә, Вакытлы хөкүмәткә мөрәҗәгать итеп, Баязитовның Петроградта хәрби мулла ярдәмчесе итеп билгеләнүенә протест белдерә.

1918 елда Мөхәммәтсафа беркадәр вакыт Петроградның җәмигъ мәчетендә мулла булып тора. Руханилыктан чыгарылгач, гаиләсен туендыру өчен, көндез Акча сугу йортында эшли, төннәрен вагон бушата.

Баязитов 1920 нче еллар башында Казанга күченә, бер авылда мулла вазыйфасын башкара.

Кайбер мәгълүматларга караганда, 1923 елда мөфти Ризаэтдин Фәхретдин, совет хөкүмәтенә мөрәҗәгать итеп, Мөхәммәтсафа Баязитовка гаиләсе белән чит илгә китәргә рөхсәт бирүне үтенә. Совет хакимияте Баязитовның үзенә генә Төркиягә китәргә рөхсәт итә, әмма ул гаиләсен – хатынын һәм биш баласын язмыш кочагына калдырып китүдән баш тарта.

Ул 1930 елның гыйнварында рәсми рәвештә Ленинград мәчете руханилар штатына билгеләнә. Шушы вазыйфасыннан 1932 елның язында революциягә кадәр патша жандармериясе белән хезмәттәшлектә гаепләнеп кулга алына. Гаебен танымый. Баязитов биш елга Темниковтагы хезмәт-төзәтү лагерена сөрелә. Аннан Казанга килә.

1937 елның 6 декабрендә кулга алынган мәлдә ул Казанда кызы Вәлидә гаиләсендә яши һәм хисапчылар курсларында укый торган була. 1937 елның 26 декабрендә атып үтерелә.



1
159 нчы дивизия гаскәриләре Корбан бәйрәме намазы вакытында. 14–16 сентябрь, 1917 ел.

2
Санкт-Петербург мәчете.

3
Санкт-Петербург мәчетендә җомга намазы. 1915 ел.

АЯУСЫЗ КИТАПЛАР, ЯКИ ХӘТЕРДӘН БАШКА ЯШӘП БУЛАМЫ?

Автор: **Луиза Янсуар**

Нәшриятлар 2021 елда кызыклы басмалар белән шатландыруын дәвам итә. Бу хәвефле һәм тотрыксыз чорда – ни гаҗәп! – безне хәтер темасына кайтырга һәм уйланырга өндиләр. Гадәти генә ракурстан түгел, ә сискәндерә торган ракурстан: әйдәгез, үзебезнең иң нечкә һәм яклауга, яратуга мохтаҗ чагыбызны искә алыйк... Әйдәгез, шуннан ничек исән чыгуыбызны хәтерлик тә, нинди көчкә ия булуыбызга гаҗәпләник...

ЯФРАКЛАР КЫШТЫРДАГАНЧЫ, ЯКИ ҖЕПНЕҢ ОЧЫ БУЛМАСКА ДА МӨМКИН...

Эмили Раскович, «Айдахо»
Фантом Пресс, 2021

Кайбер китапларга аяк басу зур куркыныч белән яный. Чөнки син алардан исән-имин чыга алмаска да мөмкинсең. Ә инде исән килеш чыккан очракта, дистәләгән, бәлки йөзәрләгән елларга картаеп чыгу хәтәре бар. Дөнья яралары, эзен калдырып, йөрәгеңдә җөйләнә алачакмы, юкмы – Вакыт күрсәтәчәк. Хәер, җөйләнсә дә, ул җөйләрнең барлыгын син инде башка беркайчан да онытмаячаксың.

Мәсәлән, Этель Лилиан Войничның «Кигәвен», Виктор Гюгоның «Көлә торган кеше», Мэри

Шеллиның «Франкенштейн», Герберт Уэллсның «Доктор Моро утравы», Уильям Пол Янгның «Алачык», Элис Сиболдның «Сөйкемле сөякләр», Эмма Донохьюның «Бүлмә» әсәрләре калдырган җөйләр... Син аларны мәңге оныта алмыйсың. Киресенчә, кайта-кайта капшап карыйсың, җиһандагы кайбер авырту нокталары яшен тизлеге белән шуларга килеп тоташа.

Һәм менә тагын бер әсәр – Эмили Раскович исемле яшь авторның романы. Һәр битен диярлек: «Ничек яздың син моны? Каян бу кадәр авырттыра торган яктылык һәм әрнү?!» – дип укыдым. Ә бәлки, мондый төр әсәрләрнең феномены да шундадыр – каян икәнен аңлап, җепнең очына чыгып булмый. Җепнең очына чыга торган булсаң, могҗизасы да калмас иде...

«Фантом Пресс» нәшриятында басылып чыккан әлеге китап үзенең шау чәчәкле тышлыгы белән укучыны бер күрүдә «алдый». Әмма бу алдану аша, ахыр чиктә, син барыбер шау чәчәкле болыннарга барып чыгасың, әрнү һәм кичерү тыйнак гөлләр үстергән тугайларга... Ул тугайлар синең туган ватаның җирләре булып тоелмаска да мөмкин. Әмма нигездә Җир шары – түгәрәк. Һәм без – һаман да кешеләр әле.

Укучылары өчен яңа, таныш булмаган авторны нәшрият шактый кырыс һәм аз сүзле итеп презентацияли. Шуның белән беррәттән, «Фантом Пресс» платформасындагы һәм китап тышлыгындагы реноме үтә гади һәм талымсыз да, хәтта ки пастораль рухында, дияргә дә мөмкиндер.

Эмили Раскович Төньяк Айдахо тауларында туып-үсә. Бу яклар үзенең кырыслыгы һәм гаҗәеп матурлыгы белән дан тота. Ул Монтана университетын тәмамлый, Нью-Брансуик университетында инглиз теле магистры дәрәҗәсен ала, ә аннары Айова Язучылар остаханәсендә – романист һәм шулай ук магистр дәрәҗәсен. 2011–2012 елларда Висконсин-Мэдисон университетында фәнни хезмәткәр булып эшли.
Беренче проза тәҗрибәләрен журналларда бастыра. 2015 елда «Сова» журналында дөнья күргән хикәясе өчен О'Генри премиясенә лаек дип табыла.
«Айдахо» романы – чын мәгънәсендә вакыйга буларак кабул ителгән әдәби дебютлардан. Китап берьюлы берничә дәрәҗәле премия финалына уза – Дилан Томас, Эдгар По, Нью-Йорк Китапханәсе премияләре. Нобель премиясеннән соң акчалата дәрәҗәсе ягыннан икенче урында исәпләнгән Халыкара Дублин премиясенә Расковичны, ниһаять, лаек дип табалар.
Эмили Раскович ире һәм бәләкәй кызы белән элеккечә Айдахода яши. Кечкенә генә җирле университетта укыта һәм язу эшен дәвам итә.

Әсәр үзәгендәге гаилә вәкилләре дә Айдахо әсирләре – цивилизациядән баш тартып яшәүче сәер бер пар. Әсәрнең беренче битләреннән үк без бу икәү арасында нәрсәнеңдер дөрес түгел икәнен ваемлап алабыз. Гәрчә арада, беренче карашка, гаҗәеп гармония хөкем сөрсә дә. Әле ул «нәрсәдер» автор тарафыннан тәгаенләнгәнче үк... йөрәкне нидер тырный.

Расковичның стиле әнә шундый: яфраклар кыштырдаганчы ук, искән җилнең юнәлеше яки тыгызлыгы турында киная биреп, тиздән без җирдә, ботаклар коеп төшереп, яфрак юрганы булачагын тоемлап алырдай итеп... сискәндерү... Һәм менә төп героиняның уйлары, тойгылары аша әнә шул тын өермә эченә кереп күмеләбез һәм бу икәүне гомер-гомергә бәйләп тә, аерып та торган һәм торачак фаҗиганең шаһитларына әверeләбез. Ә ул фаҗигане, танырга кирәк, Җир шарындагы бер генә гаилә дә баш очында эленеп калган айбалтасыз кичә алмас иде.

«Көтелмәгән яхшылык яманлыкка караганда да кыенрак тәэсир итә. Ныграк яралый. Аны кайтарыр хак юк. Түләр хак юк. Рәхмәт хисен берничек тә кайтара алмыйсың икән, ул синдә зинданга ябылган ерткыч кебек бәргаләнә...»

Эмили Раскович хәтер белән эш итә. Хәтердән башка яшәү нинди булыр иде – шул кызыксындыра аны. Язучы буларак, ул скальпель тоткан хирург кебегрәк төгәл кизәнә. Бу скальпель зарур: чөнки диагноз – хәлиткеч. Тагын бер соравы: хәтер йөген икеләтә итеп үз өстенә алучылар нәрсә кичерә? Башка берәүнең язмышы һәм намусы өчен без җавап бирә алабызмы? Алмыйбыз икән, нигә кирәк без бер-беребезгә?!

Бу тарихның яралы тарих булуын без, гади укучылар, беренче абзацлардан ук аңлап алабыз. Әмма автор безгә аны, әйтерсең, берничә өрфия пәрдә аша үткәреп карарга мәҗбүр итеп сурәтли. Саклыймы безне шулай итеп, әллә үзен яшерәме? Икесе дә бардыр. Әмма аяу барыбер булмаячак, катарсис та монда – һәркемнең үзенеке. Герметик дөньядан олыгаеп чыккан укучы бу китаптан үз гомерен җөйләрлек шифа да алып чыгарга бик мөмкин.



ШИГЪРИ КӨНДӘЛЕК, ЯКИ БҮГЕНГЕ КӨНДӘ ШАГЫЙРЬ БУЛУ МӨМКИНМЕ?!

Элизабет Асеведо, «Шагыйрь Икс»
«Манн, Иванов и Фербер» нәшрияты

Менә шушы мизгелдә кайдадыр – Җир шарының икенче бер почмагында – гаҗәеп шигъри юллар туа һәм яңа шагыйрь ярала ди. Безнең бу хакта уйланганыбыз бармы? Ә ул шагыйрьнең иҗатын белми калудан безнең никадәр ярлырак булачагыбыз турында?Асылда, бу чынлап та шулай. Күпме

шагыйрьләрнең иҗатын күз уңыннан төшереп калдырабыз һәм безнең үзебезнең күпме шагыйрьләребез локаль бер җирлек – үзебез өчен генә кадерле (ә нигездә кадерсез!) булып калуын дәвам итә. Бәлки, милли телләрдә иҗат иткән очракта, бу хәл ителмәслек дилемма рәвешеннән арынмас та... Ләкин милли идентификацияне глобальләшү контекстында ваемлап, инглиз телендә тәкъдим иткән, асылында тамырларын калкытып, актарып күрсәткән авторлар бар.

Сүз уңаеннан, заман ритмнары һәм трендлары «чиста шигърияте» күптәннән музыкаль яки театраль форматка төрде. Әйтерсең, шигырь генә буларак ул артык беркатлы, хәтта көлке тоела. Бармак белән төртеп күрсәтеп үчекләргә тотынмагайлары! Ә рок яки рэп тышчасына төренсә, яки спектакль, перформанс рәвешен алса, әле ничек тә кичерергә була...

Әмма ни гаҗәп, шигырьнең чиста килеш шигырь булуына сусау да кире кан яңартырга мөмкин икән..

Элизабет Асеведо – тамырлары белән Доминиканага барып тоташучы Америка шагыйре һәм язучысы. Ул Доминиканадан килгән иммигрантлар гаиләсендә туа һәм Нью-Йоркта үсә. Гаиләдә төпчек бала һәм бердәнбер кыз.
12 яшендә Элизабет рэпер булырга карар кыла. Бу хыял белән чын-чынлап мавыгып китә, текстлар иҗат итә. Әмма тора-бара бер нәрсәгә төшенә – ул бары тик шигырь текстлары иҗат итәргә һәм алар белән бүлешергә генә тели. 14 яшендә беренче мәртәбә шигъри бәйгеләр уза торган кафеда үз көчен сынап карый. Аннары шәһәрдәге ачык микрофоннар үзенә җәлеп итә – ул алар каршында күп тапкырлар текстларын узган-барганнарга укый.
Джордж Вашингтон университетында сәхнәдә башкаручы буларак, ә Мэриленд штаты университетында иҗади язу эше буенча бакалавр дәрәҗәсен алганнан соң, Асеведо язучылык семинарларында да белем ала. Аның беренче шигырь җыентыгы – «Шагыйрь Икс» – 2018 елда дөнья күрә һәм чын мәгънәсендә ажиотаж уята. New York Times бу китапны шунда ук бестселлерлар рәтенә кертә, җыентык күпсанлы әдәби премияләргә тәкъдим ителә.
Хәзерге вакытта Элизабет Асеведо Колумбия штатында, Вашингтонда яши. Күпсанлы шигъри слэмнар җиңүчесе һәм кайчандыр башкару осталыгына зур игътибар бирүче буларак, ул барыбер дә язма сүзнең көченә, энергиясенә зур илтифат белән карый. Ә ни өчен бу китапны дөньяга чыгарырга булганлыгы турында менә нәрсә ди: «Көннәрдән бер көнне минем: «Күбрәк укыгыз!» – дигән сүзләремә җавап итеп, укучым: «Безнең турында барыбер китап язмыйлар!» – дип җавап кайтарды. Шунда мин кистереп әйттем: «Мин язачакмын!»

«Шагыйрь Икс» басылып чыгу белән үк сатылып һәм таралып та бетә. Интернет-платформаларда, махсус кушымталарда табып укырга була, русчага тәрҗемәсе әле сатуда да бар. Элизабет Асеведо китабының уникальлеге үз заманының кыю һәм гаҗәеп ихлас каһарманын тудыру һәм яңа шигъри дөнья моделе булдыру гына да түгел. Артык зур амбицияләр белән эш итмичә, академик рухта шапырынмыйча гына, бу XXI гасырның яңа супермодадагы шагыйре асылда үзенә кадәрге классикларның онытылган традицияләренә өр-яңадан җан өрә. Шигъри роман жанры кайчандыр инглиз телле әдәбиятның тренды, яраткан юнәлеше булса, тора-бара ул сүлпәнәя төшә. Ә менә Латин Америкасы белән Кариб утраулары әдәбияты, тәнкыйтьчеләрнең күзәтүләренә ышансак, бу жанрны нәкъ менә хәзер җанландыра, хәтта ки, күпмедер дәрәҗәдә, эксплуатацияли дә.

Әмма Асеведо монда да үзе булып кала бирә – «Шагыйрь Икс» китабында ул гаҗәеп органик рәвештә бүгенге иң модада булган young adult жанры белән беррәттән мемуарларны, верлибр һәм социаль әдәбиятны бербөтенгә укмаштырып тәкъдим итә. Һәм, әйтергә кирәк, аның тавышы, берәүне дә кабатламыйча, искиткеч югары һәм үзәк өзгеч таныш яңгырый.

Үзеңне эзләү, зур тормышка юл сабу, ата-аналар һәм тирәлек-мохит белән конфликтлар аша килешү, килешмәслек очракта, лаеклы ирегеңне даулау, аны раслау... Китапның төп героинясы Сиомара Батиста боларның барысын да әрнеткеч тирәнлек һәм кайнар тынгысызлык белән кичә. Аның белән без дә яшүсмерлек чорының тоташтан яшенләп һәм гөрселдәп торган күк йөзенә баккандай булабыз, аяк астыбызда юктан гына да туфрак тетри башлый...

Гап-гади генә шигъри көндәлек юкса, әмма юк, галәми масштабларга чыгып, яшь җанның безгә чаң оруы, теләктәшлек таләп итүе, яратырга омтылуы, бәхет һәм ирек даулавы, кичерү сукмакларын эзләп таптавы... һәм, ахыр чиктә, ничек тә исән-имин калып, үзен табуы, дөнья белән кул кысышуы булып эверелә ул. Әмма компромисска бару ысулы белән түгел, юк, ә ярату аша аңлашуга килү һәм елмаюга көчүе аркылы...

Ә бит шагыйрь булуның чын бәһасе дә шунда – безне барлык катаклизмнар һәм үләрдәй газаплар аша исән-имин яшәргә алып чыгу.

У меня в семье у одной не библейское имя.
Черт, «Сиомара» – даже не доминиканское.
Я знаю, потому что погуглила.
Оно означает «та, что готова к войне».
И, надо сказать, это правда,
Я пришла в этот мир в стойке бойца.
Меня вырезали из мами
сразу после рождения Хавьера,
моего близнеца.
Вот и мое имя стоном
мучения вырывается у людей без конца,
Как и я вырывалась из чрева.
Медленно повторяю:«Си-о-ма-ра».
Я научилась не беситься в разгаре
Первого учебного дня,
Пока учителя пытаются понять, как же
это произнести.

Мами думала, что это было имя святой.
Сама так назвала свой корабль,
А теперь ругается,
что он плывет над водой.
Мои родители, наверное, хотели девочку,
Которая бы сидела на скамейке,
Банты, улыбка, платье в клеточку.
Самый милый ребенок на свете.
А кого они получили?
Дочь в берцах,
которой бы лучше помалкивать,
Потому что язык ее острее мачете.

Гадәти (асылда, әлбәттә, гайре табигый!) яшүсмер белән бергә без үткән юл чынлыкта үзебезгә һәм әйләнә-тирәбезгә сәяхәт булып әверелә, безне уңайлылык зонасыннан алып чыгып, бик күп нәрсәләр турында уйланырга мәҗбүр итә. Шәхсән үземне шушы китаптагы баланың уйлары аз гына булса да без өлкәннәр тарафыннан «тыңланса», «ишетелсә», бәлки, дөньяның кайсыдыр чылбырында фаҗигаләр булмый калмас иде, дип өметләнергә этәрә. Ә кайсыдыр бер чылбырда без янәшәдәгеләребезнең хакыйкатьләрен кире какмыйча, кабул итәргә, ә үзебезне кичерә белергә өйрәнә алабыз дип өметләнергә урын кала...

(Әмма болар – без өлкәннәр булган һәм җаваплылыкны үз кулыбызга алган очракта гына...)

Элизабет Асеведо үз героинясы турында бик төгәл һәм аяусыз фикер йөртә: «Аның аша бик тә кирәкле нәрсәләр сөйләнелде һәм ул акыл утырту юлында күпмедер дәрәҗәдә уңышка ирешә», – ди ул. (Бу җөмлә алдагы фикернең дәвамы һәм раславы була ала. Әмма булмаска да бик мөмкин).

*Мами была comparona**:*
Высокомерная матрона,
Она шла,
Нос задрав, непреклонная,
Вскидывала голову
С видом таким отрешенным,
Что сразу понятно:
Вы все – ничто.
Она родилась в Санто-Доминго,
Ухажеры пели оды ее славным ножкам,
Но она могла сказать без запинки:
Ее главным мужчиной был Сын Божий.
С самого детства мами росла, мечтая
Носить облачение,
Молиться
И о ближайшем билете до рая.
Ходят слухи, мами заставили выйти замуж за папи,
Чтобы она могла уехать в Штаты.
Бизнес-сделка, если сказать короче.
Но тридцать лет спустя они еще тут,
И я не думаю, что мами простила отца
За то, что он заставил ее изменить Богу.

Әйе, бу – аяусыз һәм кискен караш. Бәлки, кисәтү дә.

Искәрмә буларак: шагыйрь яки язучы аянычлы караш аша беркайчан да үз максатына ирешә алмас иде.

* *Үзен башкалардан ким күреп тә, өстен куярга омтылучы кеше турында.*

МӘМӘТ... ҮЗ БӘҺАҢНЕ БЕЛҮ

Автор: Руфия Фазылова

Әлмәт районына аяк баскач та, нефтьчеләр төбәгендә икәнлегеңне аңлыйсың. Сине бер-бер артлы нефть вышкалары «сәламли». Юллар тигез, чиста. Әйе, биредә тормыш республиканың бүтән күп кенә районнарыннан аерыла. Әлмәтлеләр купшырак яши кебек. Һәрхәлдә, читтән караганда шулай күренә. Ә җирле халык бу турыда үзе ни уйлый соң? Үзенең кара алтын өстендә утырганын тоямы?

Фото: Александр Ефремов

МӘМӘТ

БАЛТА ОСТАЛАРЫ АВЫЛЫ

Әлмәттән егерме чакрым ераклыктагы Мәмәт авылында булдык. Шактый зур авыл ул. Төп белем бирү мәктәбе, балалар бакчасы, мәдәният йорты, ФАП – барысы да халыкка хезмәт күрсәтә. 834 кеше яши, 283 хуҗалыгы бар.

Нефть чыгарыла торган авылларга барсаң: «Бу чишмәне нефтьчеләр ясады. Юлны да алар карап тора», – дип сөйлиләр иде. Мәмәткә баргач та шундый сүзләр ишетербез дигән идек, булмады. «Сабан туе үткәрергә дә акча бирмәделәр», – диде авыл халкы.

– Хәзер авыллар күбрәк үзсалым акчасы хисабына яши инде, – ди Мәмәт авыл җирлеге башлыгы Илсөяр Зөбәерова. – Юлны да карыйбыз, башка проблемаларны да хәл итәргә тырышабыз. Ә авыл зур, проблемалар чыгып кына тора...

Бер карасаң, Мәмәткә цивилизация күптән килгән – 1985–1986 елларда ук авылга газ кергән, үзәк юлга асфальт салынган, йортларга су кергән. Тик боларның барысын карап, яңартып торырга кирәк шул. Халык та, бер яхшыга иялләнгәч, начарны тиз күрә икән. Ничек кенә булмасын, Мәмәт – төзек, мул тормышта яши торган авыл.

– Мәмәт элек-тән үк балта осталары авылы саналган, – дип сөйләде гомерен балалар укытуга багышлаган Нурсинә апа Фәрхетдинова. – Ат арбасы, ат чанасы ясаучылар күп иде бездә. Лениногорск районы Куак авылында зур базар эшләде. Чаналарны берберсе өстенә куеп, арбага төяп, шул базарга алып китәләр иде. Безнең авылга арба-чана сатып алырга килүчеләрне яхшы хәтерлим. Акчага да сатып алалар иде, тик күп очракта аларны атка алыштырганнары истә.

Арба-чана ясаучылар турында бүтән кешеләрдән дә ишетергә туры килде. «Бездәге ир-атларның балталары чаж-чож килеп торган. Бик оста куллы булганнар», – дип сөйләделәр. Балта эшен белү җирле халыкны ашлы да иткән, данын да тирәякларга тараткан. Кызганыч, җитмешенче елларда балта эшен белүчеләр сирәгәйгән. Ни өчен дигәндә, арба-чанага сорау кимегән. Ә яшьләр күбрәк нефтьче эшенә тартылган.

1

– Мәмәт – электән үк балта осталары авылы саналган, – дип сөйләде Нурсинә Фәрхетдинова.

2 3 4

Өч ел эчендә музейда 400ләп экспонат җыелган.

Нурсинә апа белән әңгәмәне дәвам иттек. Сиксән яшен тутырган мөгаллимә туган авылы, нәселе турында да күп нәрсәне белә. Шактый кызык мәгълүматлар белән уртаклашты ул:

– Әни мине, унберенче баласын, Мәмәттән җиде чакрым ераклыкта басуда эшләгәндә тапкан. Аннан шул араны җәяү кайтып, өендә кичкә бәлеш салган. Икенче көнне тагын арыш басуына чыгып киткән. Әни барлыгы унике бала тапкан, дүрт баласы 1921 елгы ачлык вакытында үлгән. Әти белән әни бакчачы булган. Без үскәндә бакчада кавын-карбыз, кәбестә, кыяр үстерделәр. Озынча, баллы шул кавыннарны күрше Чупай авылы кибете каршында сатып, шул акчага ипи алып кайтуларым хәтердә. Әти тагын махорка да үстереп сатты. Авыл егетләре көн саен безнең бакчаны басарга җай эзли иде. Әти берүзе балта белән бакчаны саклады. Әйе, әти белән әни бик тырыш булды. Ул заман өчен хәлле дә саналганбыз. Дүрт почмаклы йортыбыз, өйалдыбыз, аңа кушылган тагын бер өебез бар иде. Әтинең атлары, сарыклары, җирләре, унбишләп умартасы бар иде. Әмма колхозлашу елларында, кулак дип, әтинең бөтен мөлкәтен тартып алганнар.

Нурсинә апаның әнисе заманасына күрә укымышлы саналган. Гарәпчә, татарча укый белгән. Бер көн намазын калдырмаган.

– Әнинең безгә, рәсемнәрен күрсәтә-күрсәтә, калын китаплар укыганын хәтерлим,-ди мөгаллимә. – Балаларының да укымышлы булуын теләде ул. Әни гомерендә бер тапкыр дару эчмәде, хастаханә юлын таптамады. Туксан алты яшенә кадәр яшәде...

ИШЕГАЛДЫНДА – МУЗЕЙ!

Мәмәттә Ситдыйковлар гаиләсе белән таныштык. Ирле-хатынлы укытучылар гаиләсе ишегалдында музей ясап куйган. Дөрес, Марат абый инде мәктәптә эшләми – авылда хосусый кибетен ачкан. Ә Ләлә ханым Мәмәт төп белем бирү мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Гаилә башлыгы хәзер сәүдәгәрлек эшендә булса да, тарих, фән белән кызыксынуын югалтмаган. Берничә ел элек ул нәсел шәҗәрәсен төзегән. Аны матурлап эшләп, өй түренә үк элеп куйганнар.

– Музей ясауга нәкъ менә шәҗәрә этәргеч булды, – дип сөйли Марат Ситдыйков. – 2000 нче елларда үзебезнең нәсел җепләрен өйрәнә башладым. Тарих ул бик кызык, шунда ук тартып ала. Хәзер буш вакыт булган саен интернетны ачам, безнең як тарихын өйрәнәм. Музейда булган экспонатларга охшаш әйберләрне эзлим. Кайчан эшләнгән, нәрсә белән бәйле... Чөнки безгә килеп эләккән экспонатларның кайберләре турында мәгълүмат бөтенләй юк. Шуларны ачыклыйсы иде.


4

Гаилә башлыгы белән музейга уздык. Монда ни генә юк... Егерменче гасыр башында авылның яшәешен күрсәткән барлык көнкүреш кирәк-яраклары, элеккеге хатын-кыз, ир-ат киемнәре, хәтта сугыш кораллары да бар.

– Музей ачу теләге ничек барлыкка килде? – дим хуҗага.

– Өч ел элек булды ул хәл. Унтугызынчы май иде. Телевизордан Музейлар көне турында сөйләделәр. Шуннан уйлап куйдым: ишегалдында җәйге йорт бар, ул буш тора. Өйдә әнинең килен булып төшкән чактан калган сандыгы, иске комган, самовар саклана. Музейның беренче экспонатлары әзер дигән сүз! Ниятемне Ләләгә әйткән идем,

5 Ирле-хатынлы Ситдыйковлар ишек алдына музей ясап куйган.

5

6

Илмир Шәфыйков берьюлы әллә ничә һөнәр үзләштергән.

7

– Нефтьче булу да җиңел түгел, – ди Рагиз абый.

8

Илмирга әтисе Рагиз абый да ярдәм итә.

ул күтәреп алды. Шуннан китте инде... Күршеләр, туганнар өйләрендә булган иске әйберләрне бирә башлады. Яшел Үзәндә туганнар яши, аннан да алып кайттык.

Өч ел эчендә музейда 400ләп экспонат җыелган. Махсус дәфтәр башлаганнар – һәр экспонатның исеме, музейга ничек килеп эләгүе турында мәгълүмат бар.

– Кайбер әйберләрне сатып та алабыз,- дип сүзгә кушылды Ләлә апа. – Безнең кебек «сәер» кешеләр күп бит. Интернет аша аралашабыз, экспонатлар белән алмашабыз. Елдан-ел азарт арта гына бара.

– Ә иң борынгы экспонат ничәнче гасырга карый? – дим.

– Унтугызынчы гасыр башларына караган тәлинкәле үлчәүдер, – диде хуҗа кеше. – Үзем инде сәүдәгәр дә булгач, ул миңа бик якын. Тагын бер яраткан экспонатларымнан берсе – 1980 елда узган Олимпиада символлары төшерелгән күлмәк. Хәтта этикеткасы да алынмаган...

Башка музейлардан аермалы буларак, биредә экспонатларны кул белән тотып карарга ярый. Мәсәлән, егерменче гасыр башында ясалган агач парта артына утырып, музейдагы берәр иске китапны укырга мөмкин. Мәктәп балалары шулай эшли дә икән.

– Әле бүген мәктәп лагерена йөрүче балалар килде, бик кызыксынып карадылар, – ди Ләлә апа.

Егерменче гасыр башында ясалган парта-урындыктан кала, тагын үзенчәлекле җиһаз бар монда – йөз еллар элек чамасы эшләнгән шкаф.

– Кибет каршында бер бабайның йорты бар, – ди Марат абый. – Җәйләрен кайтып монда яши. Музей ясагач та бабайдан әлеге шкафны сорадым. Бирмәде. Әти-әнисеннән калган кадерле җиһаз икән. Кибеттән буяулар алып чыгып, матурлап куйды ул аны. Узган ел исә үзе чакырып кертте: «Улым, минем рәт бетте. Миннән соң ул шкафны барыбер тураклап атачаклар, музейда торсын», – диде. Мәмәттә кул осталары бик күп булган. Әлеге шкафны да үзебезнең авыл осталары ясаган булырга тиеш.

Экспонатлар күбәеп китсә, җәйге өйнең тагын бер ягы бар. Шунда дәвам итәргә булачак икән. Менә шулай уйнап кына башланган эш чынга әйләнгән.

Ситдыйковларның музее һәр кешегә ачык:

– Әлбәттә, бушка! – диделәр.

УКЫТУЧЫ, ТАМАДА, ТИМЕРЧЕ...

Авылда яшьләр булу бүген олы сөенечкә әйләнде. Мәмәтлеләр дә Илмир Шәфыйков кебек талантлы егетнең туган авылыннан читкә китмәвенә сөенгән. Илмир ир-аттан таләп ителә торган эшләрнең барысын да үтәгән – йорт салган, гаилә корган, агач утырткан. Йорт дигәннән, монда барысы да заманча: хәтта үз куллары белән бассейн да ясаган. Аның төбен цемент измәсе белән катырган. Су үзе тула, кранны ачкач агып чыга. Хәтта биредә су шланглары да аунып ятмый – эш беткәч, Илмир аларны көпчәктән ясаган җайланмага түгәрәкләп җыеп куя. Ишек алдында балалар мәйданчыгы, тагын әлләниләр...

– Үземнең бала гына түгел, мәктәп укучылары да уйнарга килә, – ди мөгаллим.

Бу урында шуны әйтим: Илмир Мәмәт төп белем бирү мәктәбендә инглиз теле укыта. Сөйкемле укытучының сөйләм теле матур, фикере анык. Һичшиксез, мәктәптә аның кебекләр эшләргә тиештер.

– 2012 елда Алабуга дәүләт педагогика университетының татар-инглиз теле бүлеген тәмамладым, – диде ул. – Шуннан соң ике ел күрше Кичүчат мәктәбендә эшләдем. Аннан Мәмәт урта мәктәбенә чакырып алдылар. Шуннан бирле туган мәктәбемдә укытам.

Илмир инглиз телендә иркен аралаша. Ләкин мине икенче әйбер гаҗәпләндерде – берьюлы әллә ничә һөнәр үзләштергән ул. Һәм аларның барысын бергә алып бара. Мөгаллимнең икенче һөнәре – тамада. Әлмәтлеләргә аның исеме яхшы таныш, якын-тирә районнарга да мәҗлесләр алып барырга йөри икән.

– Укытучы һәм тамада. Бер-берсеннән шактый ерак торган һөнәрләр, – дим Илмирга.

– Тамада һәм укытучы дияргә кирәктер. Университетның икенче курсында укыганда ук бәйрәмнәр алып бара башладым. Студент чакта КВНда күп катнаштым. Бергә сәхнәдә йөргән кызлар миңа үзләренең чыгарылыш кичәсен алып



барырга тәкъдим иттеләр. Риза булдым. Шуннан күп тә үтмәде, кулына диплом алган шул кызлар кияүгә чыга башлады. Ә мине тамада итеп чакырдылар. Һич уйламаган җирдән бу өлкәгә кереп киттем. Шулай итеп студент вакытта ук акча эшли башладым.

– Мәҗлесләр мәктәп эшенә комачауламыймы? – дим.

– Мин мәктәптә ярты ставкада гына эшлим, сәгать саннарым тулмый. Атнасына өч кенә көн укытам. Комачауламый.

Пандемия вакытында исә Илмир тагын бер яңа һөнәр үзләштергән – тимерче. Дөрес, бу эштә этисе Рагиз абый да булыша, чөнки эретеп ябыштыру эшләрендә ярдәмче кирәк икән.

– Берара бит туйлар, банкетлар уздырылмады, – диде ул. – Яшерен-батырын түгел, укытучы хезмәт хакына гына яшәргә авыр. Аннары, тик торырга да өйрәнелмәгән. Гаражда эретеп ябыштыру аппараты бар иде. Үзем өчен шуның белән мангал ясап карадым. Шуннан туганым: «Ясый аласыңмы?» – дип интернеттан бер үрнәк күрсәтте. «Аламдыр, әллә ни авырлыгын күрмим», – дидем. Шулай итеп эти белән заказга беренче мангалны эшләдек. Ул эшне кызык өчен генә интернетка куеп караган идем, заказлар китте. Нәтиҗәдә, узган ел егерме дүрт мангал ясадык.

Бер ел эчендә тимер бәяләре нык арткан. Тик Шәфыйковлар әле бәяне арттырмаган. «Узган ел күп итеп тимер сатып алган идек, әлегә шулар белән эшлибез», – диде. Бер мангал якынча унбиш-егерме мең сум тора икән.

– Бер мангалны ничә көн эшлисез? – дип сорадым.

– Гел шуның өстендә генә торсаң, ике-өч көн эчендә ясап була, – ди тимерчеләр.

Рагиз абый белән аерым да аралашып алдык. Гаилә башлыгы күп еллар колхозда эшләгән, ә соңгы унҗиде елда нефтьчеләр сафына баскан.

– Ашаган белми, тураган белә, – диде Рагиз абый. – Нефтьче булу да җиңел түгел. Көн саен сероводородка батып кайтасың. Эшләгәндә хезмәт хакы ярый үзе, шуңа түзәсең. Хәзер инде пенсия алам, күп түгел, уналты-унҗиде мең тирәсе. Шуңа чама булганда эшләргә инде.

...Әлбәттә, берничә сәгать эчендә бөтен авылны йөреп чыгып булмый. Аралашкан кешеләрдән соң нинди дер бер фикергә киләсең. Мәмәтләләр үз бәясен белүче, уңган халык булып тоелды. Матур яшәү алар өчен хыял түгел, ә гадәти хәл. Үзләрен нәкъ менә шундый тормышка лаек дип саныйлар. Бу яктан күпләребезгә алардан өйрәнергә була...

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Кайбер тарихи чыганаклар буенча, Мәмәт авылына моннан 300 еллар элек нигез салынган. 1733–1744 елларда үткәрелгән халыкны исәпкә алу документларында Мәмәттә бер йорт күрсәтелгән. Беренче фараз буенча авылның исеме Килмәмәт Әмәтов (Альминеев) атлы кеше хөрмәтенә бирелгән. (Кызганыч, бу турыда мәгълүмат аз).
Икенче фараз да бар. Анысы халык күңелендәге риваять белән бәйле. Мәмәткә Пәси бабай (Фәсхетдин) нигез салган, диләр. Ул бу якларга килеп чыгып, урман белән капланган олы тау итәгендә шактый вакыт сокланып утырган. Тау битендә чишмә күреп, шуннан су эчкән. Һәм бу якларда төпләнеп калырга уйлаган. Тау итәгендәге әлеге чишмәне халык бүген дә Пәси чишмәсе дип атап йөртә.

(Мәгълүмат Мәмәт мәктәбе музееннан алынды).

ЙӨРӘК ВӘ ГАКЫЛГА ЛӘЗЗӘТ

Чал чәчле серле борынгылык, төрки символларда һәм бормалы-сырмалы гарәп язуында яшеренгән бөек тарих… Без Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә ачылган тиңдәшсез күргәзмәдә. Оештыручылар әлеге экспозицияне «Татар китабының глобаль дөньясы» дип атаган.

Автор:
Нияз Әхмәдуллин



Меңьеллык мәдәниятнең шаһите булган гасырлар кичкән язуларны күргәндә, дулкынлану, тетрәнү, соклану, горурлык кебек хисләр биләп ала. Борынгы кабер ташларындагы каллиграфик эпитафияләрдән XX гасыр татар әдәбиятына кадәр - болар барысы да үзендә төрле чорларны һәм цивилизацияләрне чагылдырган, Мәгърибне һәм Мәшрикъне колачлаган татар язуы. Заманча технологияләр исә аларны күрү генә түгел, виртуаль рәвештә булса да «капшап карарга» булыша.

Экранга баскалауга, көйле татарча сөйләм ишетелә. Нәфис сүз остасының тавышына ләззәтләнеп, юлымны дәвам итәм. Менә монда бик үзенчәлекле инсталляцияләр. Алар янында кунаклар мәхәббәт, уңыш һәм бәхетнең башка гаҗәеп тә, ымсындыргыч та мәгънәләрен чагылдыра торган төрки символлар белән кабатланмас селфи төшерергә ярата. Барлык бу тарихи символлар, проектордан җылы яктылык булып төшеп, йөзегез буйлап салмак кына шуып үтә.

Кызганыч, XVII гасырдан борынгырак кульязма китаплар сакланмаган. Ә XVII гасырга караган һәм аннан яңараклар безгә бик аз санда килеп җиткән. Менә ул китапларның оригиналлары һәм аларның диварда инсталляцияләре – бу китаплар гарәп хәрефләре белән фарсы телендә язылган, Голландия кәгазендә басылган. Глобаль дөньяда татар мәдәнияте үсешенең, үзендә төрле гадәт-йолаларны берләштерүнең үрнәге түгелме бу? Ә менә монысы – бөтен мөселман дөньясына данлыклы почмаклы-почмаклы Казан шрифты белән басылган Коръән (мәгълүм «Казан басмасы»).

Күргәзмә кунаклары магия һәм медицина турындагы китаплар янында да кызыксынып туктала. Урта гасырларда алар гел янәшә йөргән. Менә монда яңалиф, ә аннан соң латин хәрефләре һәм кириллица, алар XX гасырда, совет чорында, татар графикасы үсешен чагылдыра. Хәтта иң беркатлы, тәҗрибәсез тамашачы да совет чорының татар тарихында бик аз өлешне генә тәшкил итүен аңлый. Өстәвенә ул заманга төрлечә бәя бирелә.

Чорлар бәйләнеше һәм бу бик тирән тарихи процесста, кечкенә булса да, үз ролең, үз урының барлыгын, шушы бөек мәдәниятка үзеңнең дә чит түгеллегеңне тою – күргәзмә залыннан чыкканда, күңелне һәм аңны, мөгаен, нәкъ менә шундый якты хис вә уйлар биләп аладыр.

2021

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ

Татарстаннан кайнар сәлам!

2021

**ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА
В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ**

* Сезне яратып – Татарстаннан!
(әрмән теленнән тәрҗемә)

Татарстанда 5 987 әрмән кешесе яши
(2010 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча).